PRESSA.RU

ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

№8 (308) – АВГУСТ 2017

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

1920 елдан нәшер ителә

Президент күргән Татарстан

Камил Исхаковның яраткан ризыгы

Тыелган исемнәр



КИЛӘЧӘКНЕ БҮГЕН ТӨЗИБЕЗ

4 612750 670011

PRESSA.RU

16+

Редакция:
420066, Казан,
Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина, vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров, sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасарлары:
Нияз Әхмәдуллин, ahmadullin@tatmedia.com
Алсу Дәүләтшина
Чыгарылыш мөхәррире:
Фәридә Әхмәтҗанова
Әдәби мөхәррир: Луиза Янсуар
Бүлек мөхәррирләре:
Ольга Туманская, Олеся Бондаревская,
Руфия Фазылова
Махсус проектлар бүлеге җитәкчесе:
Алсу Троицкая
Веб-редактор: Алсу Дәүләтшина
Авторлар: Катерина Котова, Ксения Сёмина,
Фаяз Хуҗин
Фотограф: Александр Ефремов
Дизайн-макет: Леонид Гобәйдуллин
Вёрстка: Игорь Глушков, Леонид Гобәйдуллин,
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Тышлыктагы фото: Александр Ефремов

Журнал 1920 елдан нәшер ителә

1979 елда Халыклар дуслыгы
ордены белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәттә теркәлгән. Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж: 4500 данә,
шул исәптән татар телендә – 1500.

Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан» журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела. Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри. Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция җавап бирми. «Промо» һәм «Медиа» рубрикалары материаллары реклама-коммерция нигезендә басыла.

Журнал «Татмедиа» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә **басылды**: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ № А-1963

Басарга кул куелды: 21.08.2017

Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Миләүшә Байрашева,
milyaushanb@tatmedia.com

Коммерция директоры:
Нина Әхмәтшина, nivlana@tatmedia.com,
тел. (843) 222-09-76

Коммерция директоры урынбасары:
Александр Березовский

Сату бүлеге белгече:
Гөлфия Фәттахова

Махсус проектлар бүлеге белгече:
Җәмилә Әхмәтшина, ahleva5@mail.ru

Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел. (843) 222-09-80

КИЛӘЧӘКНЕ БҮГЕН ТӨЗИБЕЗ…

Әлеге бәяннең авторы яшьлегендә, мөгаен, сирәк очрый торган пессимистлардан булгандыр. Ә бәлки, ышанмаучылар, бөтен нәрсәгә шикләнеп карарга яратучылар затыннандыр. Әйтик, ул Казансу ярларының (ни уң ярының, ни сулының) кайчан да булса бүгенге кебек төзек, күз явын алырдай хәлгә киләчәгенә һич кенә дә ышана алмады. Әмма үзегез шаһит: менә диген итеп ныгытылган хәзер ул яр буйлары, мәһабәт йортлар калкып чыкты, экскурсияләр гөрләп тора… Гәрчә теге чакта киләчәк проектларын үз күзләре белән күрсә дә, «Казанда боларның гомергә булачагы юк, әкият сөйләмәгез!» – дип кырт кискән иде авторыбыз.

Бүген исә ул телен тешләргә мәҗбүр. Казанның бу яңа манзарасын да табигый буларак кабул итә хәзер. Чөнки күз алдында калыккан бу матурлыкны чынбарлыкта күргәч, ирексездән, аларны челт-челт йомып кына тора аласың. Менә бит алар – уң яры да, сул яры да. Йортлары һәм туристлары да – үз урынында. Йөриләр, сокланалар, фотога төшәләр. Без фәкыйрегез дә алардан калышмый – үрдәкләр ашата, башка шәһәрләрдә яшәүче дусларына Казанның иң матур урыннарында төшкән селфиларын җибәреп мактана. Һәм эченнән генә кайчандыр бу якын киләчәккә ышанмавы хакында берәүнең дә искә төшермәвенә сөенә.

Авторның үзтәнкыйть белән мавыгып язган бу юлларын укыганда, үзегезгә сабак алып укыгыз, дип тә өстисем килә. Татарстанда булдырып булмый торган нәрсә юк, монда барлык могҗизалар да чынга ашарга мөмкин. Ислам академиясе дә, пилотсыз «КАМАЗ» да, дөньядагы иң җитез бомбардировщик та, экологиянең барлык таләпләргә дә җавап бирә алырдай чүп-чар яндыру заводы да… Тагын нәрсәме? Югары тизлекле магистраль, бәлки? Анысы әле бүгенгә юк, әмма иртәгә булачак. Һәм психологлар белән коуч-тренерлар безне ничек кенә бүгенге көн белән яшәргә өндәмәсен, без барыбер киләчәккә йөз тотабыз. Юк, артыннан кумыйбыз, кирәкми дә, барыбер куып тота алмаячакбыз. Без аны якынайтырга тырышабыз – аңардан бүгенгегә күчереп алып булган бөтен нәрсәне эшләп. Чернышевскийның бу рухтагы фикерләрен әле мәктәп эскәмиясеннән хәтерләүче буларак әйтәм моны. Ул фикерләр ми бураэналарына чыкмаслык булып сеңеп калган. Һәм ул бураэналар сиңа, һичшиксез, киләчәкнең картинасы «якты һәм искиткеч гүзәл» булачак дип, сигнал бирергә әзер. Бары күчерә белергә генә кирәк, менә шул!

Ә алдыбызда торган иң якын киләчәк – ул Республика көне. Аның кәефен, әйдә, бүгенгебезгә дә күчерик әле. Бәйрәмчә булсын, күңелле. Татарстаныбызның киләчәкне бүген үз куллары белән торгызып яшәүче халкы моңа лаек бит.

Бәйрәм белән! Республика көне белән!

СЕЗНЕҢ РЕДАКЦИЯ

Редакция советы:
АЛАЕВ Юрий Прокопьевич
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рәфкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзум Кәлимуллович
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

татмедиа

Гамәлгә куючы:
«Татмедиа» АҖ
Нәшер итүче:
«Татмедиа» АҖ

420097, Казан,
Академическая ур., 2

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә
Индекс **П2381** – татар телендә
Индекс **П2378** – рус телендә

Яртьы елга язылу бәясе:
900 сум 00 тиен

«ТАТАРСТАН»НЫҢ КАРТИНАЛАР ГАЛЕРЕЯСЫ



Эдуард Жалдак. «Җәйге Болак». 2011 ел.

АВГУСТ. КАЗАН

ЭЧТӘЛЕК

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

6. Республика көне.
Безне нинди бәйрәмнәр берләштерә

14. Туган тел: илләр һәм континентлар.
Чит ил татарлары ничек яши

18. Исәнме, «Аккош».
«Карчыгалар» төшләрендә ниләр күрә

24. Яңа проектлар.
Чүп-чар өемнәре кая китәчәк

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

32. Камышлы җәннәт.
Казанның кайсы урынында табигый оазис пәйда булачак

38. Исемнәр турындагы закон.
Тыелган исемнәр

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

44. Тарих битләре.
Чүлмәк кенә, димәгез...

48. Аш-су.
Камил Исхаков бәрәңгене ничек кыздыра

58. Тау итәгендәге кала.
Иң биек тау – Азнакайда

64. Тормышны ничек матурларга.
Азнакай районы башлыгыннан киңәш.

94. Авылларыбыз.
Якты Күл авылына 90 яшь

108. Кызыклы авыллар.
Минзәлә Аюы

112. Татарстан риваятьләре.
Емельян Пугачёв хәзинәләре кайда яшерелгән



PRESSA.RU

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

03.08

Владимир Путин, Россия Федерациясе Президенты, – Бөтендөнья татар конгрессының VI съездында катнашучыларны котлау хатында:

– Диннәр, мәдәниятләр, традицияләрнең күптөрлелеге хаклы рәвештә күпмилләтле Ватаныбызның төп байлыкларыннан берсе булып тора. Дәүләт һәр халыкның милли тәңгәллеген һәм үзенчәлеген саклау, илдә тынычлыкны, милләтара һәм динара тынычлыкны ныгыту мәсьәләләренә аеруча игътибар бирә.

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

03.08

Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Президенты, – Казанда Бөтендөнья татар конгрессының VI съездында пленар утырышта чыгыш ясаганда:

– Республиканың Татарстаннан читтә яшәүче татарларга ярдәм итү юнәлешендәге эшчәнлеге Татарстан Республикасы Конституциясендә беркетелгән. Татарлар кайда гына яшәсәләр дә, Татарстанны үзләренең тарихи ватаннары дип саныйлар. Шуңа күрә телне, мәдәниятне һәм традицияләрне саклау һәм үстерү безнең бурычыбыз булып тора.

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

09.07

Александр Кузнецов, РФнең ЮНЕСКО каршындагы даими вәкиле, – Краковта ЮНЕСКО Бөтендөнья мирасы комитетының 41нче сессиясендә:

– Татарстан Республикасында ЮНЕСКО Исемлегенә кертелгән ике объект бар инде. Беренчесе – христиан соборы һәм мөселман мәчете янәшә урнашкан Казан Кремле. Икенчесе – рәсми рәвештә Ислам кабул ителгән борынгы Болгар шәһәре. Ә бүген өченчесе кабул ителә – христиан дине энҗесе булган Успение соборы һәм Свияжск монастыре. Әлеге өч объект – Татарстан җитәкчелегенең төрле диннәр арасында тынычлык һәм татулыкны ныгытуга юнәлтелгән зирәк сәясәтенең чагылышы. Дини нигездә килеп туган низаглар белән тулы бүгенге дөньяда бу аеруча актуаль.

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Безне **НИНДИ** бәйрәмнәр берләштерә

Конгресс кунаклары **НИНДИ** фикерләр әйттеләр

«Аккош» **КАЙДА** җыелачак

Яңа заводның **НИНДИ** өстенлекләре бар

PRESSA.RU

ПРЕЗИДЕНТ
КҮРГӘН ТАТАРСТАН



Республикабызның иң ерак почмакларында нинди хәлләр барлыгын белеп торыр өчен, аларның барысын да йөреп чыгу мәҗбүри түгел хәзер. Сезнең өчен моны Татарстан Президенты башкарачак. Тизлек буенча бер генә ММЧ да барыбер Рөстәм Миңнехановны уздыра алмаячак. Ул сезгә бер генә видеокамера да терки алмаганнарны, бер генә журналист сорарга батырчылык итмәгәннәрне күрсәтергә мөмкин. Президент «Инстаграм»ында без республиканы ничек бар, нәкъ шулай күрә алабыз:



ВАТАНПӘРВӘР ИТЕП
СПОРТКА ГАШЫЙК ИТЕП
МОДАЛЫ ИТЕП
ЗИРӘК ИТЕП
ТОЛЕРАНТЛЫ ИТЕП
ГАЗИЗ ИТЕП

PRESSA.RU

Фото: Василий Иванов («Татар-информ» МА)

БЕЗНЕ БЕРЛӘШТЕРҮЧЕ БӘЙРӘМНӘР

Татарстан – үз территориясендә яшәүче барлык халыкларның бәйрәмнәренә бер үк төрле игътибар бирелә торган төбәк. Шуңа күрә татарстанлылар һәрвакыт бөтен төр бәйрәм традицияләреннән хәбәрдар.

Бәйрәмнәр елы 30 августта Республика көне белән башлана һәм көнчыгыш белән уртак Нәүрүз һәм Корбан бәйрәме, русларның Май чабу көне һәм Караоннары, татарларның Сабантуе һәм Ураза бәйрәме, удмуртларның Гырон быдтоны, яһүдләрнең Песахы, мариларның Семык бәйрәме, чувашларның Уявы, мордваларның Балтае, керәшеннәрнең Питрау бәйрәме, славяннарның Янка Купалалары белән дәвам итә. Бәйрәмнәр елы янәдән 30 август – барлык халык күңел ача торган Республика көне белән тәмамлана. Татарстанда менә шундый күңелле эмоцияләргә бай вакыйгалар өермәсе хакимлек итә. Милли киемнәр, милли ризыклар, милли җыр-биюләр – ата-бабаларыбыздан бүгенге көнгәчә килеп җитеп, күпмилләтле Татарстанның төрле почмакларында гомер итүче халыклар дуслыгы белән беркетелгән кыйммәтләр безгә әти-әниләребезнең гореф-гадәтләрен саклаган, туган телен сөйгән кеше генә бәхетле була алуын искәртеп тора, шуңа күрә бездә ватаннарыннан читтә яшәүчеләр дә туган нигезләре җылысын тойсын өчен, барысы да эшләнә.

PRESSA.RU

САБАНТУЙ.
АЗНАКАЙ.
Татар
милли
бәйрәме.

PRESSA.RU

Фото: Зилия Әхсәнова

УЯВ. **НУРЛАТ.**
Республика
чуваш
мәдәнияте
бәйрәме.

PRESSA.RU

Фото: Александр Ефремов

ПИТРАУ. ҖӨРИ.
Мамадыш районы.
Республика
керәшен
мәдәнияте
фестивале.

PRESSA.RU

БЕР ОЧРАШУ ҮЗЕ БЕР ГОМЕР...

Бөтендөнья татар конгрессының VI корылтае узып китте. Бу эштә Татарстаннан – 106, Россиянең 73 төбәгеннән – 500, 41 ерак һәм якын чит илдән 250 делегат катнашты. Чара турында татар дөньясы шактый алдан сөйләде. Берәүләр аңа зур өметләр баглады, икенчеләр исә моны чираттагы татар «тусовкасы» итеп кенә кабул итте. Нәрсә генә әйтсәләр дә, мондый очрашулар кирәк. Ул – дөньяның төрле почмакларына таралган милләттәшләребезгә бергә җыелу өчен бер дигән форсат.



Автор:
Руфия Фазылова

«МИЛЛӘТНЕ САКЛАУ – ТЕЛНЕ САКЛАУ!»

Газета-журналлар, телевидениедә бу көнне «татар» сүзе ешрак ишетелде. Ә корылтай милләткә нәрсә бирә соң? Нәтиҗәләре нинди булыр? Әлбәттә, өч көнлек җыенда еллар буе җыелып килгән проблемаларны хәл итеп бетереп булмый. Ләкин ул көнне, һич югында, алар хакында кычкырып әйтелде. Мисал өчен, Казан шәһәренең Ш. Мәрҗани исемендәге 2нче татар гимназиясе директоры Камәрия ханым Хәмидуллина: «Милләтне саклау – телне саклау, – диде. – Ә телне саклау шул телдә язылган дәреслекләрдән укыту ул. Бүген исә татарча дәреслекләр чыгару бетте. Милли кадрлар әзерләү юкка чыкты. Милли матбугатка ихтыяҗ кимеп бара. 11 ел буе балаларга белемне татар телендә бирәбез дә чыгарылыш имтиханнарын рус телендә тапшырырга мәҗбүр итәбез. Хөрмәтле Президентыбыз, Сезгә укытучылар, ата-аналар исеменнән мөрәҗәгать итәбез: 362нче боерыкны юкка чыгару буенча федераль үзәк белән аңлашу табарга кирәк. Без Сезгә таянырга телибез!» Залда утыручылар тын калды: күрәсең, аларның да күңелендә йөргән фикер бу...

Корылтай делегатлары исә күбесе бер фикердә: татар – бөек милләт. Аның зур тарихы, горурланырлык үткәне бар. Киләчәге дә шундый булырга тиеш. Тел мәсьәләсенә килгәндә, гомер буе Кытай, Канада, Иранда гомер итеп тә, Казанда яшәүче күп кенә милләттәшләрдән яхшырак сөйләшкән татарлар бар. Ә иң гаҗәпе менә нәрсә: Казанда еш кына ата-аналардан бер фикерне ишетәсең: «Татар теле нигә кирәк, имтихан бирмисең, эшкә кергәндә кирәкми...» Ә чит илдә яшәүче милләттәшләр: «Татар телен белсәң, Көнбатыш, Урта Азия

Фото: Александр Ефремов

илләрендә яшәүчеләрнең телләрен дә аңлыйсың. Санаулы айлар эчендә фарсы телендә сөйләшә башлыйсың», – дип раслыйлар. Чынлап та, санкцияләр белән бәйле, Россия соңгы елларда күбрәк Азия илләре белән элемтәне ныгыта. Ә димәк, татар телен өйрәнү өчен бер стимул бар дигән сүз. Бу очракта безгә, һичшиксез, чит илләрдә яшәүче милләттәшләребездән үрнәк алырга кирәктер.

Бөтендөнья татар конгрессының VI корылтае узгач, иң күп тикшерелгән темаларның берсе, һичшиксез, Милли шура оешу булды. Мондый тәҗрибә татарларда нәкъ бер гасыр элек булган икәнен беләбез. 1917 елның май аенда узган Бөтенроссия мөселманнар корылтаенда барлыкка килә ул. Милли шура составына Россиянең барлык төбәкләрендә яшәүче абруйлы мөселманнар кергән. Аның бурычы – мөселманнарны борчыган проблемаларны Үзәк хакимияткә җиткерү булган. Яңа барлыкка килгән Милли шура да әлеге юнәлештә эшләр дип көтелә: тел, милләт проблемасын дәүләт югарылыгында хәл итү. Шураның рәисе итеп ТР Премьер-министр урынбасары Васыйл Шәйхразыев сайланды. Яңа оешма еллар буе җыелып килгән милли проблемаларны хәл итә алырмы? Монысын вакыт күрсәтер. Һәрхәлдә, без өметләнәбез, ышанабыз...

Корылтайга килгән кунаклар арасында дистәләп кеше белән аралаштым.

Красноярск краеның «Яр» Төбәкара татар милли-мәдәни автономия рәисе Вәгыйзь Исмәгыйлев: «Безнең өлкәдә 33 чып-чын татар авылы бар», – дигәч, ялгыш кына сорау биреп куйдым: «Аларда укыту татар телендә түгелдер инде?» «Юк, әлбәттә, – диде Вәгыйзь әфәнде. – – Рус, украиннар күпләп яшәгән Красноярскида балаларны татар телендә укыттырып булмый...». Дөрес сүзгә җавап юк диләрме әле, шулайрак килеп чыкты.

Ә Үзбәкстанда туган, егерме елдан бирле Америка, соңрак Канаданың Торонто шәһәренә күченгән, «Microsoft» оешмасының әйдәп баручы белгече булган Әмир Җиһаншинның татар телен камил дәрәҗәдә белүенә сокландым да, гаҗәпләндем дә. Тик егет, монда ис китәрлек бернәрсә дә юк дип саный: «Мин бит – татар. Ничек инде үз телеңне белмисең?! Гаиләдә без бары татар телендә генә аралаштык. Хәзер дә шулай. Һәр кеше үзенең ана телен белергә тиеш!» – диде.

Ираннан килгән эшмәкәр Габдерәхим Мәгъфури белән җирле банк җитәкчесе Ибраһим Бинагәр исә бездәге хатын-кызларның ярымшәрә йөрүенә исләре киткән. «Татарлар мөселман динен беренчеләрдән булып кабул итүчеләр. Сездә бит нигездә татарлар яши. Мөселман хатын-кызы ничек шулай йөри ала? Гаҗәп...» Иранда туып-үскән әлеге эшкуар егетләр белән Тарих институтында эшләүче Исмәгыйль Гыйбадуллин ярдәмендә аралаштык. Кунаклар, татарча аерым сүзләрне, җөмләләрне аңласалар да, фикерләрен ана телендә җиткерә алмыйлар икән.

Чит илдә яшәүче милләттәшләребезнең иң кызыклы фикерләрен журнал укучыларыбызга да тәкъдим итәбез.

Әмир Җиһаншин,
Канада, Торонто шәһәренең «Берлек» Татар иҗтимагый оешмасы лидеры, «Microsoft» оешмасының әйдәп баручы белгече:

– 1981 елда Үзбәкстанда Ташкент шәһәрендә туганмын. Уналты яшемдә, 1997 елда, Америкага киттем. Вашингтон штатында урта мәктәпне тәмамладым. Анда югары белем алып, магистратураны тәмамлагач, Канаданың Торонто шәһәренә күчендем. Хәер, эш урыным Америка оешмасы булганлыктан, еш кына тегендә дә, монда да булырга туры килә. Ләкин төп торган җирем дип Канаданы саныйм.

Еш кына сорау бирәләр: «Ташкент мәктәбендә укып йөргән егет ничек Америкага чыгып китте?» Беренчедән, әти-әнигә рәхмәт, алар мине махсус инглиз телен тирәнтен өйрәтә торган мәктәпкә биргәннәр. Икенчедән, кечкенәдән кызыксынучан булдым. Бик күптөрле конкурсларда катнаштым. Америкага китүем дә конкурс аша булды. Анда баргач, мине бер гаилә үзенә алды. Мәктәптә укыганда аларда яшәдем, укыдым. Алга киткән илләрдә бу гадәти тәҗрибә. Үзләренең балалары булган ир белән хатын шу-

лай читтән килгән малай-кызларны шефлыкка ала. Бу махсус шулай эшләнелә: тәҗрибә алмашу үзенә күрә. Америка баласы – бездән, без алардан нәрсәгәдер өйрәнәбез.

2006 елда әти-әнием дә Канадага күченеп килде. «Гаиләне кушу» программасы буенча чакыртып алдым. (Кызганычка каршы, әти узган ел мәрхүм булды). Канадада миграция җиңелрәк башкарыла, читтән килүчеләр өчен шартлар да уңайлырак. Үзбәкстаннан «Грин-карта» программасы буенча ел саен 5 мең кеше Америкага килә. Мәсәлән, Нью-Йоркта бик күп ватандашларым яши. Тамырларыбыз – Татарстаннан, әби-бабаларыбыз Чирмешән районының Кармыш авылында яшәгән. Кулаклар дип, аларны туган җирләреннән куганнар. Әтиемә – Самарада, әниемә Ташкентта туу насыйп булган. Соңрак әтиемнең гаиләсе дә Ташкентка күченеп килгән. Шунда әни белән танышканнар, гаилә корганнар.

Торонтода якынча 500–600 татар яши. Үзебезнең «Берлек» исемле Татар иҗтимагый үзәгебез бар. Елына җиде-сигез тапкыр очрашабыз. Сабантуй, дини бәйрәмнәрне үткәрәбез. Иң актив кешеләр 150–200 гә җыеладыр, ә калганнары, нигездә, күзәтүче ролендә. Кичәләрне татар телендә алып барырга тырышабыз. Ни кызганыч, балалар, үсмерләрнең күбесе татарча да, русча да бик белми. Яшьтәшләре белән инглиз телендә аралашалар. Шуңа күрә бәйрәмнәрдә инглиз телендә дә сөйлибез. Әлбәттә, татар җырлары, уеннары, милли кием, ризык – берсе дә читтә калмый.

Торонтога яңа килгән татарларга хәлдән килгәнчә ярдәм итәбез: кайда арендага фатир арзанрак, нинди эшкә керергә. Берәүне дә игътибарсыз калдырмаска тырышабыз. Әлбәттә, башта авыррак була. Ләкин Америка, Канадага киткән кешенең кире туган якларына әйләнеп кайтканын белмим. Ничек тә җайлашалар. Сер түгел, Россия, Үзбәкстанга караганда анда тормыш күпкә җиңелрәк. Мисал өчен, анда иң аз түләнелә торган һөнәр ияләре (җыештыру, кафеларда эшләүче һ.б.) дә сәгатендә 11–12 доллар ала. Ә укытучы, табиблар, стажы, исеменә карап, 150–200 доллар акча эшли. Бер атна дәвамында сигез сәгать хезмәт куйса, иң аз түләнелә торган һөнәр иясе фатир өчен айлык аренда акчасын эшли, дигән сүз. Дәүләт тарафыннан бик күп социаль программалар каралган. Мисал өчен, даими теркәлгән урыны бар икән (Канада гражданины булмасаң да), кечкенә баласы булган гаиләләргә, дәүләт арендага алган фатирның 50–60 процентын үзе түли. Бу аз керемле гаиләләргә кагыла.

Кеше кайда уңайлырак, шунда гомер итәргә тиеш, дип саныйм. Казанга икенче тапкыр килүем, күпләр белән аралаштым. Кызганыч, минем кебек яшьләрнең күбесе татар телен белми. Без исә, чит илдә яшәп тә, ана телебезне саклыйбыз. Бу нисбәттән мин үземне чын патриот дип саныйм. Нинди генә телләрне өйрәнсәм дә, татар телендә сөйләшүдән туктамаячакмын!

Габдерәхим Мәгъфури, Иран, эшкуар:

– Казанга икенче тапкыр киләм. Бер ел элек без, Ираннан бер төркем делегат, Тукайның 130 еллыгына багышланган конференциягә чакырулы идек. Ә Казан белән дуслыгыбыз 2013 елда башланды: әдәбият һәм сәнгать елы уңаеннан ИЯЛИдә эшләүче бер төркем мөгаллим, әдипләр Төньяк Иранның Гөлестан шәһәренә килделәр. Казан кунаклары безнең гаиләдә булды. Шулвакыт без аларга җиде буын турындагы шәҗәрәне күрсәттек. Алтынчы буын бабам – Мөхәммәтшәриф Ютазы районының Бәйрәкә авылында туган. Егерме яшендә Бохарага укырга киткән. Үзбәкстанда укымышлы, дәрәҗәле кеше булып танылган. Кешеләргә дин гыйлеме өйрәткән, мәчетләр салдырган. Аның балалары исә Иранга күченгән. Бабайның туган җире – Бәйрәкә авылында булдык.

Татарлар тормышына килгәндә, милләттәшләребез Төньяк Иранның төрле шәһәрләре буенча таралган. Түбән Татар, Югары Татар исемле ике зур бистә бар. Күптән түгел Түбән Татар бистәсе шәһәр статусы алды. Нигездә, анда халык ана телен яхшы белә. Иранда татарлар шактый күп, тик аларның күбесе үзен төрекмән дип күрсәтә. «Төрекмәнләшү» чагыштырмача күптән түгел барлыкка килде.

Сәбәбе гади: Россиядә татарларның руслашуы кебек, катнаш никахлар, күпләрнең туган телендә сөйләшмәве… Иранда кешенең татар икәнен раслаучы күрсәткеч булып аш-су тора, аеруча авылларда. Анда халык һаман да татар күмәче пешерә.

Иран – мөселман республикасы. Аңлашылганча, анда шигыйлар күбрәк. Сөнниләр булып төрекмәннәр һәм татарлар тора. Ләкин безнең хокуклар тулысынча якланган. Ниндидер каршылыклар сизмибез. Үзебезнең мәчет, муллабыз, дигәндәй. Мөселман республикасы буларак, бездә күпчелек хатын-кызлар хиҗаптан йөри. Ул яктан Казан урамнарындагы ярымшәрә йөргән хатын-кызларны күргәч аптырадык. Шулай ук урамда хатын-кызларның күп булуы да гаҗәпкә калдырды. Алар кайчан гына ашарга пешерә, өйдәге эшләрне карый соң? Бездә, нигездә, хатын-кызлар урамга күбрәк ире белән чыга. Ә көндез аш булмасында, гаиләсенә ризык әзерли, балалар карый. Биредә шулай ук хәләл ризык белән дә проблемага юлыктык. Мисал өчен, без яшәгән «Гранд» кунакханәсендә хәләл меню юк. Ризык эзләп, шактый йөрергә туры килде.

Иран белән Россиягә кертелгән санкцияләр ике ил арасындагы мөнәсәбәтне ныгытты гына. Казанга килүем дә шуның белән бәйле: партнерлар табасы иде. Иран, сәүдә-икътисадый яктан караганда, бик отышлы төбәк: бездә ел әйләнәсе җиләк-җимеш, яшелчә үсә. Һәм алар барысы да экспортка чыгарыла. Шулай ук нефть өлкәсендә дә эшләргә була. Ике арадагы элемтәне ныгытсак, Татарстан, Иран өчен дә бик файдалы булыр, дип уйлыйм. Гомумән, татарлар бердәм, бер-беребезгә таяныч булып яшик.

Вәгыйзь Фәйзуллин, Красноярск краеның «Яр» Төбәкара татар милли-мәдәни автономия рәисе:

– Казанны беренче тапкыр күрүем 1997 елда булды. Шуннан бирле елга бер-ике тапкыр килергә тырышам. Казан – татар дөньясының башкаласы бит. Бөтендөнья татар конгрессында, ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы, ТР Мәдәният министрлыгында булам. Безгә яңалыклар, нindидер үзгәрешләрдән читтә калырга ярамый.

Красноярск краенда, рус, украиннардан соң, татарлар өченче урында тора. Барлыгы 36 мең татар яши. Безгә карата җирле халыкның да, җитәкчеләрнең дә хөрмәте бик зур. Бер генә мисал: губернаторыбыз Виктор Толоконский узган елны татар теле дәреслекләре өчен күпме кирәк, шуның кадәр акча бирде. Милли бәйрәмнәргә, башка чаралар өчен дә край бюджетыннан акча бүленә. Ә җирле халыкның татарларны хөрмәт итүенә бер күрсәткеч: 2015 елда узган Федераль Сабантуйга 45 мең кеше килгән иде. Алар көне буе татар җырын тыңлады, биюләрен карады, милли ярышларда катнашты. Ул көнне татар белән бер дә аралашмаган башка милләт кешесе дә, безне күреп, милли гореф-гадәтләребез турында ишетеп китте.

1997 елда Красноярск шәһәрендә «Яңарыш» исемле милли-мәдәни автономия төзегән идек. 2007 елда аны төбәкара итеп үзгәрттек. Шәһәрнеке элеккеге исемендә калды, ә яңа төбәкара автономиягә "Яр" исемен бирдек. Татар егет-кызлары крайда уздырылган һәр бәйрәмдә чыгыш ясый. Татар телле 15 иҗат коллективыбыз гына бар. Әлбәттә, башка юнәлештә дә эш алып барабыз. Мисал өчен, 2003 елда, иң беренчеләрдән булып, Красноярск белән Татарстан арасында хезмәттәшлек итү турында килешү төзедек. 2013 елда ул килешүне икенче кат расладык. Безнең инициатива белән 2002 елда Казан – Себер маршруты буенча туры поезд йөри башлады. Автономия биш кечкенә татар авылына һәйкәл ясап куйды. Анда клуб, мәктәп тә юк. Һәйкәл халыкка җыелырга урын булды. Мәктәп турында сүз чыккач, әйтим: төп фәннәр рус телендә алып барыла, ана телләрен факультатив рәвештә укыйлар. Балалар татарча яхшы сөйләшә дип әйтә алмыйм, төрлесе бар. Нигездә тел авылларда сакланып калган. Ата-аналары, әби-бабалары татарча сөйләшсә, бала да туган телен белә әле. Сөйләшмәсәләр дә, күпләр ана телен аңлый. Шуңа да яшьләрне күбрәк мәдәният, сәнгать аша тартырга тырышабыз.

Бүгенге көндә Красноярск краенда 33 татар авылы бар. Зурлыгы буенча төрле: 38 кеше яшәгәне дә, халык саны 300 гә җиткән авыллар да бар. Ни кызганыч, Татарстандагы проблема бездә дә барлыкка килде – татар авыллары үлеп бара. Сәбәбе: яшьләр калмый. Колхозлар таралгач, төпле эш урыннары кимеде. Тик мин гел әйтәм: «Иренмәгән кешегә авыл җирендә эш табып була». Үз эшеңне булдыр, мөмкинлекләр бар бит. Юк, безнең хәзер җиңел генә яшисе килә.

Без Татарстанга чын күңелдән рәхмәтлебез. Төрле чаралар үткәрә, грантлар бирә. Читтә яшәгән татарлар өчен бик кирәк ул: ярдәм кулы сузучылар бар икәнен беләсең, тоясың. Эшләр яңа планнарны тормышка ашырыр өчен канат куя. Шул ук вакытта җирле җитәкчеләргә бер киңәш-теләгем бар: әгәр чит төбәктән Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре исемен бирүне сорап хат килә икән, кире бормасыннар иде. Мисал өчен, бездә җирле ансамбльне бөтен крайга таныткан бик талантлы ханым бар. Аңа мактаулы исем бирүне сорап, ике тапкыр Казанга хат юлладык. Юк, әле бер документ дөрес түгел, диләр, әле икенче сәбәп табалар. Исем алган кешегә акча бирелми, матди якка бәйләнмәгән бит. Кешегә күңел сөенече, яңадан иҗат итәргә бер стимул булыр иде. Бигрәк тә – читтә яшәгән милләт вәкиленә.

PRESSA.RU

«АККОШ» КҮККӘ АШКЫНА

«Американың котын алган нәрсә». «Дөньядагы иң җитез бомбардировщик». «Бер залп белән Американың дистәләгән штатын җир белән тигезләргә сәләтле ракета ташу очкычы»... Болар барысы да «Аккош» дип исемләнгән Ту-160 стратегик бомбардировщигы хакында. Атом-төш кораллары кулланыну тыеп, ике арада тигезлекне тотып торган тиңдәшсез самолетның Казанда яңадан эшләнә башлавы, мөгаен, илебезнең оборона сәнәгатендә иң күләмле проекттыр.

Автор:
Әскәр Сабиров

Май аенда оборона министры Сергей Шойгу Федерация Советында узган «хөкүмәт сәгате»ндәге чыгышында анык срокларны атаган иде: яңартылган Ту-160 М2 самолетын С.П.Горбунов исемендәге Казан авиация заводында 2021 елдан соң серияле рәвештә эшләп чыгара башлаячаклар. «Берләштерелгән авиатөзелеш корпорациясе» башлыгы Юрий Слюсарь шул вакытларда тагын бер мөһим санны билгеләп куйды: илгә 30–50 Ту-160 М2 стратегик бомбардировщик кирәк булачак.

Әле совет заманында ук эшләнгән бер «Аккош» якынча 250 миллион долларга бәяләнә. Ләкин ул үз хакына тора – АКШның әлеге ракета ташучы самолет белән охшаш мәсьәләләрне күздә тотып эшләнгән B-1B очкычы – «Аккош»ның мескен күләгәсе кебек кенә. Хәзер күрше генә булган ил үз территориясендә калган Ту-160 самолетларыннан арынырга теләк белдергәч, һәрвакыт акча саный белгән америкалылар, самолетларны кискәләп тураклау өчен, һәрберсе өчен сөенә-сөенә берәр миллион бирергә карар кыла. Бәхеткә, Украинаның Прилуки аэродромындагы «йөз алтмышлылар»ның бөтенесен дә металл өеменә ташларга өлгермиләр – аларның бер өлеше Россиягә кайта.

Бүген илебезнең хәрби-космик гаскәрләрендә уналты Ту-160 үзенең сугышчан вазыйфасын үти. Машиналарның күбесе егерме биш яшьнең аръягында. Бу чик яшь түгел – аларга очасы да очасы әле. Кайберләре Казан авиазаводында яңартылып, яңа радиоэлектрон җиһазлар һәм һөҗүм өчен тагын да камилрәк кораллар белән тәэмин ителде. Кирәк икән – тавыштан тизрәк очып, дошманның һава һөҗүменнән саклану системасын үтеп чыга, югары төгәллек белән ата торган, атом-төш зарядлы канатлы ракеталарны ун-унике мең километр ераклыктагы очыртып җибәрү ноктасына китереп җиткерә, ә аннары, куелган максатка ирешкәч, кире базага кайта алалар.

«Аккош»лар – атом-төш коралын кулланыну тыеп-тигезләп торган бик куәтле һәм нәтиҗәле коралыбыз. Дөньяда вәзгыятьнең үзгәреп торуы, һәм бу үзгәрешләрнең яхшыга таба булмавы «аккош»ларга җирдә озак ял итеп ятарга ирек бирми – көн-төннәребез имин торсын өчен, алар тәүлек буе хәрби дежурда булырга тиеш. Һәм Россия чикләрендә генә түгел, ә планетабызның төрле почмакларында, дип саный оборона министры Сергей Шойгу. Моның өчен исә уналты «аккош» кына, әлбәттә, азрак.

КАНАТЛАРНЫ ҖӘЯР ЧАК

Биш елдан серияле рәвештә чыгарылачак ракета йөртүче очкычның прототибы күзгә күренерлек килеш-кыяфәт алды да инде. Гермокабиналы фюзеляж, канатлар, койрык өлеше – бормалы-сырмалы баскычлар һәм платформалар белән чормап алынган самолетны хәзер Казан авиазаводының җыюны төгәлләү цехында төзеп бетерәләр. Беренче карашка, серияле җитештерүгә егерме биш ел элек туктатылган «Аккош»тан һич аермасы юк кебек тоела.

Хәер, бу хис-тойгылар алдамый икән. Яңа Ту-160 М2 база модельдә булган планерны «мирас» итеп алган. Һәм бу юкка түгел. Оборона министры әйтүенчә, хәзер гамәлдә булган ракеталы очкычыбыз – «вакытны берничә дистә елдан узып киткән һәм әле бүген дә үзенә

Фото: uacrussia.ru, авиару.рф

Титанны электрон-нурлы ысул белән эретеп ябыштыру технологиясен кабат өйрәнү «Аккош»ларны яңадан җитештерә башлауны җайга салу юлында иң мөһим адымнарның берсе булды.

салынган конструктив мөмкинлекләрне тулы куәтенә файдаланмаган тиңдәшсез машина».

Кайчандыр ошбу очкычны җитештергән заводта мондый машинаны яңадан җыя башлаудан да гадирәк, җиңелрәк нәрсә юк кебек, беренче карашка. Чынлыкта исә чирек гасыр дәвамында – нәкъ шуның кадәр вакыт элегрәк Борис Николаевич тавыштан тизрәк оча торган, дөньядагы иң яхшы бомбардировщиклар безгә башка кирәк түгел дигән фикерне алга сөргән – тиңдәше булмаган технологияләр онытылган. Җиһазларның күбесе ватылган, ә ярдәмче предприятиеләрнең бер өлеше безгә дус булмаган илләр территориясендә калган яки бөтенләй таралган-югалган. Һәм тагын да авыррагы – технологияләрне белгән кешеләр киткән.

Моннан өч дистә еллар элек (Казанда эшләнгән тәүге Ту-160 хәрбиләр кулына 1987 елда тапшырыла. – Ред. искәрмәсе) бик оста башкарган нәрсәләрне хәтта стратегик бомбардировщиклар җитештерүдә шулкадәр тәҗрибә туплаган казанлыларга да яңабаштан өйрәнергә туры килә. Әлбәттә инде, тагын да югарырак, сыйфатлырак дәрәҗәдә, чөнки узган вакыт эчендә күп кенә технологияләр алга атлады, димәк, искене сукырларча күчереп ясауның мәгънәсе юк.

Онытылган, югалган эш – титанны электрон-нурлы ысул белән эретеп ябыштыру технологиясен кабат өйрәнү «Аккош»ларны яңадан җитештерә башлауны җайга салу юлында иң мөһим адымнарның берсе булды. Бу технологиядән башка самолетның планерын җыеп булмый диярлек, чөнки ул 40 процент чамасы титаннан тора. Әлеге эшнең катлаулылыгын күзаллау өчен бер факт китерү дә җитә: бу процессны яңадан кайтару һәм камилләштерүдә казанлыларга берьюлы дүрт зур фәнни һәм җитештерү үзәге – Бөтенроссия авиация материаллары институты (ВИАМ), Авиация технологияләре илкүләм институты (НИАТ), Ижевскидан НТИ-Прогресс һәм Пензадан «Электромеханика» булышлык күрсәтте. Мәсьәләне искиткеч яхшы чиштек. Апрельдә Россиянең вице-премьеры Дмитрий Рогозин предприятиегә килеп киткәч, Твиттердагы сәхифәсендә: «С.П.Горбунов исемендәге Казан авиазаводында титанны электрон-нурлы ысул белән эретеп ябыштыру эше рекордлы кыска срокта яңадан гамәлгә куелган. Яңа буын «Аккош»ларны җитештерүгә әзерлек бара», – дип язды.

ЧИРЕК ГАСЫР БУЕ «КӨТЕЛГӘН ИСЕМЛЕКТӘ»

Тәүге Ту-160 М2 очкычын апрель аенда эшли башладылар, ә июльнең беренче яртысында самолетның фюзеляжы шассига утыртылып, җыюны төгәлләү цехына тарттырып куелган иде. Шундый гаҗәп кыска сроклар эшнең тәүлек әйләнә алып барылуы белән генә түгел, ә дистәләгән коллектив тырышлыгы нәтиҗәсендә технологик процессларның планлаштырылганнан да иртәрәк кайтарылуы белән аңлатыла. Иң мөһиме, «Аккош»ны җыю эшен буш урында башламадылар – бомбардировщикның предприятиедә 25 ел сакланган ике өлешенең берсен файдаландылар. Федераль үзәк 90 нчы еллар башында сепаратизмда гаепләргә яраткан Татарстан хөкүмәте ясалып бетмәгән хәлдә дә ил өчен стратегик әһәмияткә ия машиналарны аяк терәп саклап кала алган бердәнбер көч булып чыкты. Югыйсә, бу самолет өлешләрен металлоломга кисеп вакларга җыенган булалар (соңрак әлеге ике өлешне файдаланып, казанлылар 2002 һәм 2008 елларда оборона министрлыгына ике яңа Ту-160 тапшырды). Әлеге нигез өлешләрне сакламаган очракта, беренче самолетны әле тагын берничә ел көтәргә туры киләчәк иде.

Тәүге бомбардировщикны җыюны төгәлләү цехына тапшыруны Казан авиация заводы газетасы тарихи вакыйга дип атады. Бәлки, бу ул кадәр арттыру да түгелдер. «Безнең өчен аеруча мөһим машина, – дип аңлатып узды директорның беренче урынбасары Зөфәр Миргалимов. – Киләчәктә заводның нигезен тәшкил итәчәк коллектив оештырылды. Әлбәттә, абынган-сөртенгән урыннар күп булды. Тик иң мөһиме – ахыргы нәтиҗә: Ту-160 очкычының төзелеше турында теориядә генә белгән яшь егетләр бу самолетны төзергә өйрәнде һәм хәзер осталыкларын шомарта бара...

Инде октябрь аенда ракеталар йөртүче беренче Ту-160 М2 очкычы җыю цехыннан чыгып, очу-сынау станциясенә юл тотачак. Уңышмы? Бу әле башы гына.

РАКЕТАДАН САКЛАНУ СИСТЕМАСЫ АНЫҢ ӨЧЕН КИРТӘ ТҮГЕЛ

Вакытны берничә дистә елга узып алга киткән машина да аны туктатырга сәләтле түгел. «Аккош»ның искиткеч алдынгы мөмкинлекләрен һичкем кире какмый, фәкать хәзер урамда XXI гасыр, димәк, стратегик бомбардировщик башкарырга тиешле мәсьәләләр берничә тапкыр катлауланырга өлгерде. Ту-160 очкычын яңадан кире кайтару мөмкинлеге турында сөйләшүләр барган гына

PRESSA.RU

раль директоры урынбасары Гиви Джанджгава әйтүенчә, «яңа Ту-160 безгә хисаплау системасы ягыннан да, навигация һәм төгәллек ягыннан да алга барырга мөмкинлек бирәчәк».

«Радиоэлектрон технологияләр концерны» (КРЭТ) самолетның яңа борт системаларын, радиоэлектрон сугыш комплексын, шулай ук кораллар белән идарә итү һәм навигация системаларын ясау белән шөгыльләнә. Әлеге эшләнмәләр турында мәгълүматлар аларның нигездән яңа булуы һәм әһәмиятлелеге турында фикер йөртергә мөмкинлек бирә. Мәсәлән, Ту-160 М2 самолетында интеграл-модульле авионика принцибын куллану ниятләнгәнлеге билгеле. Бу принцип борт электроникасы компонентларының кирәк вакытта бер-берсен алыштыра һәм яңадан торгыза алуын күздә тота. Аерым алганда, электрон сугыш комплексы, нәрсәдер сафтан чыкканда, үз өстенә башка идарә системасы функцияләрен алырга сәләтле булачак. Ә махсус инерцияле навигация системасы иярчен сигналларыннан башка да курс билгеләргә мөмкинлек тудырачак...

чорда, илебез авиациясенең билгеле, абруйлы шәхесе, СССРның атказанган очучысы Олег Смирнов самолетның, ким дигәндә, камилләштерү таләп иткән системаларын телгә алды. «Беренче чиратта, бу – авионика: навигация җиһазлары, приборлар, төзәгечләр, ракета төзәү системалары... Икенче проблема – двигательләр. Сарыф ителә торган авиация керосины күләмен киметү өчен, аларны һәрдаим үзгәртергә, яхшыртырга кирәк...»

Яңартылган бомбардировщикның конструкторлары алдына хәрбиләр нинди мәсьәләләр куйганын, мәгълүм сәбәпләр аркасында, бары тик фаразларга гына кала. Әмма хәтта ачык чыганаклардан алынган аз-маз мәгълүмат та заказ бирүченең бик җитди таләп куйганын раслый: Ту-160 М2 үзенең әүвәлге агай-энесеннән ераграк оча, күктә озаграк тора алырга, экономиялерәк булырга, куәтлерәк корал ташырга һәм дошманның ракетадан саклану системаларыннан шактый ераклыкта вакытта да ракеталар белән югары төгәллектәге һөҗүм ясарга сәләтле булырга тиеш.

Башкача әйткәндә, әүвәлге буын «Аккош»лар белән чагыштырганда, тагын да камилрәк, тагын да явызрак, куәтлерәк машина турында сүз бара. Тышкы охшашлык, мөгаен, аларның туганлыгын раслаган бердәнбер үзенчәлектер. Моны оборона-сәнәгать комплексына караган бер чыганак та раслады. Аның сүзләрен ТАСС китерде: «Яңарту нәтиҗәсендә Ту-160 М2 самолетында база модельдән хәзер дә барлык таләпләргә җавап бирә торган планер гына кала. Самолетның эчке өлеше исә, шул исәптән авионика, радиоэлектрон җиһазлар, очучылар кабинасы, элемтә, идарә чаралары, бер төркем кораллар системасы яңаларга алыштырылачак».

Нәтиҗәдә ни килеп чыгар? Моңа анык җавапны дүрт елдан соң әйтеп булачак, чөнки күп кенә системалар параллель рәвештә – самолетны төзү барышында эшләнә генә. Фәкать шунысы мәгълүм: самолет, әйтик, югары төгәллеккә ия яңа канатлы ракеталар белән җиһазландырылачак. Аларның очыш ераклыгы бүгенге Ту-160 арсеналындагылардан ике тапкыр зуррак. Бу исә хәлиткеч һөҗүм ясау өчен «аккош»ларга һәрвакыт дошман чигенә үк якынаерга туры да килмәячәк дигән сүз, чөнки үз территорияңнән дә ракета очырырга мөмкин булачак. Сүз хәзер эшләнә торган Х-БД канатлы ракеталары турында барырга тиеш. Белгечләр бәяләмәсе буенча, бу канатлы «аждаһалар» гамәлдәге һәм хәтта киләчәктә эшләнәчәк комплекслар – һава һөҗүменнән һәм ракета һөҗүменнән саклану системаларын үтеп чыгарга сәләтле булачак.

Сүз уңаеннан, күптән түгел оборона министры Сергей Шойгу да раслады: бу очкыч ракета һөҗүменнән саклану системаларын узып һөҗүм ясарга сәләтле булырга тиеш. Аның урынбасары Юрий Борисов яңа машинаның хәрби нәтиҗәлелеге 1987 елгы Ту-160 белән чагыштырганда 2,5 тапкыр артачагын сөйләде. «Радиоэлектрон технологияләр концерны» генеральный директоры урынбасары...

ОБОРОНА – МИНИСТР КОНТРОЛЕНДӘ

План буенча, Ту-160М2 тәүге очышына 2018 елда күтәреләчәк – Самарадагы «Кузнецов» фәнни-җитештерү берләшмәсендә яңартылган «Аккош» өчен НК-32-02 двигательләрен эшләп чыгару җайга салынган инде. Юрий Борисов хәбәр иткәнчә, яңартылган двигательләрнең ресурслары зуррак, алар экономиялерәк һәм очыш ераклыгын, ким дигәндә, бер мең километрга арттырырга мөмкинлек бирәчәк. Яңа самолет күзәтү системалары өчен тагын да «күренмәсрәк» булачак, аның аэродинамикасы яхшырачак.

Ләкин яңа ракеталар йөртүче очкычта куллану ниятләнгән күп нәрсә әле эшләнә генә. Әйтик, КРЭТ үзенә йөкләнгән өлешне 2020 елга гына тулысынча башкарып чыгарга планлаштыра. Димәк, самолетның яңа эчке «әгъзалары», корал системалары серияле җитештерү башланыр көнгә кадәр бер-бер артлы килә торачак, сынау узачак һәм бортка урнаштырылачак. Графиктан тайпылышлар мөмкин түгел диярлек. Әле гыйнвар аенда ук, Казанда авиация заводында чакта, Сергей Шойгу

Фото: Александр Ефремов

кисәтеп куйды: Ту-160 М2 төзелеше аның аерым контролендә тора, эш этаплары турында аңа атна саен хисап тотарга тиешләр.

Кайчандыр Ту-160 очкычын бөтен ил ясады. Бүген исә бөтен ил диярлек Казанда «Аккош» самолетын җитештерүне яңадан торгызу проектында катнаша. Стратегик бомбардировщикның цифрлы моделен ясауда Россиянең иң алдынгы авиатөзелеш ширкәтләрендәге зур-зур конструкторлык бюроларыннан барысы да диярлек эшкә җигелде. Әлеге куәтле машинаны төзүдә Татарстан авиатөзелеш осталары белән бергә Самара һәм Пермь, Воронеж һәм Мәскәү, Иркутск һәм Пенза предприятиеләре катнаша… «Берләштерелгән авиатөзелеш корпорациясе» башлыгы Юрий Слюсарь сүзләренчә, «Эшкә җигелгән технологияләр, кооперация, интеллектуаль ресурслар күзлегеннән караганда, Ту-160М2 – Россия авиасәнәгатенең Советлар чорыннан соңгы иң катлаулы проекты».

Беренче прототипны ясау белән бергә предприятиедә җитди модернизация тормышка ашырыла. Аэродром комплексы һәм конструкторлык үзәге яңартылды инде, якын елларда барлык җиһазларның якынча кырык проценты алыштырылачак. «Берләштерелгән авиатөзелеш корпорациясе» вәкилләре раслаганча, хәзерге белән чагыштырырлык күләмле инвестицияләр завод тарихында дистәләрчә еллар элек – совет чорында гына булган. 2020 елга кадәр яңартуга тотылачак чыгымнар берничә дистә миллиард сум тәшкил итәчәк. Нәтиҗәдә, без бөтенләй башка технологик югарылыкка күтәрелгән предприятиеле булабыз. Хәер, аның каршына куелачак максат-бурычлар да башка…

Кайчандыр Ту-160 очкычын бөтен ил ясады. Бүген исә бөтен ил диярлек Казанда «Аккош» самолетын җитештерүне яңадан торгызу проектында катнаша.

– КАЗ бездә стратегик авиациянең гамәлдәге һәм киләчәктәге үзәге буларак расланган. Җитештерүгә әзерлек барышында без тормышка ашырган инвестицияләр яңа модельнең нигезенә салыначак. Әлеге модель еракка оча торган авиациянең тулы бер комплексы өчен киләчәкне күзаллап эшләнә, – дип хәбәр итте МАКС-2017 авиасалоны кысаларында күптән түгел уздырылган матбугат очрашуында Юрий Слюсарь.

Бераз аңлатма бирик. Еракка оча торган авиациянең перспектив комплексы (ПАК ДА) дип исемләнгән комплекс турында сүз бара монда. Ул «Аккош»ка алмашка киләчәк. Тагын да куркынычрак коралга әйләнергә тиешле ПАК ДА хәзер конструкторлар тарафыннан эшләнеп ята, машиналарны җыю өчен җитештерү мәйданнары инде әзерләнә дә. Казанның авиатөзелеш белгечләре өчен бу проект – чираттагы этап. Бәлки, ПАК ДА 2025–2026 елларда тәүге очышына күтәрелер дә, тик шунысы игътибарга лаек: аны эшләгәндә Ту-160 М2 самолетында сыналган кайбер ноу-хауларны кулланырга тәкъдим ителә.

Стратегик ракеталар йөртүче очкычларны яңартылган формада серияле җитештерүне җайга салу бүгенге көндә илебездәге оборона комплексының иң кыйммәтле проектларыннан берсе буларак карала. Кайчак бу чыгымнарны «Борей» кебек су асты көймәләре ясауга яки… Сочи Олимпиадасына тотылган акчалар белән чагыштырырга мөмкин дип тә расларга тырышалар. Ләкин акыл ияләре бу мәсьәләдә инде күптән үз сүзен әйткән: «чит армияне ашатырга калганчы, үзеңнекенә акча тотуың һәрвакыт яхшырак».

Фото: uacrussia.ru, авиару.рф

PRESSA.RU

«ЭЛЕКТРОПРИБОР» – 100 ЕЛ АВИАЦИЯДӘ

Казанның «Электроприбор» заводына быел 100 ел тула. Авиация приборлары ясау буенча беренче үзебезнең ил предприятиесенә Мәскәүдә нигез салынган була. Ул башта «Авиаприбор» дип атап йөртелә.

Александр Фридман (1883-1925) – заводның беренче директоры, профессор, 1нче номерлы Ленин премиясе лауреаты (үлгәннән соң бүләкләнә).

Авиаприборлар ясый торган үз заводыбызны булдыру идеясен заманында математика, динамик метеорология һәм атмосфера физикасы өлкәсендәге белгеч – Россия галиме Александр Александрович Фридман беренчеләрдән булып күтәреп чыга. Ул авиациягә кирәкле аэронавигация приборларының фәнни-техник тасвирламасын әзерли, прибор төзү заводының проектын эшли, һәм бу оешманы җитәкләүне дә нәкъ менә аның үзенә йөклиләр.

Предприятие әле яңа аякка басып кына килгән чакта кыенлыклар шактый күп була, әлбәттә. Илдә сугыш бара, 1917 ел – ике инкыйлаб шаулап узган ел. Элеккеге тормыш җимерелгән, фәкыйрьлек, ачлык хөкем сөрә, ә яңа оешкан заводта җиһазлар җитми, квалификацияле кадрлар турында әйтеп тә торасы юк. Әмма предприятие коллективы, барлык авырлыкларны кичеп, 1924 елга инде үзләре ясаган приборларны серияләп чыгара башлый. Бу – барометрлы биеклек үлчәгечләре, тизлек күрсәткечләре, термометрлар, тахометрлар, тайпылыш билгеләгечләр, авиадвигательләрдәге май белән бензинның басымын үлчәү өчен манометрлар.

1937 елда заводны Наркоматның оборона сәнәгате предприятиеләреннән торган төп төркемнә кертәләр һәм дәүләт реестры буенча 230 нчы номер белән тамгалыйлар. Предприятие приборлар чыгару белән бергәттән, авиация двигательләренең эш режимын контрольдә тоту системаларын да әзерли башлый.

Бөек Ватан сугышы башлангач, заводны Казанга эвакуациялиләр. Биредә, Ветеринария институты биналарына килеп урнашуга, ул приборлар чыгару эшен дәвам итә. Өстәвенә, фронт авиациясе өчен генә дә түгел, ә танклар белән суднолар производствосы өчен дә. Сугыш елларында заводның хәрби җитештерү күләме 3,5 тапкырга арта.

Сугыштан соң, реактив авиация пәйда булгач, завод илдә беренчеләрдән булып Ту-4 бомбардировщигы өчен автопилот узләштерә. Алга таба автопилотлар белән МиГ истребительләре һәм бомбардировщиклары өчен автомат идарә системасын да җитештерә.

50нче елларда, илдә ракета техникасы үсеше башлангач, оешма «һава-һава» ракеталарының радиолокацион антенналары өчен махсус гироскопияле стабилизаторлар эшләп чыгара башлый. Шулай ук ул хәзергәчә төрле класска караган идарә ителә торган ракеталарны табуның югары ноктaлы (дәрәҗәдәге) системасын башкару һәм җитештерү белән шөгыльләнә.

Заводның гаять катлаулы гироплатформалар җитештерү тәҗрибәсе космик программаларны тормышка ашырганда да бик файдалы булды. Оешмага космик корабларның җир шары янындагы орбитада автоматик рәвештә тоташуын тәэмин итүче системага караган антеннаның гиростабилизацияле платформасын әзерләү бурычы йөкләнде. 1967 елда, дөньядагы беренче тоташу вакытында да, аннан соңгы 100 тоташуда да заводның эшләнмәләре кулланылды.

Завод эшләп чыгарган гиростабилизатор урнаштырылган Ил-76 МД-М яңарыш кичергән транспорт самолеты (фотода кызыл белән билгеләнгән).

Завод җитәкчелеге механик производствода. Сулдан уңга: сыйфат буенча генераль директор урынбасары С.Плаксин, техник тәэмин ителеш буенча генераль директор урынбасары П.Инцин, җитештерү буенча директор В.Желтов, механик производство җитәкчесе И.Хаҗиморатов, генераль директор П.Шацких. 2017 елның апрель ае.

Реклама

Завод эшчәнлегендәге иң төп юнәлешләрнең берсе – датчик тематикасы, үлчәнешне, двигатель әйләнешләрен, янгын хакындагы сигнализация системасын контрольдә тоту һәм җайга салу. Болар, 70 нче елларда старт алып, хәзер дә үсешен дәвам итә.

90 нчы еллар кризисын җиңеп, завод янә бер кат үзенең тормышка яраклы булуын искәртте: кадрларны да саклап кала алды, җитештерүнең авиацион юнәлешен дә.

Яңа гасырда, авиация өлкәсендәге активлыкны күреп, заводта җитди үзгәрешләр кертелде. Механика-эшкәртү һәм җыю производствосын булдыру һәм яңарту буенча гаять зур эш эшләнә хәзер. Инновацияле эшкәртү үзәкләре линейкасы сатып алына һәм кулланышка кертелде, җыю производствосы заманча слесарь-монтаж җиһазлары һәм пайкалау станцияләре белән комплектланды, сынау базасы яхшыртылды – электрон платаларның сыйфатын контрольдә тотучы оптик станциягә ия булдылар. Производство гына үзгәртеп корылып калмыйча, заводның гомумструктурасы ук баштанаяк үзгәртелде. 2011 елда конструкторлык һәм технология бүлекләре базасында инженерлык үзәге оешу IT-технологияләргә нигезләнгән продукция җитештерү һәм эшләп чыгаруның бердәм комплексын күздә тоткан йомгаклау этабы булды.

Соңгы елларда заводта төп ике юнәлеш буенча эш алып барыла: гиростабилизацияле платформалар һәм әйләнү тизлеге белән температураны тикшерүче датчиклар. Предприятие авиация һәм ракета техникасы өчен күзәтү системалары сферасына актив юл яра. Алар арасында хәрби-транспорт самолетлар өчен эшләнмәләр бар, шул исәптән – Ил-76 МД-90 А, Ил-76 Мд-М һәм бензин белән тәэмин итүче Ил-78 М-90 А кебек яңарыш кичергән самолетлар өчен дә. Әлеге адымнарның барысы да икътисад ягыннан сыйфатны яхшырту, хезмәт ягыннан җитештерүчәнлекне көчәйтү, җитештерүнең рентабельлеген үстерү кебек уңай күрсәткечләргә ирешергә мөмкинлек бирде. Эшчеләр өчен эш урынындагы шартларны уңайлырак итү, эш хакы һәм соцпакетны җайга салу да – үзе бер уңыш. Соңгы ун ел эчендә предприятиедә сатудан алынган керем – 50 тапкырга, производство күләме – 5 тапкырга, ә айлык уртача хезмәт хакы исә 5 тапкырдан да күбрәккә артты.

Техник үсеш белән беррәттән яңа производство корпуслары сафка бастырылды, социаль сфера үсеш кичерде. 90 нчы елларда социаль сфера, ял базасы белән балалар сәламәтләндерү лагерен исәпкә алмаганда, менә дигән хәлдә шәһәргә тапшырылды. Бүген дә заводта коллектив килешү, махсус программалар кысаларында эзлекле социаль сәясәт алып барыла. Табиблар өчен здравпункт эшли һәм үстерелә.

2004 елда завод акционерлашты, 2005 елда «Ак Барс» Холдинг компаниясе» АҖ компанияләр төркеменә керде.

100 еллык тарихының инде менә 76 сы дәвамында завод Татарстанда эшли һәм шәһәр белән республиканың иҗтимагый тормышында актив катнаша. Хәйрия һәм химаячелек белән шөгыльләнә. Заводның керемнәре спортны үстерүгә, мәдәни һәйкәлләрне саклауга һәм торгызуга, храмнар, мәчетләр төзүгә, балалар хәйрия фондларына акча күчерүгә, шулай ук мәктәпләр белән югары уку йортларына шефлык итүгә, ярдәм күрсәтүгә тотыла. Соңгы биш елда гына да бу максаттан 16,5 млн сум файдаланылган.

Дәверләр, илдәге системалар алышынып тора, әмма завод эшләп чыгарган продукция элеккечә ихтыяҗ тудыра. Үзенең юбилей елында «Электроприбор» Россия авиакосмос юнәлешендәге әйдәп баручы предприятие булып калуын дәвам итә. Ул үзен Россиянең эчке базарында гына түгел, ә тышкы базарында да ышанычлы партнер буларак күрсәтте.

Завод коллективының эшчәнлеге күпсанлы бүләкләр белән билгеләп үтелгән: Татарстан Республикасы Президентының республиканың иминлеген тәэмин итү хакына нәтиҗәле эшчәнлек алып барулары һәм Россия сәнәгате үсешенә керткән лаеклы өлешләре өчен Рәхмәт хаты, Россиянең иң яхшы экспортеры дигән диплом, сыйфат, коллективның социаль үсеше, экология һәм хәйрия өлкәсендәге эшчәнлекләре өчен бирелгән дипломнар. Предприятиенең 2000 нән артык хезмәткәре Татарстан һәм Россиянең, шулай ук СССРның орденнары һәм медальләре иясе.

Завод җитештергән продукция барлык эре Россия һәм халыкара авиация күргәзмәләрендә уңыш казана. Татарстан Республикасы Премьер-министры – Сәнәгать һәм сәүдә министры А.Кәримов һәм заводның генераль директоры П.Шацких 2017 елның 13 июлендә Мәскәүдә үткән МАКС-2017 күргәзмәсе вакытында стенд янында.

Завод коллективы эшчәнлеген шулай югары бәяләү мондагы хезмәткәрләргә киләчәккә ышаныч белән карарга мөмкинлек бирә, аларны яңа хезмәт нәтиҗәләренә рухландыра.

PRESSA.RU

ЧҮПМЕ? ЭНЕРГИЯМЕ?

2021 елда Казанда заманча дөнья технологияләре буенча төзелгән чүп яндыру заводын сафка бастырырга җыеналар. Татарстан башкаласы илдә каты коммуналь калдыкларны бөтенләй күмәчәк беренче шәһәр булачак. Сезне шул проект белән таныштырабыз!

ЧИСТА КАЗАН

Копенгагенда Хөкүмәт йортыннан якынча өч чакрым ераклыкта сез архитектур футуризмның затлы образын күрә аласыз. Биниһая зур бина, ә аның түбәсендә… 30 мең квадрат метрдан артыграк мәйданда тау чаңгысы юлы салынган! Төзелеп килүче каты коммуналь калдыкларны термик эшкәртү заводының тышкы күренеше нәкъ менә шундый. Кыйммәтле булуына карамастан, Копенгаген тормышка ашыру өчен инде сыналган проектны сайлаган. Казанда да шундый ук технология кулланылачак. Проект авторлары булачак завод түбәсендә чаңгы тавы төзергә вәгъдә итми итүен, әмма бу предприятие ТР башкаласында экологик проблеманы нәтиҗәле хәл итәргә мөмкинлек бирәчәк, дип ышандыралар.

Чүп яндыру заводларын төзү «Чиста ил» өстенлекле милли проект кысаларында каралган. 2021–2022 елларда барлыгы биш заводны сафка бастыру күздә тотыла: дүртесен Мәскәүдә һәм Мәскәү өлкәсендә, берсен – Татарстан башкаласында. Әлеге дәүләт заказына конкурста «Ростех» дәүләт корпорациясенең бүлендек предприятиесе – «РТ-Инвест» җиңеп чыкты. Проектның технологик, һәм шулай ук инвестицион партнёры Hitachi Zosen Inova япон-швейцария компаниясе булачак, ул инде Азия, Европа һәм Төньяк Америка илләрендә 500дән артык шундый завод төзегән.

Копенгаген



Вена

Автор:
Катерина Котова

– Безнең белгечләр дөньядагы мөмкин булган барлык технологияләрне өйрәнделәр һәм шуннан соң гына калдыкларны Даниядәгечә яндыру ысулы ярдәмендә термик эшкәртүне энергиягә әверелдерү технологиясен карарга тәкъдим иттеләр, – дип сөйли «РТ-Инвест» компаниясенең генераль директоры Андрей Шипелов. – Безнең алга төп критерийлар итеп экология, нәтиҗәлелек, куркынычсызлык һәм файдалы продукт – энергия алу мөмкинлеге куелды. Бу проект Татарстан башкаласына, Россиядә беренче буларак, коммуналь калдыкларны бөтенләй күмәчәк шәһәр булу мөмкинлеге бирәчәк. Казанда – чүпне аерым җыю һәм сортларга аерудан башлап, икенчел җитештерү һәм энергия өчен эшкәртүгә кадәр – калдыклар белән эшләүнең тулы циклы кертеләчәк.

ЧҮПНЕ ЮК ИТӘРГӘ!

Бүгенге көндә Казанда чүп мәсьәләсе, Россия мегаполисларының күпчелегендәге кебек, утырып еларлык. 600 мең тонна – шәһәрдә ел саен шуның кадәр каты коммуналь калдыклар барлыкка килә. Идеалда аның 50 процент тирәсе кабат эшкәртелергә һәм хуҗалык әйләнешенә кертелергә, тагын шуңа якын күләмдәгесе – термик зарарсызландыруга озатылып, аннан җылылык һәм электр энергиясе алынырга тиеш. Һәм бары тик 1 процентын гына полигоннарда күмү каралган. Чынлыкта исә чүпнең 95 проценты полигонга озатыла.

– Кызганыч, әйләнә-тирә мохитне инженерлык схемаларындагы дәрәҗәсе күп муниципаль полигоннарда бик түбән, – дип сөйли Рөстәм Богданов, ТР Төзелеш, архитектура һәм ТКХ министрлыгының калдыклар белән эшләү бүлеге җитәкчесе. – Күп очракта анда туфракны һәм грунт суларын пычранудан саклаучы гидроизоляция экраны куелмаган, кергәндә үлчәү һәм радиация контроле юк, чүпне беренчел сортларга аеру да юк… Муниципалитетларның күпчелеге, таратыр алдыннан чүпне ваклап, җиде тапкыр тыгызларга мөмкинлек бирүче кыйммәтле җиһазларны сатып ала алмый һәм, димәк, бүленгән урыннарны куллану вакытын да озайта алмый. Чүп өемнәреннән таралган газларны җыю система-

Люцерн

PRESSA.RU

Казандагы заводның тышкы күренеше турында инвестор әлегә әйтә алмый – соңгы карар кабул ителмәгән. Фотода Россия заводларының беренчел проекты.

сы булмау мондый полигоннарда янгын чыгу куркынычын арттыра – чөнки ватык пыяла кисәгенә төшкән кояш нуры да очкын кабынып китүгә сәбәпче булырга мөмкин. Ә янгын вакытында калдыклардан һавага аерым агулы матдәләр – диоксиннар һәм фураннар бүленеп чыга.

Казанда әле күптән түгел генә каты көнкүреш калдыклары өчен яңа полигон ачылды. «Восточный» әйләнә-тирә мохитне саклауның барлык таләпләренә туры килә. Ул рекультивация ясалырга тиешле «данлыклы» Самосырово чүплеген алыштыруны күздә тотып эшләнгән. Полигонны эшләтүнең вакыт ресурсы ун елга исәпләнгән, әмма бу чүп яндыру заводы ачылуга каршылык тудырмый, чөнки каты көнкүреш калдыклары арасында янмый торганнары да бар бит. Мәсәлән, иске сантехника, плитка, кирпеч ватыклары...

Сүз уңаеннан, шәһәрдә «чүп революциясе» башланды инде. Якын арада монда калдыкларны дуаль җыю системасы кертеләчәк, ә бит органик чүп һәм шул ук кәгазь аерым җыелмаса, чүп катнашмасы икенчел эшкәртү өчен яраксызга әверелә диярлек.

Гади генә итеп әйткәндә, һәр контейнер мәйданында калдыклар хәзерге кебек бер контейнерга түгел, ә икегә җыелачак. Азык калдыкларыннан шәһәр территорияләрен яхшырту һәм ярлыланган җирләрне баету өчен биокомпост әзерләргә мөмкин булачак. Кәгазь, пластик, пыяла ватыгы, алюминий банкалар кебек утиль компонентлары икенчел эшкәртүгә озатылачак.

– Безнең компания һәрьяклап чүпне аерым җыю, аны сортларга аеру һәм икенчел эшкәртүне хуплаячак, – дип вәгъдә итә Андрей Шипелов. Шул ук вакытта ул, дөнья тәҗрибәсенә караганда, амбициоз нәтиҗәләргә ирешү өчен бер дистә ел гына җитмәячәген дә белдерә.

Республикада бу турыда бәхәсләшмиләр дә. Татарстанда контейнер мәйданнарының 90 проценты 2025 елга чүпне аерым җыюга көйләнергә тиеш дип фаразлана. Абсолют нәтиҗәгә тагын ун елдан соң гына ирешеләчәк.

– Завод сафка бастырылган вакытка чүпне аерым җыю системасын тулысынча тормышка ашырырга без, әлбәттә, өлгермәячәкбез, – ди Рөстәм Богданов. – Әйе, «чүп революциясе» бездә инде старт алды, әмма, әйдәгез, шунысын да таныйк: бик түбән позицияләрдән старт алды ул. Һәм туры, һәм күчерелмә мәгънәдә безгә бик күп «чүп аралыйсы» бар әле. Һәм иң мөһиме – калдыкларга караш культурасы безнең җәмгыятьтә әлегә тәрбияләнмәгән. Бу юлда бик күп хаталар булыр, мөгаен.

НИЧЕК ЭШЛӘЯЧӘК

Шулай итеп, 2021 елга күчеп карыйк. Бу вакытка Татарстанда чүпне сортларга аеру комплекслары сафка бастырылачак. Кызганыч, чүпне дуаль җыю контейнерга куркынычлы компонентлар яисә икенчел эшкәртү өчен чимал кермәячәгенә ышаныч бирми. Сортларга ахыргы аерудан соң, чүп, калдыклар заводка озатыла. Алар авырлык һәм радиация контроле үткәннән соң гына кабул итү бункерына бушатыла.

Заводның «йөрәге» – хәрәкәтле рәшәткә. Сүз уңаеннан, соңгы 10 елда төзелгән калдыклардан энергия эшләп чыгаручы предприятиеләрнең 90 процент тирәсе нәкъ менә шул технологияне куллана. Яну зонасындагы максималь температура Цельсий буенча 1260 градуска җитә. Әһәмиятле деталь: януның тигез процессын тәэмин итүче технология янып бетмәүгә юл калдырмый – бу заводның экологик куркынычсызлык буенча төп позицияләреннән берсе булып тора.

Монда Германиянең Әйләнә-тирә мохитне саклау буенча федераль министрлыгы 2005 елда әзерләгән коммюникены искә төшерү урынлы булыр. Исегезгә төшерик, ул чакта аңа Яшелләр партиясе вәкиле Юргин Триттин җитәкчелек итә иде. «Калдыкларны яндыру куркыныч тудырамы? Хушыгыз, диоксинлы чыгарылмалар» – Рөстәм Богданов сылтама итеп китергән документның исеме шундый. Чүп яндыру заводлары һавага диоксин, тузан, авыр металлар чыгару ягыннан караганда, куркыныч тудырмыйлар, – диелә анда. Хәтта соңгы 20 елда аларның егәрлеге ике тапкыр арткан булса да. Әгәр 1990 елда Германиядә һавага барлык диоксин чыгармаларының өчтән бере чүп яндыру заводларына туры килгән булса, ун елдан соң бу өлеш бер проценттан да кимрәк санны тәшкил иткән.

– Галимнәр, ниһаять, органиканы хлорлы кушылмалар янында яндырганда барлыкка килә торган диоксиннардан әйләнә-тирә мо-

хитне ничек араларга кирәклеген аңладылар, – дип сөйли Рөстәм Богданов. – Шунысы мәгълүм, алардан котылырга югары температура ярдәм итә. Әмма иске технологияләрдә төтен газлары суынган чакта диоксиннарның кабат синтезлашуы исәпкә алынмаган. Мәсьәлә болай хәл ителә: диоксиннар уңышлы таркалсын өчен газларны казанда 850 градустан артык температурада ике секундтан да кимрәк тотмаска кирәк.

Әле бу башы гына. Яңа буын заводларының төтен газларын чистарту системасы, шул исәптән, булачак Казан заводында да – өч баскычтан тора. Аларның икенчесе икенчел диоксиннардан, органик матдәләрдән, авыр металлардан һәм кислоталы кушылмалардан активлаштырылган күмер һәм сүндерелгән известь ярдәмендә котылырга булыша. Өченчесе – төтен газларын көлдән, тузаннан һәм газ чистарту продуктларыннан җиңсә фильтрында арындыру.

«РТ-Инвест» компаниясе Мәскәүдә үз проектын тәкъдим иткәндә, аның файдасына тәэсирле саннар китерде. 2022 елда ул сафка бастырачак биш завод та елына якынча 3,35 млн тонна калдыклар эшкәртә алачак, шул ук вакытта һавага нибары 0,7 грамм диоксиннар бүлеп чыгарылачак. Чагыштыру өчен: Мәскәү өлкәсе һәм Татарстан полигоннарында, әйләнә-тирә мохиткә 190 грамм диоксин бүлеп чыгарып, бер контрольсез 0,29 млн тонна калдыклар яна.

Кайчандыр Мәскәүдә экология таләпләренә туры килмәгән чүп яндыру заводлары төзелгән булган. Алар, җәмгыятебездә калдыкларны термик зарарсызландыру технологиясенә карата озакка сузылган ышанычсызлык тудырып, үзләрен начар яктан күрсәттеләр. Күптән түгел аларның берсе, төгәлрәк әйткәндә, МСЗ-3, барлык заманча нормаларга туры китереп, тулысынча үзгәртеп корылды.

– Мин ул заводта булдым, – дип сөйли Рөстәм Богданов. – Күргәннәрем бик тәэсирләндерде һәм шулай ук ышаныч та уятты: нәкъ менә шушы юлдан барырга кирәк. Бигрәк тә – миллионлы шәһәрләргә, алар алдында инде бүген үк полигоннар өчен буш җир мәйданнары сайлау проблемасы кискен тора.

Сүз уңаеннан, Казанда булачак төзелеш инвесторлары шушындый ук сайлау проблемасы алдында калдылар. Россия санитар нормалары буенча завод торак төзелешләренә якын урнашмаска тиеш. Шул ук вакытта сәламәт компромисс табарга да кирәк, ахыр чиктә аның ераклыгы логистик маршрутларны озайту исәбенә халык өчен тарифның артуына китермәслек булсын.

– Европада чүп яндыру заводлары берсүзсез хәтта балалар бакчасы янәшәсендә дә торырга мөмкин, чөнки анда безнең законнар куйган кебек «санитар-саклык зонасы» дигән төшенчә юк. – дип сөйли Рөстәм Богданов. – Гаҗәп, әмма бу яктан безнең законнар шактый кырыс. Казан кешеләре хәтта атаклы Монако князе белән чагыштырганда да отышлырак хәлдә булачак! Үзем тикшереп карамадым, әмма аның шушындый заводтан алтмыш метр ераклыкта гына яшәве турында ишеткәнем булды.

Эксперт сүзләренә караганда, санитар-саклык зонасы, таблица саннарына караганда, якынча бер мең метр чамасын тәшкил итәчәк. Исәп саны модельләштерү нәтиҗәләре буенча алынса, чынбарлыкта – предприятие эшли башлагач, натурада үлчәүләр барышында билгеләнәчәк. Әйтик, Мәскүнең МСЗ-3 заводы өчен санитар-саклык зонасы нибары 350 метрны тәшкил иткән. Шул ук вакытта Богданов анык ышана: Казан заводы өчен сайланган урын торак йортлардан шактый читтә (1–2 чакрымнан ким түгел) булачак.

ЧЫГЫШЫ НИНДИ?

Татарстан заводы Казанда һәм якын-тирә шәһәрләрдә яшәүче 1,5 миллионлап кешегә хезмәт күрсәтәчәк. Аның егәрлекләре бер елга 550 тонна чүп эшкәртә алачак, бу сан мегаполисның бүгенге таләпләрен дә артыгы белән узып китә – ягъни калдыкларны икенчел эшкәртү өлешенең артуын исәпкә алмыйча да. Ә чыгышы нинди?

Инвестор исәпләре буенча, калдыкларның бер тоннасыннан сәгатенә 690 кВт электр энергиясе (ул кулланучылар өчен челтәргә тапшырылачак), юл төзелеше ихтыяҗларына 300 килограмм инертлы шлак, һәм шулай ук 28 килограмм металл һәм 30 килограмм очучан көл алырга мөмкин булачак. Соңгысы куркыныч калдыклардан санала һәм ул цементлау юлы белән нейтральләштереләчәк, әмма Андрей Шипелов әйтүенчә, бу юнәлештә аларның эшлиселәре бар.

– Очучан көлне куллануда Бөекбританиянең Колнбрук шәһәрендәге завод үрнәк булып тора, – дип сөйли ул. – Анда көл-шлак калдыклары йөз проценты белән файдалы продуктларга эшкәртелә. Заводта очучан көлдән төзелеш материаллары җитештерү буенча кулланыла торган Carbon8 технологиясе БМО тарафыннан цикллы икътисад үсешенә керткән әһәмиятле өлеш үрнәге дип танылган.

«РТ-Инвест» компаниясе исәпләвенчә, завод сафка басканнан соң 5 ел дәвамында Казан бюджетына 1,8 млрд сум күләмендә салым һәм салымнан тыш керемнәр, ә республика бюджетына 4 млрд сум күләмендә керемнәр юнәлтеләчәк. Моннан тыш, проекттан тагын бер икътисади нәтиҗә көтелә – ул сәнәгатьнең яңа тармагын, һәм шулай ук яңа эш урыннарын булдыруның нигезен тәшкил итәчәк.

Компаниядә әйтүләренчә, җәмәгатьчелек тыңлауларын булачак проект турында инженерлык тикшеренүләре һәм аның әйләнә-тирә мохиткә тәэсире турындагы бәяләмәләрдән соң шунда ук уздыру күздә тотыла. Мөгаен, алар шушы елның көзенә туры килер. Без әлеге очрашулар вакытында шәһәр кешеләре үзләрен борчыган барлык сорауларга җавап табар дип ышанабыз. Ә без бу теманың үсешен күзәтеп торачакбыз.

ГАЛИМ ФИКЕРЕ:

Светлана Селивановская, КФУның Экология һәм табигатьтән файдалану институты директоры, профессор, биология фәннәре докторы

– Европа илләрендә чүпләрне яндырудан инде баш тарталар, дип сөйлиләр. Бу бик үк дөрес түгел. Термик эшкәртелүгә җибәрелә торган калдыклар күләменең статистикасына карау да җитә. Ул анда елдан-ел үсә бара. Күптән түгел без калдыкларны эшкәртү темасына түгәрәк өстәл оештырдык. Анда катнашучылар – галимнәр, шушы юнәлештәге министрлыклар хезмәткәрләре, һәм шулай ук җәмәгатьчелек вәкилләре – шундый консенсуска килде: полигоннарда әйләнә-тирә мохиттә калдыкларны урнаштыру минималь күләмдә булырга тиеш. Әмма моны тормышка ашыру өчен республикада чүпне селекцияле җыю, аны сортларга аеру, утиль фракцияләрен эшкәртүне дә кертеп, калдыкларны эшкәртүнең күп этаплы схемасын кертү зарур. Һәм барыбер, моннан соң да, калдыклар калачак, ә аларны термик юл белән юк итәргә кирәк, ә полигоннарда калдырмаска. Шуңа күрә, фәнни күзлектән караганда, чүп яндыру заводы булырга хаклы. Бу яктан мин эшләрнең сыйфаты турында борчылуымны белдерә алам. Булачак чүп яндыру заводы – проект документациясеннән башлап, аның урнашу урынын сайлауга кадәр – барлык зарури экспертизаларны үтәргә тиеш. Барысы да дөрес эшләнергә тиеш.

PRESSA.RU

ТАТТЕЛЕКОМ
ҮЗЕБЕЗНЕКЕЛӘР БЕЛӘН ҺӘРЧАК ЭЛЕМТӘДӘ!

Татарстан Республикасы Россия Федерациясендәге иң актив үсештәге һәм алдынгы субъектларның берсе. Техник һәм мәдәни үсеш биредә бер генә секундка да тукталып тормый, ТР шәһәрләренә һәм районнарына актив рәвештә үтеп керүен дәвам итә. Моңа Татарстан Хөкүмәтенең сәясәте дә этәргеч булып тора. Бу сәясәт предприятиеләрнең, кече һәм урта бизнесның, аграр секторның үсешен һәм мегаполиска хас булган уңайлыкларның республикадагы иң ерак районнарга кадәр барып җитүен тәэмин итүгә корылган.

Элемтә турында сүз алып барсак, республика районнарының үсешенә без керткән төп күрсәткечләрнең берсе булып аларда яшәүчеләргә мәгълүмат чыганакларына тоташа алу мөмкинлеге бирү исәпләнә ала. Интернет булсынмы ул, телевидениеме, телефониями, мобиль элемтә турында инде сүз кузгатып тору да кирәкмидер. Максатыбыз – «цифрлы тигезсезлек» дигән төшенчәне юк итү.

Бүген Татарстанның эре шәһәрләрендә һәм районнарында цифралы технологияләрне үстерү өлкәсендәге төп проектыбыз булып, әлбәттә, мобиль элемтә хезмәтләре тора. Таттелекомның «Летай» брендлы мобиль элемтәсе базарга 2014 елда чыкты, нәкъ менә шул вакытта 1800 МГц диапазонында 4G/LTE стандарты буенча хезмәтләр күрсәтүгә Россиядә беренче лицензия алынды.

3,5 ел эчендә Таттелеком төп станцияләре санын 4 тапкырга арттырды. Хәерге көндә «Летай»ның 1300 дән артык төп станциясе бар, аларның күбесе 4G/LTE стандарты буенча җиһазландырылган. Geo.minsvyaz.ru хөкүмәт порталы мәгълүматы буенча, «Летай» республикадагы 4G/LTE белән каплау буенча лидер, шулай ук трасса белән сәнәгать зоналарында да аның өстенлеге мәгълүм.

«Летай» мобиль элемтәсе белән нәкъ менә Таттелекомның 4G/LTE стандарты буенча мобиль интернет белән иң беренчеләрдән булып киң колачлы рәвештә районнарны тәэмин итә алуы гаять әһәмиятле.

2017 ел нәтиҗәләре буенча, Таттелеком коллективы тагын өстәмә 100 дән артык төп станцияне эксплуатациягә тапшырырга җыена.

Таттелекомның үзе өчен яңа юнәлештә эшләвенең нәтиҗәсе: «Летай» мобиль элемтәсе базасында бүгенге көндә 400 меңнән артык абонент бар. Асылда, 2016 елда һәм 2017 елның ярты елында кулланучылар саны ике тапкырга артты. ComNews Telecom 2016 мәртәбәле аналитик хисап системасы бәясе буенча «Летай» Россия Федерациясендәге иң тиз үсешкә ия мобиль элемтә операторы булып игълан ителгән.

Республикабыз территориясендә яши торган халык һәм иң мөһим оешмалар белән индивидуаль эш алып баруның бер мисалы буларак Татарстан Республикасы Диния Нәзарәте белән берлектә булдырылган «Азан» тариф планын атарга мөмкин. «Азан» тарифында 4G лимитсыз интернеты кулланыла ала. Тарифның башка мөмкинлекләрен исәпкә алсак, гудоклар урынына ТР ДН тарафыннан хупланган көйләр һәм иртәнге намазга уятучы будильник хезмәте каралган. Алар өстәмә бонус буларак бара, теләгән кеше үзләрен куша, теләми икән, кушып тормый яисә теләсә кайсы мизгелдә алардан баш тарта ала. «Азан» тарифын ТРнда яшәүчеләрнең һәммәсе дә куллана ала – Таттелеком белән «Летай» офисларына мөрәҗәгать итәргә генә кирәк.

«Азан» тариф планын чыгару ТР Диния Нәзарәте белән хезмәттәшлекнең бер юнәлеше генә, Таттелекомның башка проектлары да бар – мөселман радиосы һәм ТВ каналы белән эшчәнлек, мәсәлән.

Бүген күпчелек яшьләр рухи кыйммәтләргә тартыла: вәгазь тыңларга йөри һәм яшәеш турындагы сорауларына җавап эзли. Шуңа да, мөселманнар алдында Диния Нәзарәте мөһим бурыч куя – яшьләр белән әхлакый яктан дөрес, матур диалог төзи алу. Таттелеком бу эштә аларның уң кулы булып тора.

Стратегик хезмәттәшлек кысаларында Таттелеком һәм ТР Диния Нәзарәте тарафыннан шулай ук мөселманнар өммәте өчен уртак булган мәсьәләләрне хәл итү өчен кайнар телефон линиясе булдырылды. Тариф кысаларында мөселман календарендәге мөһим даталарны искә төшереп, хәдисләр, нәсыйхәтләр урнаштырып, ТР Мөфтиятенең котлауларын беркетеп махсус СМС-таратулар юллау каралган. Уртак

Реклама

* 4Джи/ЛТЕ, ** КомНьюс Телеком.

проектның төп социаль һәм мәгърифәтчел максаты шуннан гыйбарәт.

«Цифрлы тигезсезлек»не бетерүдән тыш, тагын бер өстенлекле юнәлеш булып республика гражданнарының куркынычсызлыгы тора. Бу өлкәдә Таттелеком «Куркынычсыз ишегалды» дигән киң колачлы проектны тормышка ашыра.

Заманча күзәтү камералары кешене берничә дистә метр ераклыктан күреп алырга һәм танырга мөмкинлек бирә, ә бүген күпчелек урам видеокамераларына урнаштырылган инфракызыл яктырткыч исә территориядә нинәр булганын тулы караңгылык шартларында да яздырып алуны тәэмин итә. Бу сынауны Европадагы иң эре шәһәрләр үтте инде, Лондонда гына да хокук бозуны теркәп куя торган 4 миллионнан артык видеокамера бар.

2016 ел башында ук республика хакимияте «торак йортлардагы видеокамераларның мөһим куркынычсызлык чарасы» булуын ассызыклады. Шәһәрдәге куркынычсызлык дәрәҗәсен арттыру юнәлешендә эшне камераларны нәкъ менә торак йортларга мөмкин кадәр күбрәк урнаштырып алып барырга кирәк дип таптылар. «Куркынычсыз ишегалды» проекты Татарстан Республикасы Куркынычсызлык советы тарафыннан тулаем хупланды.

2016 елда Таттелеком ИК һәм ТМШ белән актив хезмәттәшлек кысаларында йорт тирәсендәге территорияләрдә беренче күзәтү камераларын монтажларга кереште. Күпкатлы йорт нигездә өч камера белән җиһазландырыла. Алар ишегалдына керү юлын, балалар уйный торган мәйданчыкны һәм чүп-чар ташлый торган мәйданчыкны төшерә. Видеокамераларны монтажлау, элемтә чаралары һәм видеоархивны саклау системасы өчен киткән чыгымнарны Таттелеком тулаем үз өстенә ала. Видеокүзәтү хезмәтен кулланучылар булып идарә компанияләре белән хосусый милек иясе ширкәтләре тора, нәкъ менә алар йорт тирәсендәге мөлкәтнең саклануына гаять җитди карый. Камераларга төшерелгән язма махсус тапшыргыч челтәр буйлап видеомониторинг серверларына җибәрелә. Бу системага мөрәҗәгать итәргә бары тик ИК/ТМШ белән эчке эшләр органнары хезмәткәрләренә генә рөхсәт бирелә.

Компания проекты үсеш кичерә, хәзер инде йортта яшәүчеләрнең күбесе үз йортлары тирәсендәге язмаларның видеотрансляциясен Таттелекомның шәхси кабинеты аша онлайн режимда карый ала. Теләге булганнар тәүлек дәвамында үз автомобиле һәм ишегалдында уйнап йөрүче баласын күзәтә ала, бер үк вакытта өйдәге эшләрне ташламаска да мөмкин.

ТРның торак йортларында бүгенге көндә «Куркынычсыз ишегалды» кысаларында 5500 видеокамера урнаштырылган, планда тагын 10 меңне урнаштыру. Йорт тирәсендәге территорияне күзәтү – «Куркынычсыз ишегалды» дигән олы проектның үсешендәге әһәмиятле этапларның берсе. Таттелекомның планнары зурдан: подъезд эчендә күзәтү урнаштыру мөмкинлегеннән файдалану, яңа типтагы видеомофонны эшләтеп карау. Соңгысы йортта яшәүчеләргә видеочакыруны үзләренең планшетында яисә өй телефонында күрү мөмкинлеген бирә.

Ришат Хәмидуллин – мәгълүмати сәясәт буенча мөфти киңәшчесе, «Хозур» нәшрият йорты директоры, Камил хәзрәт Сәмигуллин – ТР мөфтие, Лотфулла Шәфигуллин – «Таттелеком» ГАҖ генераль директоры, Александр Смирнов – «Таттелеком» ГАҖнең маркетинг һәм хезмәт күрсәтүләр белән идарә итү буенча директоры.

Без бүген Татарстан Республикасындагы бердәнбер «йорт» операторы. Туган төбәгебезнең үсеше өчен кулдан килгәннең барысын да эшләргә тырышабыз. Таттелекомның киң колачлы бөтен планнары да бер максатны күздә тота – татарстанлыларның тормышын тагын да уңайлырак итү.

Таттелеком.
«Летай» мобиль элемтәсе.
Үзебезнекеләр белән һәрчак элемтәдә!

Летай
ТАТТЕЛЕКОМ



PRESSA.RU

ТАТАРСТАНДА УКЫЙСЫҢ –

«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАНДА ҖИҢӘСЕҢ –

«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

ТАТАРСТАНДА ЭШЛИСЕҢ –

«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

ТАТАРСТАНДА ЯШИСЕҢ –

«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

WWW.PROTATARSTAN.RU

Реклама 16+

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Казанның **КАЙСЫ** урынында табигый оазис пәйда булачак

Балага **НИНДИ** исемнәрне кушарга ярамаячак

PRESSA.RU

КАБАН КҮЛЕ. ХӘЗИНӘЛӘРНЕ КИРЕ КАЙТАРУ

Казандагы Меңьеллык паркы каршында могҗиза туа: Түбән Кабан яры күз алдында үзгәрә, искиткеч гүзәлләнә. Якын киләчәктә Татарстан башкаласы үзенең... технологиялелеге белән гаҗәпкә калдыра торган табигый оазис рәвешен алачак – анда Россия өчен уникаль үзеннән-үзе чистартылу системасы кулланылачак.

Автор:
Ольга Туманская

ТРЕНДТА – ТАБИГЫЙЛЕК

Барысы да Кабан күленнән башланган. Әлеге күлләр системасы ярларын төзекләндерүнең иң яхшы концепциясенә конкурс былтыр июньдә игълан ителгән иде. Анда 18 илдән белгечләр катнашкан, 160 тан артык архитектура бюросы үз гаризаларын җибәргән.

Идеяләр бик күп һәм берсеннән-берсе әкәмәтрәк булган. Мәсәлән, Кабанда шәһәрнең яңа символын – Зилант аждаһасы манарасын төзү. Су өстендәге йөзмә айсбергта дискотекалар үткәрү. Яисә түбән күлдә берничә биосфера булдырып, аларда бөтенләй башка географик зоналар табигатен җанландыру. «Сыгылмалы тасма – Казанның үлемсез хәзинәләре» концепцияле проект исә җиңеп чыккан. Аның төп идеясе гади һәм ышандыргыч: күлне кешеләргә кайтару (исегезгә төшерәбез, хәзер шәһәр халкы ярның нибары бер кечкенә генә урынында су буена төшә ала). Абруйлы жюри проектка экология критерийлары буенча бик югары баллар куйган, шуңа әлеге хезмәт башкаларын күпкә артта калдырган.

Бу идеянең авторы – Кытайның Туренскейп компаниясе, ул үзенең масштаблы ландшафт проектлары белән бөтен дөньяда танылган. Алар арасында – Харбин, Сиэтл, Гонконгтагы, Бали утравындагы паркларны тәртипкә китерү... Компания фәлсәфәсенең нигезендә табигать һәм кешенең урбанлашу шартларында үзара тыгыз бәйләнеше ята. Казанда ул Кабан күлләре системасының буеннан-буена сузылган яшел-зәңгәр билбау рәвешендә тормышка ашырылачак, табигать объектларын мәдәни мохит һәм торак мәйданнар белән «туганлаштырачак».

– Экологик материаллар файдасына без бетоннан баш тартабыз, суны чистартабыз, аның янына ук барып җитәрлек ясыйбыз, мәдәни чаралар өчен мохит формалаштырабыз, – диде Туренскейп бюросы президенты һәм баш дизайнеры доктор Конгжан Ю үз

проектын ТР Президенты Рөстәм Миңнехановка тәкъдим иткәндә. – Без су шәһәрнең аерылмас өлешенә әйләнә торган җәмәгать урыннары булдырабыз. Ул сыгылмалы элементтай эшли – һәркем өчен, теләсә кайсы фасылда. Безнең идеябез шуннан гыйбарәт: без мәдәни мирастан читкә тайпылмаска, шәһәрнең хәтерен һәм тарихын сакларга тиеш.

Үз чиратында, республика җитәкчелеге кытай архитекторлары идеяләрен тулы күләмендә, бернинди кыскартуларсыз тормышка ашыру ниятен белдерде.

БЕЛЕШМӘ:
Кабан – республикадагы иң зур күлләр системасы. Бу – Татарстан башкаласының экологик каркасы һәм аның һичшиксез табигый өстенлеге. Гомуми мәйданы 186 гектар тәшкил итә. Система өч күлдән – Югары Кабан, Урта Кабан һәм Түбән Кабаннан гыйбарәт. Беренчесе – иң кечкенә, озынлыгы бер километр гына, икенчесе – иң зурысы, өч километрдан артыгракка сузылган, өченчесе исә иң төзеге. Түбән Кабанның яр буйлары шәһәрнең үзәк урамнарына тоташа, аның тарихи өлешенә чыга.

ХӘТТА СУ БАСУ БЕЛӘН ДӘ ДУСЛАШЫП БУЛА

Моңа охшаш проектларның берсен компания ватаннарында – Кытайда гамәлгә ашырган. Тайчжоу округы халкы озак вакытлар буе су басулардан интеккән. Хакимият елга каналын торгызуга күп көч һәм акча сарыф иткән, әмма бу проблеманы кискенләштергән генә. Су басулар белән көрәшүне түгел, бәлки дуслашуны артыграк күргән Туренскейп архитекторлары иң беренче эш итеп бетон ярларны җимерергә тәкъдим иткән. Икенче этапта эчке буалар буылган. Өченче этапта парк булдырылган. Бүген җансыз канал урынында искиткеч гүзәл «Йөзмә

PRESSA.RU

бакчалар» ландшафт комплексы җәйрәп ята. Су басулар проблемасы да хәл ителгән, кешеләр өчен күпфункцияле мәдәни мәйдан да пәйда булган.

Моңа охшаш чишелешнең Казан өчен актуальлеген бүген табигать көчләре үзләре таләп итә. Быелгы җәй безнең төбәкне аномаль явым-төшем күләме белән «сөендерде» инде. Кайвакыт Татарстан башкаласы урамнары Венеция каналларын хәтерләтте.

Шәһәрдә яңгыр суының ничек җыелуын без барыбыз да балачактан ук беләбез. Кәгазь көймәләр әлеге процесска иң күрсәтмә сурәтләр булып торадыр, мөгаен: башта су асфальт тротуарлардан юлларга, аннары, алар буйлап, бөтен пычракны үзенә ияртеп, табигый сулыкларга – елга һәм күлләргә агып төшә. Шундый сулыкларның берсе – Түбән Кабан.

Бүген күлгә 12 урында су агып төшә, һәм шулардан нибары берсендә генә чистарту җайланмасы бар. Ни өчен берсендә генәме? Чөнки, су чистартуны шул рәвешле башкарганда, без икенче күңелсезлеккә юлыгабыз – төзекләндерелгән яр буе урынына койма белән киртәләп алынган зур санитар зона барлыкка килә. Су агып төшкән бөтен җиргә дә чистарту системалары куйганда, шәһәр халкына яр буена төшәрлек урын бөтенләй калмас иде.

Үзенең асылы белән Туренскейп компаниясе проекты Кабан ярларын яңарту гына түгел, күпкә колачлырак ул. Бу Казанның гына түгел, бөтен илнең коммуналь өлкә сәясәтендә чын үзгәреш! Үзегез уйлап карагыз: шәһәргә яңгыр суын җыю, чистарту һәм кабат файдалануның бөтенләй яңа ысулы тәкъдим ителә. Аның нигезендә шәһәрдәге табигый процессларның өстенлеге принцибы ята. Әлеге технологияне доктор Ю «Яшел губка» дип атый. Бүген ул Европада һәм Америкада зур уңыш белән кулланыла.

– Яңа проект безгә юллардан җыела торган яңгыр суларының күләмен киметү юлыннан барырга тәкъдим итте, – дип сөйли проектны әзерләү стадиясенең архитекторы Анна Новикова. – Киләчәктә су бөтен шәһәр буйлап (ишегалларында да) урнашкан яңгыр бакчаларының ландшафт комплексларына юнәлтеләчәк, дип фаразлана. Шунда ук биологик чистартылачак. Без бу мәсьәләне өйрәндек: мондый үсемлекләр комплексы суны пычранудан ике дәрәҗәгә яхшырак чистартырга сәләтле – бу бик яхшы күрсәткеч.

Анна әйтүенчә, иң югары чистарту сәләтенә безнең җирлек өчен традицион булган җикәнбаш, камыш, куга, май чәчәге һ.б. ия. Аларның кайберләре хәтта нефтьле кушылмаларны да эшкәртергә сәләтле! Ландшафт дизайнерларының бурычы – бу вакытта эстетиканы да хәтердән чыгармыйча, үсемлекләрнең әлеге үзлекләрен файдалану.

Түбән Кабан күле ярының Марсель Сәлимҗанов һәм Артем Айдинов урамнары киселешеннән ерак булмаган өлешендә беренче комплекс төзелә инде. Биредә катлаулы гидротехника корылмасы – унике биоплатодан торган яңгыр бакчалары каскады салыначак, ә тыгыз асфальтны беренче тапкыр су үткәрә торган өслек белән алыштырачаклар.

– Бу безнең тест полигоны, – дип аңлата Анна Новикова. – Үсемлекләр утыртачакбыз, кирәк булса, аларны алыштырачакбыз – бер сүз белән әйткәндә, аларның нинди комбинациядә яхшырак эшләвен өйрәнәчәкбез. Әлеге сынау комплексы яңгыр суын чистартуның локаль ландшафт системасын Казанда һәм республикада ничек яхшырак кулланып буласын аңларга ярдәм итәчәк. Процесс тиз түгел – киңәш-тәкъдимнәрне бары берничә елдан соң гына тулысынча формалаштырып булачак.

«ЯШЕЛ ГУБКА» ТАНТАНАСЫ

– Россиядә хәзер моннан берничә ел элек Кытайда барган вазгыять күзәтелә, димәк, ул шулай ук аяныч тәмамланырга мөмкин, – дип борчыла Туренскейп президенты ярдәмчесе Стэнли Лунг archspeech интернет-басмасына биргән интервьюсында. – Соңгы 30 ел дәвамында барган урбанлашу процессы нәтиҗәсендә хәзер кытайларның 70 проценты шәһәрләрдә яши, бөтен табигать системасы җимерелде, һәм пычрату процесслары тагын да тизрәк бара башлады. Кайчандыр безнең илебез яшел иде, бүген исә бөтен урман массивлары юк ителгән. Мондый шартларда безнең барыбызга да ничек исән калырга соң? Мәскәүдән аермалы буларак, Казанда, күлле районнарда гына булса да, әлегә шәһәр инфраструктурасын тиешенчә кору мөмкинлеге бар.

Шулай итеп, якындагы елларда Кабан күлләре системасы ничек үзгәрәчәк? Беренче үзгәрешләр Түбән күлгә кагыла. Барлыгы 186 гектарның 25есе тәртипкә китереләчәк. ТР Президентының Җәмәгать урыннарын үстерү программасы кысаларында инде быел җәй азагында ук Сәлимҗанов урамы ягындагы гадәттә кешесез яр буенда – Камал театрыннан алып «Планета Фитнес» спорт комплексына кадәр – төзекләндерелгән кишәрлек пәйда булачак. Субайларга урнаштырылган аскы юл буйлап су кырыена ук төшеп булачак.



Велосипедта йөрергә яратучылар, мөгаен, киләсе елдан күл периметры буенча салынган махсус юлдан элдертә алачак. Тоташ променадның озынлыгы биш километр тәшкил итәчәк. Аның иң катлаулы урыннарыннан берсе – яңа җәяүлеләр-велосипедчылар күпере – Назарбаев урамындагы транспорт күперенә параллель төзеләчәк, исәпләүләр аны киңәйтүнең максатка яраклы булмавын күрсәткән.

Күлнең бөтен ярлары буена яктырту системасы һәм кече архитектура формалары урнаштырылачак, җәмәгать туклануы павильоннары, көймә, катамаран һәм байдаркаларны прокатка алу пункты һәм бәдрәф булдырылачак. Киләчәктә кафелар челтәре эшләячәк.

Бер ярдан икенчесенә кадәр су таксиенда барып җитеп булачак – бөтен күл буена пирслар системасы салыначак. Сүз уңаеннан, бу ял итеп йөрүче туристлар өчен генә түгел, гел ашыгучы шәһәр халкы өчен дә уңайлы булачак.

Шулай да күлнең иң кызыклы (һәм иң технологик!) элементын «Яшел губка» технологияле су буалары каскады системасы тәшкил итәчәк. Үсемлекләрне инфильтрлаштыру системасы ярдәмендә ул күлдәге суны чистартачак. Чиста Кабан – шәһәр халкының күптәнге хыялы, ул озак вакытлар буе ирешә алмаслык саналды. Алар өчен бу технология яр буенда төзелгән гаять зур су кристаллы формасындагы махсус павильонда бөтен нечкәлекләре белән аңлатылачак.

– Без Кабан күлләре буендагы табигый шартларда су бакчалары утыртырга җыенабыз, – ди Анна Новикова. – Безнең җирлеккә хас үсемлекләрне, шулай ук декоратив элементлар кулланачакбыз. Бүген ландшафт дизайнында тренд табигыйлеккә йөз тота, һәм без дә шуңа иярәбез!

Проектның тагын бер тренды – тотрыклы үсеш принцибы, ул күпьеллык, талымсыз үсемлекләрне файдалануны күздә тота. Бу киләчәктә бакчаны карап тоту чыгымнарын киметәчәк.

– Без әле матур кышкы пейзаж турында да хыялланабыз, – дип сөйли Анна. – Үсемлекләрнең бер өлеше туры басып торучы булачак. Җикәнбаш, камыш, кайбер кыяклылар карда искиткеч күренәчәк. Яр буенда салкын кыш көннәрендә йөрү дә күңелгә рәхәтлек бирәчәк. Язын кипкән үсемлекләр җыеп алыначак.

Шулай да казанлыларга шактый сабыр итәргә туры киләчәк әле: бакча үстерү – бер генә еллык эш түгел. Әмма барысы да ниятләгәнчә барып чыкса, шәһәр судагы искиткеч ботаника бакчалы булачак. Проектның метафоралы «Сыгылмалы тасмасы» өч күлдән торган бердәм ландшафт системасын шәһәрнең мәдәни һәм тарихи мирасы белән бәйләячәк. Ул мегаполис халкына кайчандыр юкка чыгарылган табигать оазисын кире кайтарачак.

«Казанда тагын 50 елдан соң нәрсәләр буласын күзаллавы җиңел. Бу тормыш өчен уңайлы шәһәр булачак. Теләгән һәркем аның буенча велосипедта йөреп, күлдә көймәдә йөзеп, җәй эссесендә челләдән котыла алачак...» – дигән иде Стэнли Лунг интервьюларының берсендә. Моңа беренче адым ясалган инде.

PRESSA.RU

БЕРДӘМЛЕККӘ ИСӘП ТОТЫП

Июнь башында Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов 2018 елның 1 гыйнварыннан төп бурычы коммуналь түләүләрне исәпләү методикасын унификацияләү булачак бердәм республика исәпләү үзәге эшли башларга тиешлеге турында белдерде. Әмма үзәк аның концепциясе буенча эшләсен өчен, гомуми юнәлешләрне тәртипкә салучы гына түгел, ә үзәкнең нәтиҗәлелеген гарантияли торган критерийларны да билгеләүче хокукый база булдырырга кирәк.

Төп проблемалар турында безгә «Казан шәһәренең бердәм исәпләү үзәге» ҖЧҖ генераль директоры Дмитрий Анисимов сөйләде.

МИЛЛИ ТКХ НЫҢ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

– Бүген безнең эшчәнлек РФ Торак кодексы положениеләренә нигезләнә. Шул ук вакытта кодекс та, нинди дә булса башка норматив документлар да БИҮнә, бу структура туры килергә тиешле критерийларга төгәл билгеләмә бирми. Нәтиҗәдә Россия Федерациясендәге исәпләү үзәкләре эшләрен тулаем алар тирәсендә барлыкка килгән инфраструктура кысаларында мөмкин булганча оештыралар, – ди Дмитрий Владимирович.

Мондый шартларда БИҮ файдаланучылар һәм хезмәт күрсәтүчеләр, шулай ук надзор органнары белән даими каршылыкка очрап тора. Өстәвенә, мондый проблемаларның һәр төбәктә үз үзенчәлеге бар.

– ТКИнә түләү буенча халык белән эшләүгә килгәндә,Татарстан шактый алдынгы төбәк булып исәпләнә. Безгә Норильскидан да, Чиләбедән дә килгәннәре бар. Хәтта Владикавказдан да – анда хәлләр шактый мөшкел. Татарстанда торак өчен түләү уртача 96–99% тәшкил итсә, аларда – 15%, ә коммуналь хезмәткә түләү – 60%. Идарә компанияләре еш кына банкротлыкка чыга, – дип сөйли Дмитрий Анисимов. – Ә менә Мәскәүдә бөтен нәрсә башкача. Анда шәһәр исәпләү үзәге күп функцияле үзәк системасына берләшкән, һәм гаилә составы, пропискадагылар саны үзгәрү белән, БИҮ хезмәткәрләре шунда ук бу хакта белә, бер генә төймәгә басып, квитанциягә үзгәреш кертә. Яңа закон чыгарганда берничә реаль үрнәк тәкъдим итәргә һәм төбәкләргә алар арасыннан үз шартларына туры килгәнен сайлап алу мөмкинлеге тудырырга кирәк.

БАНКРОТ ӨЧЕН КЕМ ТҮЛИ?

БИҮ эшчәнлеген җайга салу буенча законнар чыгаруны камилләштерү өчен, үзәкләр үзләре, идарә компанияләре һәм банклар башкара торган торак-коммуналь идарәсенә түләү акчаларының иминлеген тәэмин итәргә кирәк.

Бу түләүне бүген РФ Торак кодексы һәм РФ Хөкүмәтенең ике карары регламентлаштыра. Ләкин бу документлар, мәсәлән, коммерциялә нгән исәпләү үзәкләренең устав капиталы нинди булырга тиешлеген билгеләми. Ә мондый үзәкләр булып еш кына устав капиталы 10 мең сумнан артмаган оешмалар тора. Банкротлыкка чыккан очракта аларның финанс җаваплылыгы бик кечкенә булачак. Компания җитәкчелеге алышынганда яисә торак йорт белән идарә итү формасы үзгәргәндә акчаларның «югалу» очраклары да аз түгел.

Моннан тыш, Россиядә ТКХна халыктан җыела торган түләү акчаларын страховкалау гамәлгә кертелмәгән. Моның ачык мисалы – гражданнарның Татфондбанк һәм Интехбанкта «эленеп» калган түләү акчалары.

– БИҮ өчен акчаларны страховкалау процедурасы мәҗбүри бу-

Реклама

лырга тиеш. Моннан тыш, БИҮ турында без дәүләт финанслый һәм идарә итә торган зур структура буларак сөйләшәбез икән, аңа хезмәт күрсәтүче банк, һичшиксез, конкурс нигезендә сайлап алынырга тиеш. Мондый тәртипне федераль дәрәҗәдә раслау күп кенә Россия төбәкләрендә түләүләрнең куркынычсызлыгын сизелерлек күтәрергә ярдәм итәчәк, – дип ышандыра Дмитрий Анисимов.

САКЛАУ ҺӘМ ТАПШЫРУ АЧКЫЧЫ

БИҮ эшенең икенче бер үзенчәлеге – гамәлдәге оешмамы ул, әллә киләчәккә йөз тоткан проект кынамы, – мәгълүматларны саклау һәм тапшыруны тәэмин итүгә бәйле. Бу процесс бүген исәпләү үзәкләренең күп төрле каршылыклар белән очрашуын исәпкә алмый торган «Персональ мәгълүматларны яклау турында»гы ФЗ белән генә регламентлана.

– Идарә итүче оешмаларның исәп-хисап эшләренә куелган таләпләр закон буенча исәпләү үзәкләре аша билгеләнгән очракта БИҮ түләүләрне күчерү һәм җыю буенча мәгълүматларның тулы базасын саклауның гаранты булырга мөмкин, – ди Дмитрий Владимирович. – Бердәм мәгълүматлар базасы төзү белән дәүләт, муниципаль, хокук саклау һәм күзәтчелек органнарының да кызыксыначакларына шикләнмим.

ХӘРӘКӘТ ИТӘРГӘ ВАКЫТ

Казанның БИҮ җитәкчесе торак-коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү, кабул итү һәм түләү процессларында катнашучыларның барысы арасында да үзара оптималь мөнәсәбәтләр булдыруга ярдәм итәчәк тормышчан, нәтиҗәле закон проекты төзү өчен бу эш белән кызыксынган һәр төбәк эксперт советларының планлы уртак эшләре кирәклегенә тирәнтен ышана. Барлык кирәкле ресурслары, шул исәптән ТКХ сферасында нәтиҗәле программалар төзүдә зур тәҗрибәсе һәм РФ Дәүләт Думасында әлеге үзәкнең кирәклеге белән кызыксынган вәкилләре булган Татарстан, үзенең социаль-икътисади өлкәдә иң яхшы, иң нәтиҗәле практикаларны тормышка ашыручы драйвер-төбәк статусын тагын бер кат раслап, бу процессның инициаторы булырга мөмкин.

Искәндәр Гыйниятуллин, Казан Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары – Торак-коммуналь хуҗалык комитеты рәисе:

– Илнең күп кенә эре шәһәрләрендә торак-коммуналь хезмәтенә түләүне махсус оештырылган юридик шәхесләр – исәпләү үзәкләре санап чыгара, җыя һәм бүлә. Төрле төбәкләрдә аларны төрлечә атыйлар – бердәм исәпләү үзәкләре, исәпләү-мәгълүмат үзәкләре, исәпләү-касса үзәкләре һ.б. Бүгенге көндә аларның эшчәнлеге махсус норматив-хокукый актлар белән көйләнмәгән. Ә моңа мохтаҗлык бар, чөнки, беренчедән, мондый юридик шәхесләр карамагына шәһәр һәм авыл бюджетлары белән тәңгәлләшкән гаять зур суммада акчалар керә. Ә бу әлеге акчалар яклауга мохтаҗ дигән сүз – акча әйләнешенә карап, юридик шәхеснең устав капиталы күләменә тиешле таләпләр куярга, акчалар белән идарә итү тәртибен җайга салырга, юридик шәхеснең счетын ачу өчен кредит оешмаларын сайлап алу критерийларын билгеләргә, исәпләү үзәкләрендәге акчаларның, физик затларның банк счетындагы кертемнәре кебек үк, дәүләт гарантияләгән страховкага эләгүләрен булдырырга кирәк.

Икенчедән, исәпләү үзәкләре халыктан акча җыеп һәм бүлеп кенә калмый, фатирга түләүне исәпли һәм түләү документларын формалаштыра, һәм бу иң заманча программа нәтиҗәләрен кулланылуны таләп итә. Кулланыла торган программаларда түләү документларының соңгы формасында бүген шулай ук бертөрлелек тә юк.

Өченчедән, санауларны һәм түләүләрне исәпләү үзәкләре аша мәҗбүри үткәрү таләпләренең булмавы аерым идарә оешмаларының җыелган акчалардан контрольсез файдалануына, шулай ук исәпләмәләр буенча еш үзгәреп торучы закон таләпләрен үтәмәүгә китерә. Җаваплылыкның бердәм үзәге булмаганда, идарә итү ысулы алышынган очракта исәпләмәләр һәм гражданнардан акча җыю буенча мәгълүмат базаларының саклануын тәэмин итү кыен.

2014 елдан Казанда бердәм исәпләү үзәге эшли, аның белән шәһәр торак фондының 80% тан артыграгына хезмәт күрсәтүче 35 идарә оешмасы килешүләр төзеде. Хакимият органнары өчен исәпләү үзәге – ул, беренче чиратта, мәгълүмат ресурсы: тармакның финанс-икътисад хәленә анализ ясау, гражданнарның мөрәҗәгатенә квалификацияле җаваплар әзерләү өчен кирәкле бик зур мәгълүматлар базасы. Моннан тыш, БИҮ муниципалитетка идарә итүче оешмаларның халык акчасын максатчан файдалануларына ведомстволы контрольлек итүне тормышка ашырырга мөмкинлек бирә. Муниципаль торак хуҗасы буларак, һәм шулай ук барлык шәһәр халкы мәнфәгатьләрен чагылдырып, Башкарма комитет, хезмәт күрсәтү белән тәэмин итүчеләргә һәм подрядчы оешмаларга акча күчерүне үзара яраштырып, эшнең үтәлүенә һәм халыкка хезмәт күрсәтүгә контрольлек итә.

Казанда исәпләмәләрне һәм акча җыюны Бердәм исәпләү үзәге аша оештыру буенча шактый зур тәҗрибә тупланды. Бүген БИҮ базасында исәпләмәләр буенча барлык закон таләпләре үтәлә; бердәм түләү документы кабул ителгән; түләүне, кайда яшәвеңә карамастан, шәһәрнең теләсә кайсы почмагында башкарырга мөмкин; оешманың югары квалификацияле персоналы ярдәмендә программа нәтиҗәсе дә камилләшә бара. БИҮ исәпләмәләр билгеләү һәм субсидияләр түләү өчен капиталь ремонт буенча Төбәк операторы һәм социаль яклау органнары белән үзара бәйләнештә тора.

Шуңа күрә исәпләү үзәкләренең максималь нәтиҗәлелегенә ирешү, халык акчасының якланган булуын тәэмин итү, ТКИ түләүләре өлкәсендә гамәлдәге барлык закон таләпләрен үтәү өчен исәпләү үзәкләре эшчәнлеген көйләүче тиешле норматив-хокукый актлар кабул итәргә кирәк.

PRESSA.RU

«ЯРАМАГАН – БАЛА-ЧАГАГА!»

Нинди генә сәер исемнәр юк: Даздраперма, Трактор, Карамель, Универсиада... Ә Ренат, Ленар, Дамир, Эльмира кебек исемнәргә гадәти итеп карыйбыз. Нигездә алар совет чорыннан калган, аббревиатура, ягъни берничә сүзне кыскартып ясалган исемнәр: Ринат, Ренат («революция, наука, труд»), Ленар («Ленин армиясе»), Дамир («да здравствует мировая революция!»), Эльмира («электрификация мира») һ.б.

Автор:
Руфия Фазылова

«Дөрес» булмаган мондый исемнәргә каршы дәүләт югарылыгында көрәшергә булдылар. Июнь аенда ТР Дәүләт Советы яңа закон кабул итте. Гаилә кодексына үзгәрешләр кертү хакында шундый ук закон язын РФ Дәүләт Думасында кабул ителгән иде. Аның нигезендә әти-әниләр баласына сан, хәрефле-санлы билгеләр, хәреф булмаган тамгалар, аларга кушымталар кергән исемнәр бирергә тиеш түгел. Шулай ук сүгенү сүзләре куллану, вазыйфа, титул, рангларны күрсәтү дә рөхсәт ителми. Халык арасында бер фикер йөри: аббревиатурадан торган исемнәрне кушарга ярамый икән. Нәрсә, хәзер Дамир, Ринат кебек исемнәр юкка чыгачакмы? Тагын бер борчыган сорау: яңа туган баласына ата-ана үзе теләгән исемне куша алачакмы?

«УЛ ЧОРДА АНДЫЙ ИСЕМНӘР МОДАДА ИДЕ...»

Яңа законның тәртипләре хакында – соңрак. Башта сәер дә, кызык та булган исемнәр хакында сөйләшик әле. Бу уңайдан бер мәзәк тә искә төште.

Бер кешенең улы туган. Куршесе аңардан сорый икән:

– Нинди исем куштыгыз соң?
– Джек.
– Абау! Эт исеме түгелме соң ул?
– Әй, ярамаган тагын бала-чагага...

Совет чорында татарлар, русларга әйтергә җиңелрәк булсын, дип, интернациональ исемнәр кушкан: Руслан, Регина, Денис... Татарлар ул яктан, мөгаен, исемнәр мәсьәләсендә иң күп зыян күргән халыктыр. Бер генә рус яки яһүднең дә татарга әйтергә җиңел булсын, дип, исем алмаштырганын белмим. Руслан, Региналарның күп булу сәбәбе исә икенче нисбәткә дә бәйле: катнаш никахлар. Гадәттә, андый вакытта, ике якка да уңай булсын өчен, ата-аналар интернациональ исем куша. Ә менә Камал театрының музей мөдире Луара ханым Шакирҗанның исем белән бәйле тарихы бөтенләй икенче:

– Без гаиләдә дүрт бала, барыбызның да исемнәре зур елга атамалары белән бәйле, – дип сөйләде Луара ханым. – Әти-әнием – интеллигенция вәкилләре. Шуңа алар, үзенчәлекле булсын, дип, балаларына зур елга исемнәрен биргәннәр: Амур, Нил, Лена, Луара. Кечкенә, үсмер чакта мондый исемнәр йөрткәнебезгә гаҗәпләнмәдек. Ул чорда хәтта мода иде алар. Бары соңрак, халык дингә кайта башлагач кына,

мин дә үз исемем турында уйлана башладым. Һәм Луараны Зөһрәгә алмаштырдым. Казанда яшәгәндә Равил хәзрәт Гайнетдин гаиләсе белән аралаша идек. Хәзрәтнең тормыш иптәше Зөһрә атлы. Миңа бу исем бик ошады...

Мулла Зөһрә дип кушса да, Луара Шакирҗанга күпләр элеккеге исеме белән эндәшә икән. Бары аерым берничә кеше, бик якыннары гына, Зөһрә, ди.

Абыйларым үзләренең исемнәрен алмаштырмадылар, аларның моңа әллә ни исләре китмәде, – ди Луара (Зөһрә) ханым. – Ни кызганыч, Амур, Нил абыйларым инде гүр ияләре. Күңелдә бер үкенеч калды: үзебезчә мәгънәле мөселман исеме куштырасы калган. Алдан уйлап күндерә алмадым шул. Матур мәгънәле исем – бәхет чыганагы, дип уйлыйм.

Сәнгать өлкәсендә кайнаучы тагын бер ханым – артист, тамада Аграфена Васильеваның исә берьюлы берничә исеме бар: Груня, Гөрпинә, Груша...

– Түбән Кама районының Келәтле исемле гүзәл авылында туганмын, – дип сөйләп китте Аграфена ханым. – Авылдагы бөтен титуллар белән әйтсәк: «Бүре Бәчелие кызы Марҗук белән Җабалак Симонының Унтун кызы Гөрпинә» булам мин. Тугач та шулай атарга уйлаганнар. Авыл советында исә мондый исемне язарга рөхсәт бирмәгәннәр, Аграфена дип теркәгәннәр. Бәләкәй вакытта, үртәп, «Гөрпинә Гөберле бака» дип тә әйтәләр иде. Үсә-үсә андый үртәүләр бетте. Үз исемемне бик яратам. Милләтем буенча керәшен татары мин. Бездә Аграфена изге исем санала, «саклаучы фәрештә» мәгънәсендә. Христианнарда «Аграфена Купальница» дигән көн бар, ул 6 июньгә туры килә ул. Бу көннән соң аерым бер үләннәрне җыярга кушалар, шифасы күп була.

Аграфена Васильева исемне алмаштыру хәерле түгел дип саный:

– Минем танышларым арасында, яңа исем кушылгач, тормышлары гел кирегә тәгәрәгән кешеләр бар. Хәтта фаҗигале төстә һәлак булучылар да очрады. Бездә шундый ышану яши: балага исем кушканда, аңа бер фәрештә иңә, ул аны саклап, яклап тора. Әгәр инде олыгайган көндә исемеңне алмаштырасың икән, теге фәрештә урынына икенчесе килә. Ә ул сабый бала кебек яшь була, димәк, олы гәүдәле кешене саклап бетерә алмый.

«БОРЧЫЛЫРГА СӘБӘП ЮК»

Гаилә кодексына үзгәрешләр кертү турындагы законга килик. Аны Дәүләт Думасы депутатлары агымдагы елның 21 апрелендә кабул иткән иде. Санаулы көннәрдән соң, Президент Владимир Путин дә законга кул куйды. Шулай итеп, үз чиратында ТР Дәүләт Советының 29нчы утырышында «ТР Гаилә кодексына үзгәрешләр кертү турында»гы закон проекты кабул ителде. Моңарчы ЗАГС органнарының ата-ана сайлаган исемне теркәүдән баш тартырга хокуклары юк иде. Хәзер исә андый чикләүләр закон тарафыннан рөхсәт ителәчәк.

– Халык борчылмасын, бездә кайсы исемне кушарга ярый, кайсын ярамый дигән аерым китап юк, – дип тынычландырды ТР Министрлар Кабинетының Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсе башлыгы урынбасары Ренат Әхмәтҗанов. – Республиканың күпчелек ЗАГС органнарында исемнәр китабы бар. Гадәттә, колакка ишетелмәгән исем булса, безнең хезмәткәрләр шунда карап ала. Ямьсез яңгырашлы яки әйтергә җайсыз исем кушарга теләгән ата-анага икенче исем сайларга

PRESSA.RU

тәкъдим ителә иде. Хәзер дә бу шулай эшләнәчәк. «Татарстан Республикасы Гаилә кодексына үзгәрешләр кертү турында»гы ТР Законы ЗАГС хезмәткәрләре өчен исем кушканда бер таяну ноктасы булачак. Теге яки бу исемне ни өчен кушарга ярамаганны, ата-аналарга әлеге закон нигезендә аңлатачакбыз. Монда бер куркырлык нәрсә дә юк. Закон нигезендә, исемгә сан, хәрефле-санлы билгеләр, хәреф булмаган тамгаларны, аларга кушымталар тагарга ярамый. Шулай ук сүгенү сүзләре куллану, вазыйфа, титул, рангларны күрсәтү дә рөхсәт ителми. Ә менә балага атасының исеме (отчество), ата-ана ризалыгы белән милли традицияләр нигезендә, «улы» (ир бала өчен) сүзе, «кызы» (кыз бала өчен) сүзе өстәргә мөмкин дигән нигезләмә сакланып калды. Андый очраклар да бар. Дәүләт Думасында депутатлар башта аббревиатурадан торган исемнәрне дә тыярга кирәк дип фикер алышкан иде. Тик, бу очракта бәхеткә дияргәдер, аларга тимәделәр. Ринат, Ленарлар иң киң таралган исемнәр бит!

– Аббревиатурадан торган исемнәрне калдыруны сорап, Дәүләт Думасына хат юллаган идек, – диде ТР Министрлар Кабинетының Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсенең хокук, кадрлар эшләре һәм оештыру бүлеге башлыгы Ольга Захаренко. – Беренчедән, андый исемнәр бездә күп, икенчедән, мәгънәсе, яңгырашы ягыннан матур. Депутатлар безнең сүзгә колак салды: элек кушылган аббревиатурадан торган исемнәр кулланылышта кала. Аларны яңа туган сабыйларга алга таба да кушарга рөхсәт ителде. Ә менә берничә сүзне кыскартып ясалган яңа исемнәр бик хупланмый. Бу очракта аның мәгънәсен карарга, тикшерергә кирәк булачак.

Соңгы елларда татарстанлылар балаларына күбрәк дини исемнәр куша башлаган. Шулай ук кино, эстрада йолдызларының исемнәре, төрле мифик геройларның, тарихка кереп калган шәхесләрнең исемнәре дә популяр икән. Мисал өчен: Жасмин, Аврора, Эсмеральда, Тамерлан, Чыңгыз һ.б.

ИСЕМ ХИКМӘТЕ

Татар исемнәренә тукталыйк. Төрки халыкларда: «Башка милләт исемен кушу – башка халыкка әверелү» дигән гыйбарә дә йөргән. Гадәттә, исемне бала тугач та җиде көн эчендә кушалар.

Татар исемнәренең барлыкка килүе өч чорга бүленеп карала:

– Мәҗүсилек ырымнары, йолалары тәэсире булган борынгы төрки чор (I–X гасырлар). Бала таза, нык булсын дип хайван, киек кошлар, затлы булсын дип, төрле металл атамаларын исем итеп кушканнар. Мисал өчен: Шаһбаз (бөркет), Карлыгач, Арыслан, Зөмрәд, Энҗе һ.б.

– Ислам дине һәм шәригать кануннары йогынтысы булган чор (X–XX гасыр башы): Болгарда Алмыш хан тарафыннан 922 елда Ислам дине кабул ителгәннән соң гарәп исемнәре керә башлый: Мөхәммәт, Йосыф, Гайсә, Муса, Зәкәрия, Зөлхиҗә һ.б.

– Октябрь инкыйлабыннан соңгы чор (XX гасыр башыннан алып, хәзерге чорга кадәр): рус һәм Көнбатыш Европа илләреннән кергән исемнәр популярлаша. Мәсәлән, Радик, Артур, Эрнест, Альберт һ.б.

Филокартист, диктор Абдулла Дубин исемнәрне ныклап өйрәнгән затларның берсе. Бу турыда аның аерым хезмәтләре дә бар.

– Иске Казан сурәтләрен эзләгән вакытта бер китапка юлыктым: исемнәрнең кеше тормышында зур роль уйнавы турында язылган иде анда, – дип сөйләде Абдулла абый. – Шуннан бу тема белән кызыксынып киттем. Кеше исемнәрен өйрәндем. Шуны әйтә алам: исемдәге баш хәреф зур көчкә ия. Миңа 68 яшь тулгач дөньяга килгән кызыма «Мәрьямиям» дип куштым. «М» хәрефе – тырыш, актив, «Я» – иҗади, яхшы күңелле дигән мәгънәгә ия. Кызык өчен генә тикшереп карагыз: исемнәре «А» хәрефенә башланган кешеләр көчле рухлы, нык холыклы, власть яратучылар (Айдар, Айгөл һ.б.) «Б» – тотрыклы, үз максатына ирешүчән, «В» үзгәрүчән кешеләр, үз фикерендә, сүзендә тора белмәү сыйфатлары хас, «Г» – намуслы, мөстәкыйль, «С» – салкын акыл белән эш итә торган, көйсез, «Р» хәрефенә башланган кешеләр тиз кызып китүчән, ышанучан булалар. Иң беренче чиратта әтисенең исеме зур роль уйный.

Татар телендә ялгызлык исемнәрен һәм аларның килеп чыгышын ныклап өйрәнү XIX йөзнең икенче яртысыннан башлана. Бу өлкәгә Ш. Мәрҗани, К. Насыйри, Г. Әхмәров, В.В. Радлов, В.К. Магницкий, Н.И. Золотницкий, С.М. Шпилевский, Н.И. Ашмарин, И.А. Износков, Г. Тукай һ.б. үзләреннән зур өлеш керткән.

Октябрьдән соң да ономастик материалны җыю эше дәвам иткән. Г.В. Юсупов, Р.Х. Субаева бу өлкәдә эшли. 1963 елдан башлап татар ономастикасын Г.Ф. Саттаров өйрәнергә керешә. Татарларда кеше исемнәренең тулы картинасы аның тарафыннан болай тасвирлана:

- бик борынгы чорга караган борынгы гомумалтай исемнәре: Алтын, Алтынбикә, Алтынчәч, Байбуга, Ишбуга, Тайбуга һ.б.;
- борынгы төрки катлам: Айбикә, Айтимер, Илбарыс, Килдебәк, Толымбай, Юлкотлы һ.б.;
- иске татар теле катламы: Айсылу, Таңсылу, Алмас, Туйбикә, Айдар, Сөенбикә, Таңбикә, Ханәкә, Сайман һ.б.;
- гарәп теленнән кергән катлам: Габдулла, Госман, Нурия, Рамазан, Әлфия, Сания, Әхмәт, Һади һ.б.;
- фарсы теленнән кергән катлам: Бану, Гәүһәр, Гөлзадә, Гөлсинә, Зифа, Нияз, Рушан, Сәрвәр, Рөстәм һ.б.;
- татар, гарәп һәм фарсы исемнәреннән гибридлашып ясалган катлам: Акназар, Фәезхан, Әсмабикә, Тимершан, Маһибәдәр һ.б.;
- рус теленнән һәм Европа телләреннән кергән алынма исемнәр: Лена, Роберт, Альбина, Клара, Эльза, Альберт, Марат һ.б.;
- Октябрьдән соң формалашкан яңа татар исемнәре катламы: Айгөл, Айзирәк, Гөлүсә, Илдус, Илшат, Илсөяр, Иркә һ.б.

Хатын-кыз берничә мәртәбә кияүгә чыгып, фамилиясен үзгәртергә мөмкин, ләкин барыбер аңа беренче, кыз фамилиясендәге хәрефләр йогынты ясый. Ата-аналарга сүзем шул: балага исемне уйлап бирегез. Модага ияреп, әллә нинди колак ишетмәгән исемнәр кую – ахмаклык. Мода уза ул, ә балага шул исем белән яшәргә кирәк бит. Татарстанда исем алмаштыру шактый киң таралган күренеш, аеруча мөселманнар арасында. Дөрес, яңа документлар эшләтәсе була, дип, күпләр аны ЗАГС идарәсенә барып теркәтми. Шуңа күрә дә төгәл статистика турында сүз йөртеп булмый.

«Туган авылым» мәчете имам-хатыйбы Илнар (Нурулла) хәзрәт Зиннәтуллин ярты ел элек исемен алмаштырган. Бу хакта менә нәрсәләр сөйләде ул безгә:

– Кешенең исеме аның язмышына, тормышына турыдан-туры тәэсир итә. Галимнәр моны раслады. Кешеләр программалашырга сәләтле. Көн саен нәрсәдер әйтеп торсаң, нигәдер игътибарын юнәлтсәң, адәм баласы ул шулай була, дип ышана башлый. Ә кеше көн саен иң күп ишеткән сүз нинди? Үз исеме! Начар исемнәр хәтта ниндидер авырулар китереп чыгарырга мөмкин. Ә яхшы исем, үз чиратында, авыруны дәваларга ук сәләтле. Мисал өчен, бала миңле булып туса, аңа Миңлебикә, Миңсылу исемнәре куша торган булганнар. Һәм миң акрынлап юкка чыккан. Шулай ук кеше авырса, сәбәбен белмәгән очракта, исемен алмаштырганнар. Авыруның хәле чынлап та яхшырып киткән. Минем исемем, ягъни Илнар, мөселманнарда тыелган булмаса да, авыр исем: «ил уты» дигәнне аңлата. Тормышта бөтен нәрсә авырлык белән килгән кебек булды миңа, ут эчендә яшәгән кебек. Ә Нурулланың мәгънәсе: «Аллаһның нуры». Ут кебек якты, ләкин пешерми, ә җылы, нурлы. Уттан бераз китәр өчен шулай эшләдем. Шәригать буенча, ата-анасы балага, белмичә, тыелган, мәгънәсез исемнәр кушкан очракта аны алыштырырга кирәк. Хәтта мәгънәсе начар, ислам диненә туры килмәсә, исемне үзгәртү мәҗбүри дияр идем.

БУ КЫЗЫК!

БОЧ рВФ 260602. Рәссам Вячеслав Воронин белән реставратор Марина Фролова үзләренең балаларына шундый исем кушарга теләп, ничә еллар буе көрәштеләр. Тик Мәскәүнең ЗАГС идарәсе, аннан берничә суд та ата-анага мондый исемне куярга рөхсәт итмәде. Хәрефләрнең аңлатмасына килгәндә ул түбәндәгечә: «Биологический Объект Человек рода Ворониных-Фроловых». Ә саннар баланың туган көне, ае, елын күрсәтә.

Малайларга кушылган сирәк исемнәр (2017):	Кызларга кушылган сирәк исемнәр (2017):
Акпер, Агаали, Әмирҗан, Ардольф, Батулла, Вилен, Давыд, Зариф, Илһам, Йосыф, Ирфан, Кир, Миңнехан, Роял, Самад, Туран, Уоррен Данил, Фоат, Чарльз;	Ада, Айя, Аят, Вета, Владлена, Гунай, Дариана, Дилноза, Зәйнәб, Зөләйха, Иркә, Климентина, Латыйфа, Луна, Нурана, Патрина, Сәйдә, Саяра, Сәвдә, Шушанна, Язгөлем.
Малайларга иң күп кушылган исемнәр (2017):	**Кызларга иң күп кушылган исемнәр (2017):**
Әмир, Тимур, Кәрим, Артем, Матвей, Кирилл, Егор, Данил, Александр, Камил.	Ясминә, София, Ралина, Арина, Милана, Виктория, Алисә, Азалия, Анастасия.

(Мәгълүматлар ТР Министрлар Кабинетының Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсеннән алынды).

PRESSA.RU

ГКЗ
ГЛАЗОВСКИЙ
комбикормовый
завод

ПОДБИРАЙТЕ КОМБИКОРМА ПРАВИЛЬНО!

Входит в группу компаний
КОМОС ГРУПП

ДЛЯ ЛИЧНЫХ ПОДСОБНЫХ ХОЗЯЙСТВ.

Комбикорма ЭКОНОМ – «Доброе подворье» разработаны специально для животных, которые содержатся в условиях домашних хозяйств с традиционной технологией выращивания. Необходимое количество питательных веществ, витаминов и минералов обеспечат здоровье и продуктивность ваших животных.

• Фасовка 5 и 25 кг. •

ДЛЯ ПРОМЫШЛЕННЫХ ЖИВОТНОВОДЧЕСКИХ КОМПЛЕКСОВ И ПТИЦЕФАБРИК.

Рецептуры комбикормов ПРОФИ разработаны с учетом рекомендаций от создателей пород и кроссов сельскохозяйственных животных и птицы, оптимальны для применения в условиях промышленных комплексов с интенсивной технологией выращивания.

• Фасовка 25 и 40 кг. •

Реклама

АДРЕСА ТОРГОВЫХ ТОЧЕК

УДМУРТИЯ

«Глазовский комбикормовый завод»
г.Глазов,
ул. Красногорский тракт, 15
Отдел продаж:
тел.:(34141)3-85- 33
Фирменный магазин:
тел.:(34141)3-81- 20

«Можгинский элеватор»
г.Можга,
ул.Железнодорожная, 93
Фирменный магазин:
тел.: (912)019-54- 60

УДМУРТИЯ

«Крестьянский рынок»
Завьяловский район,
уд.Пирогово, ул.Торговая, 1
тел.: (3412)62-33- 89

БАШКИРИЯ

«Янаульский элеватор»
г. Янаул,
ул. Социалистическая, 19А
Фирменный магазин:
тел.: (34760)5-95-93

ТАТАРСТАН

«Крестьянский двор»
г. Набережные Челны,
п. Сидоровка,
ул. Магистральная, 47 Б
тел.: (927)416-95-07

«ИП Садреев»
г. Чистополь,
ул. Привалова, 86
тел.: (917)905-95-85

«ИП Минабутдинова»
г. Казань,
Горьковское шоссе, 113 В
тел.: (919)633-83-32

ПЕРМСКИЙ КРАЙ

«Агро-Торг»
г. Пермь,
ул. Буксирная, 4
тел.: (922)24-34-224

КИРОВСКАЯ ОБЛАСТЬ

«Оникс»
тел.: (912)874-82-00
тел.: (912)852-31-93

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Чүлмәк ватыклары **НӘРСӘЛӘР** сөйли

Камил Исхаков бәрәңгене **НИЧЕК** кыздыра

Чатыртауга **НИЧӘ** яшь

КАЙСЫ шәһәр балконыннан таулар күренә

Якты Күл авылы тарихын **КЕМ** казып чыгарган



ЧҮЛМӘК КЕНӘ, ДИМӘГЕЗ...

Керамика, ягъни балчыктан әвәләп эшләнгән савыт-саба һәм дә төрле хайван, кош-корт рәвешендәге бала-чага уенчыклары археологик казу эшләре вакытында иң еш очрый торган табылдыклардан санала. Аларда бик бай тарихи мәгълүмат «яшеренгән». Әле археологик разведкалар үткәргәндә үк, моңа кадәр билгеле булмаган берәр яңа объект, әйтик, борынгы авыл урыны табып алсак, өч-дүрт чүлмәк китегенә күз төшереп, әлеге объектның кайсы гасырга караганын һәм биредә нинди халык яшәгәнен шактый ук төгәллек белән әйтеп бирә алабыз. Нәкъ менә шуңа күрә дә инде археологлар керамиканы җентекләп, төрле ысуллар кулланып өйрәнәләр.

Авторлар:



Вера Бахматова

Фаяз Хуҗин

«ГОМУМБОЛГАР» КЕРАМИКАСЫ

Болгар илендә чүлмәк җитештерү шәһәр һөнәрчелегенең иң алдынгы тармакларыннан саналган. Чүлмәкчеләр бик югары сыйфатлы һәм киң ассортиментлы продукция җитештергәннәр. Алар арасында аш-су пешерергә җайлаштырылган казан һәм 3–5 литрлы, артык зур булмаган чүлмәкләр, пешкән ризыкны салып өстәлгә куя торган тәлинкәләр, җамаяклар, кувшиннар һәм башка төрле аш савытлары, ашамлык продуктларын (он-ярма, ит-май, сөт) саклау өчен махсус ясалган хум, корчагаише күләмле, 20–30 литр сыйдырышлы чүлмәкләр, һәр гаиләдә кулланыла торган яктырткыч лампалар бар. Бала арбалары, бишек төпләренә урнаштырыла торган «стаканга охшаш туваклар («бала чүлмәкләре»), кара һәм төсле металлургиядә кирәкле терекөмеш саклау өчен махсуслаштырылган сфероконуслар еш табыла.

Бу савытларны елга комы кушып изелгән кызыл балчыктан чүлмәк түгәрәкләрендә ясаганнар, бераз кояшта киптереп алганнан соң, махсус таякчыклар (лощило) белән шомартып-ялтыратып алганнар, гади генә, әмма бик зәвыклы итеп дулкынсыман бизәкләр төшергәннәр, аннан соң кайнарлыгы 700–800 градуска җитә торган махсус мичләрдә (горннарда) яхшылап яндырганнар.

Күрәсең, практик яктан чыдам, ә формасы белән бик матур булгангадыр, болгар чүлмәкчеләре җитештергән савытларны сәүдәгәрләр күрше халыкларга, бигрәк тә рус кенәзлекләренә илтеп сата торган булганнар. Мәскәү, Суздаль, Муром, Владимир, Белоозеро, Ростов, Бөек Новгород, Түбән Новгород, Киев, Чернигов кебек шәһәрләрне казыганда болгар чүлмәкләре еш табыла. Алай гына да түгел, Суздаль тирәсендә археологлар болгар чүлмәкчеләре эшләгән остаханә калдыкларына тап булдылар. Биредә ике ярусы түгәрәк горннар (аскы катта – утын ягып җылыту, өстә – әзер продукция яндыру камералары) сакланып калган. Диаметры һәм биеклеге икешәр метрга җитә торган әлеге мичләр монголларга кадәр-

Фотолар автордан алынды

ге чорда бары тик болгарларда гына булган. Рус һөнәрчеләре чүлмәкләрне гади мичләрдә – учакларда яндырганнар, шуңа күрә алар җитештергән продукциянең сыйфаты түбән булган. Бары тик XIV йөздә генә болгар чүлмәкчеләренең турыдан-туры йогынтысы астында кайбер рус шәһәрләрендә, мәсәлән, Мәскәүдә кызыл балчыклы чүлмәкләр ясарга өйрәнгәннәр.

Болгар шәһәрләрен һәм авылларын казыганда табыла торган кызыл балчыклы керамиканы фәндә «гомумболгар керамикасы» дип атыйлар. Ул барлык керамик табылдыкларның якынча 94–95 процентын тәшкил итә. Калган 5–6 проценты махсус станок – чүлмәк түгәрәге кулланмыйча, кулдан гына әвәләп ясалган савыт-сабага туры килә. Формалары, җитештерү технологиясе, бизәлеше ягыннан алар бик төрле. Шуңа күрә дә аларны археологлар бик кызыксынып өйрәнәләр. Төрлелекнең сәбәбе шул: әгәр дә кызыл балчыклы һәм яхшы сыйфатлы гомумболгар керамикасын, исеменнән үк аңлашылганча, болгарлар үзләре җитештерсәләр, кулдан эшләнгән, ярыйсы ук архаик, әйтергә кирәк, тупас савыт-саба болгарларга килеп кушылган башка халыкларга мөнәсәбәтле. Болгар керамикасы буенча күренекле белгечләребез Т.А. Хлебникова һәм Н.А. Кокорина әлеге керамиканы ике дистәгә якын этномәдәни төркемгә бүлеп карыйлар. Без аларның һәрберсенә тукталып тормабыз, әмма кайбер төркемнәр турында мәгълүмат биреп китмичә ярамас. Түбәндә язылганнар укучыларыбыз өчен аңлаешлырак булсын өчен шуны искәртеп үтәбез: керамиканың этномәдәни төркемнәрен галимнәр береч чиратта теге яки бу халыклардагы/кабиләләрдәге чүлмәкчелекнең технологик үзенчәлекләренә карап билгеләр. Бу үзенчәлекләр балчык савыт-саба ясау өчен чимал әзерләгән чорда ук башлана. Карьердан казып чыгарылган кызыл балчыктан турыдан-туры измә ясамыйлар, чөнки ул артык майлы була, андый балчыктан ясалган савыт-саба мичтә яндырганда чатный, яраксызга әверелә. Балчыкның майлылыгын киметү өчен аңа елга комы, тирес, төелгән бака кабырчыгы, кош йоны, туралган үлән, вакланган таш һәм башкаларны кушалар. Бу өлкәдә һәр халыкның үз традициясе була. Шундый ук традицияләр савыт-сабаларның формасында, аларны бизәүдә дә күзәтелә.

ҮЗЕ МӨҺЕРЛЕ, ҮЗЕ ЧЫРШЫЛЫ

Болгарлар әле Хәзәр дәүләте чикләрендә, Азов-Дон буйларында яшәгән чорда ук бик үзенчәлекле, күрше халыкларныкына охшамаган савыт-саба җитештерә торган булганнар. Чүлмәкләр көрән төстәге балчык составына туралган үлән яисә шамот – төелгән иске чүлмәк ватыклары кушып кулдан әвәләп ясалган (соңыннан өлешчә чүлмәк түгәрәкләрендә эшкәртелгән); өслеге параллель сызыклар белән сырланган, иңнәре дулкынга охшаш рәсемнәр белән бизәлгән. VIII гасыр урталарында Урта Иделгә күчеп утыргач та, болгарлар традиция буенча шундый ук савыт-саба җитештерүләрен дәвам иткәннәр. Ул бары тик X гасыр ахырларында, кулланылышка югарыда тасвирлап үтелгән яхшы сыйфатлы гомумболгар керамикасы кергәч кенә, юкка чыга. Сүз уңаеннан исегезгә төшереп китим: әлеге этномәдәни төркемгә кергән савыт-саба фрагментлары (фән телендә «салтово-маяк тибындагы керамика» дип йөртелә) Казан кремлендә дә табылган иде, һәм алар башкалабызның барлыкка килү вакытын ачыклауда әһәмиятле роль уйнадылар.

X гасыр башларында болгарлар яшәгән шәһәр-авылларда тагын бер этномәдәни төркемгә караган савыт-саба пәйда була. Фәндәге исеме – «постпетрогром» тибындагы керамика (беренче мәртәбә Екатеринбург шәһәре тирәсендәге Петрогром тавы итәгендә табылган). Бу төркемгә кергән савытлар да кулдан эшләнгән, әмма аларны башка төркемдәгеләр белән һич бутый алмыйсың: барысы да түгәрәк төпле, цилиндр муенлы, балчыгы составында – вакланган бака кабырчыгы. Бизәлеше дә бик үзенчәлекле: муенында рәт-рәт булып шнур, үрелгән бау эзләре, иңнәрендә тарак тешләренә охшаш штамп «сугып» ясалган зигзаг яисә чыршы сурәте (фәндә «гребенчато-шнуровая керамика» дип йөртелә). Әлеге керамика безнең якларга Урал таулары тирәсендә, Кама елгасының югары агымы бассейнында яшәүче угыр кабиләләре белән бергә «күчеп» килгән. Бер төркем галимнәр әлеге керамиканың килеп чыгышын шул ук территориядә яшәүче финнар – коми-пермяк һәм удмуртларның борынгы бабалары белән бәйләп аңлаталар. Болгар дәүләтенең Кама аръягында урнашкан үзәк өлкәләрендә «постпетрогромлылар» болгарлар белән аралашып бетәләр.



Яндырырга куелган чүлмәк.

Постпетрогром кабиләләрнең Идел Болгары җирләренә күчеп утырулары XI–XII гасырларда да дәвам итә. Аларның күбесе Алабуга, Кирмән калалары җирлегендә һәм аның тирә-юнендә туплана. Хәзерге Татарстанның көнчыгыш районнарында яшәгән «постпетрогромлылар» Алтын Урда чорында Чиялек археология культурасын барлыкка китерәләр. Әлеге культура кабиләләре, галимнәр фаразлавынча, башкорт халкының килеп чыгышында катнашалар.

Тагын бер үзенчәлекле төркем нык аерылып тора болгар керамикасыннан. Ул да булса безнең фин күршеләребез кулланган савыт-саба. Борынгы марилар ясаган чүлмәкләр бик примитив:

PRESSA.RU

Рәсемнәрдәге чүлмәкләр тарихыбызның шаһитлары һәм истәлекләре булып тора.

өй шартларында кулдан гына әвәләп эшләнгән, бизәкләре дә юк, уачкта яндырылган, кыскасы, начар сыйфатлы, хуҗасына озак хезмәт итмәгәндер алар. Мондый савыт-саба китекләре Казан кремленнән дә табып алынды. Ләкин алар күп түгел, болгарлар арасында яши башлаган марилар үзләре алып килгән савыт-сабадан озак файдаланмаганнардыр, күрәсең, базардан очсызга гына яхшы сыйфатлыларын сатып ала башлаганнардыр.

Ә менә борынгы удмуртларның (ломоватово, чепец, полом кабиләләре) савыт-сабалары сыйфатлырак итеп ясалган, матур гына бизәкләре дә бар. Мондый керамика соңгы елларда Болгар казылмаларыннан, шәһәрнең IX–X гасырларда тупланган иң борынгы катламнарыннан чыкты.

Хәзерге Пермь яклары белән бәйләнгән, ягъни Урал буе финнарына (коми-пермякларга) мөнәсәбәте булган савыт-саба иң әүвәл Чистай шәһәре янында урнашкан Җукәтау каласында табыла, шуңа күрә ул фәндә «Җукәтау тибындагы керамика» дип йөртелә дә. Аның балчыгында эре ком бөртекләре ачык күренеп тора, формасы белән тирән булмаган киң авызлы, бер тоткалы савытлар. Төпләре яссы түгел, бераз түгәрәк. Иңнәрендәге бизәк күп зоналы текә дулкыннардан гыйбарәт. Әлеге савытларның башка халыклар арасында таралган төгәл аналоглары билгеле түгел, шуңа күрә аның Урал-Кама буйларында яшәгән халыкларныкы булуы мөмкин дигән гипотеза әлегә исбатланмаган килеш кала бирә.

КАЯН КИЛЕП ЧЫКЧАННАР?

Болгар истәлекләрен казыганда сирәк булса да Рус кенәзлекләреннән китерелгән савыт-сабалар да очрый. Хуш, русларның болгар шәһәрләрендә даими яшәүләре борынгы елъязмаларда да чагылыш тапкан. Сугышып та торганнар, сәүдә дә итешкәннәр, алар болгарлар белән «тел, лөгать, гадәт һәм әхлак алмашып» яшәгәннәр. Рус чүлмәкләре кара-көрән төстә, өслеге параллель сызыклар белән бизәлгән, начар яндырылган. Мондый чүлмәкләрне алар үзләре белән алып килгәннәр, әмма бе-

раздан болгар савыт-сабасыннан файдалануга күчкәннәр.

Болгарлар белән Көнчыгыш Европа далаларында яшәүче күчмән төрки халыклары арасындагы багланышлар гасырлар буена дәвам иткән. X йөздә алар бәҗәнәкләр, XI йөздән башлап кыпчаклар белән аралашып яшиләр. Күчмәннәрнең бер өлеше Идел Болгары территориясенә дә үтеп керә дип әйтергә нигез бар, чөнки аларның культурасына хас әйберләр, шул исәптән кулдан эшләнгән савыт-саба фрагментлары еш табыла. Болгар теленең кыпчаклаша башлавы да монгол яуларына кадәрге чорга туры киләдер, мөгаен.

Күргәнебезчә, төрле халыклар калдырган традицион керамика болгар халкының килеп чыгышын, Урта Идел һәм Урал буе татарларының этник тарихын өйрәнүдә бай мәгълүмат бирә алырлык тарихи чыганак булып тора. Әлеге чыганак болгарларның күп төрле этник компонентлардан торганлыгын бик ачык күрсәтә.

Тагын бер тапкыр яхшы сыйфатлы гомумболгар керамикасына күз төшерик. Каян килеп чыккан ул? Күрше-тирә халыкларында юк бит мондый формалар – кувшиннар, хумнар, яктырткыч лампалар, туваклар, сфероконуслар.

Кайбер галимнәр мондый формаларның килеп чыгышын һәм безнең төбәкләрдә таралышын антик чор истәлекләре белән бәйләргә тырыша. Имеш, Борынгы Грециядә һәм Римдә кулланылышта йөргән савыт-саба формалары һәм аларны ясау технологиясе Хәзәр каганлыгы аша Идел болгарларына килеп җиткән. Бу версияне әлегә хуплап та, инкарь итеп тә булмый. Өстәмә тикшеренүләр үткәрергә кирәк. Шул ук вакытта болгар савыт-сабалары (бигрәк тә хумнар, туваклар, яктырткычлар) күп яктан Урта Азия халыкларыныкына охшаш. Кызганыч, Урта Азия һәм Болгар керамикасын чагыштырма планда өйрәнү проблемасы әлегә кадәр игътибардан читтә калып килә. Идел Болгарында табылган сфероконусларның күбесе импорт өлешенә туры килә, алар нәкъ менә Урта Азиядән һәм Кавказ аръягы дәүләтләреннән кителгәннәр.



PRESSA.RU

Камил Исхаковтан КЫЗДЫРЫЛГАН БӘРӘҢГЕ

«ТАТАРСТАН» МАХСУС ЖУРНАЛЫ ӨЧЕН

«Татарстан» журналының «Аш-су бүлмәсе» башны әйләндереп, аяктан егып салырлык тәмле итеп кыздырылган бәрәңге исенә күмелде. Ә без әле кыздырмадык та бит! Җыенабыз гына. Бүгенге кунагыбыз – Татарстан Президенты ярдәмчесе һәм Болгар ислам академиясе президенты Камил Шамил улы Исхаков үзенең шәп итеп ашарга пешерергә ничек өйрәнүе турында шундый тәмләп сөйли ки, гүя аның бу бәяны чынбарлыкка үтеп кереп, тирә-ягыбызны миллионлаган ватандашларыбызның яраткан ризык исе белән тутыра.

Автор:
Татьяна Вафина

Фото: Ната Смирнова

ТАТАРСТАН
Татарстан
ТАТАРСТАН
ВЕСТНИК

PRESSA.RU

Кирәк булачак:

- Бәрәңге – 2 кг
- Суган – 4–5 дanә
- Зәйтүн мае
- Тәменчә – тоз

ОЯТ...

Ышанасызмы-юкмы, «Татарстан»ның баш мөхәррирен, кайнанасыннан соң икенче кеше булып, бәрәңгене дөрес әрчи белмәгәне өчен, Камил әфәнде оятка калдырды.

– Кем инде шулай калын итеп әрчи? – дип канәгатьсезлеген белдерде ул һәм бәрәңгене, кабыгы искиткеч нәзек спираль рәвешендә сузылып барырлык итеп, әрчеп тә күрсәтте. Бу спиральдәге кабык шулкадәр юка ки, хәтта үтә күренмәле.

Оялудан тәмам кызарып чыккан баш мөхәррир, кулинария белән башка бәйләнмичә, үзенең төп вазыйфасына –әңгәмә коруга керешергә карар кыла һәм бәрәңгегә башка кагылмый.

ЯРЫШ ТУРЫНДА СҮЗ ДӘ БУЛА АЛМЫЙ!

– Камил әфәнде, кыздырылган бәрәңге – яраткан ризыгыгызмы?

– Гадәттә, мин бар нәрсәне дә ашыйм. Тик ничектер өйдә бер тапкыр бәрәңгене мин кыздыргач, ул гаиләбездә иң яраткан ризыкка әйләнде дә куйды. Соңыннан тагын кыздыр әле, дип, бик еш сорап йөрделәр... Ләкин инде күптән таба тотканым юк. Хатыннан бик уңдым, аш-суга кулы ята. Теләсә нәрсәне пешерә-әзерли ала. Бу мәсьәләдә ул чын оста. Өстәвенә, осталыгын камилләштерә бара. Мин исә, мөгаен, элек белгән нәрсәләремне дә онытып бетергәнмендер... Менә хәзер тикшереп карарбыз!

– «Ир-атлар сирәк пешергәнгә күрә тәмле пешерә» дигән фикер белән килешәсезме?

– Юк! Бу яктан мин һичнәрсәгә өмет итмим. Ярыш турында сүз дә була алмый! Хатыным һәрвакыт беренче булачак. Әле без танышкан комсомол вакытларында ук шулай иде. «Комсомол» дип аталган бик шәп мәктәп бар иде. Ни генә сөйләсәләр дә, партия дә, комсомол да – кешене ышану-ышандыру кораллары. Кеше һәрвакыт нәрсәгә дә булса ышанырга тиеш. Һичбер имансыз, бернәрсәгә дә табынмыйча яшәү мөмкин түгел.

ИМАН МӘСЬӘЛӘСЕ

– Инде шул ышанычны югалтып тормыш итүебезгә ничә ел...

– Шул «кәнфит»ебезне тартып алгач, яшьләребез үз мәшәкать-борчулары белән йөзгә-йөз калды. Комсомолга алмаш ясап карарга маташалар, әйтик, төрле яшьләр хәрәкәтләре, берлекләре, алар фәкать ахыргача уйланып бетмәгән, димме... Ни дисәк тә, берләштерүче һәм тәрбия бирүче көч буларак, асылда комсомолга алмаш юк.

Мин хәзер «Казан нуры» мәчетенең мәхәллә шурасы рәисе (әтиемнең киңәш-нәсихәтләренә зур хөрмәт белән карыйм) булып торам һәм кешегә иман кирәклеген гел күрәм. Яшьләр мәчеткә дә, чиркәүгә дә, бер сүз белән генә әйткәндә, гомумән дингә тартыла. Дин дәүләттән аерылган илдә шундый тартылу, кызыксыну бу. Аларны берәү дә мәҗбүриләми, үзләре килгәләр.

– Димәк, Аллага ышану теге комсомолга ышануны алыштыра ала?

– Мин үз күзәтүләремне, күн саен күргән нәрсәләремне генә җиткерәм.

Бәлки, бәрәңгене җитәрлек әрчегәнбездер? Табага сыярмы икән? Мин дә чамалап бетермим. Нигездә, миңа бәрәңге әрчү ошый. Кызыклы шөгыль. Тынычландыра...

Һәм без бәрәңге кабыкларының бөтерелә-бөтерелә сузылып төшүен өзмичә генә, әңгәмәне дәвам итәбез.

– Мин моны ни өчен сөйлим, – ди Камил әфәнде, – чөнки мәхәллә шурасы рәисе буларак, хуҗалык эшләре өчен җавап бирәм, мәчетне яшәтер өчен акча юнәтәм. Минем бурычым – мәхәллә халкы өчен бөтен мөмкинлекләрне тудыру. Ә аларның саны даими арта бара, бүлмәләр, урыннар торган саен җитми. Әле бер янкорма салабыз, әле икенчесен төзибез, чатыр корабыз, палатка куябыз... Ә урыннар тагын җитми! Менә бүген җомга – мөселманнар өчен изге көн. Җомга намазына хәтта кеше азрак була торган җәй көнендә дә бихисап халык килә. Тик бүген аеруча күп, аеруча ыгы-зыгы. Ләкин иманлы кешенең намаз алдыннан тәһарәт алырга да мөмкинлеге булырга тиеш. Димәк, су, краннар кирәк, алар янында этеш-төртеш, чират булмавы да мөһим. Шундый шартлар тудыру белән мәшгуль чагымда, җәмгыятьтәге рухи процессларның алга баруын күрәм. Бу безнең теләкләргә бәйле түгел. Ата-аналар да һичкемне куып китерми, җәмгыять тә бездә, Татарстанда, һичкемне мәҗбүриләми. Татарстанлыларның эш сәгатьләренә күз салсак, берәү дә мәчет режимына җайлашмаган иканлеген күрербез. Мәсәлән, көндезге сәгать 12 дә мәчеттә намаз вакыты, ә бу вакытка бездәге эш урынында җыелыш билгеләп куярга мөмкиннәр. Ягъни иҗтимагый тормыш динле, иманлы затлар режимын ислам дәүләтләрендәге кебек исәпкә алып көйләнми. Әмма кешеләр өйлә намазына, әйтик, төшке аш вакытында килергә барыбер җай таба. Бу – факт.

– Сез – дини академия президенты, шул ук вакытта дәүләт кешесе дә. Үзегезнең дингә мөнәсәбәтегез нинди? Ураза тотканыгызны беләбез. Авыр булдымы?

– Кешенең эчке халәте шундый булганда, бер дә кыен түгел. Ә вакыт ягын караганда, 19ар сәгать ашарга да, хәтта су да эчәргә ярамаган озын көннәр булды...

– Җиләс бүлмәләрдә диванга сузылып яту бер хәл, тик сез бит башкалар белән иңгә-иң, хәтта алардан күбрәк тә эшлисез?

– Ураза тотуым беренче ел гына түгел, күнеккән инде, сәламәтлек өчен дә файдасы бар бит: организм чистара.

Гафу итегез, мин монда сезне сөйләштереп, бәрәңгене онытып

җибәргәнмен. Бүген бәрәңгегә уң килә торган көндер. Дүртәү генә калган. Чистартып бетеримме?

Әрчеп бетерергә бездән ризалык алгач, Камил әфәнде калган бәрәңгеләрне дә кабыктан арындыру эшенә кереште. Һәм тиздән каршыбыздагы әрчелгән бәрәңге тау булып өелде, армиядәге һәр кухняда кызыгырлар иде моңа.

ШӘРЫК ҺӘМ КӨНБАТЫШ

– Бернична ел Россия белән ислам дөньясы арасында бәйләүче чылбыр буыны булып тордыгыз. Шәрык менталитетын яхшы беләсез. Бу өлкәдә нинди уңышларга ирештегез?

– Мине шулай бәйләгеч буын дип атавыгыз кызык. Мин Ислам конференциясе оешмасында (ИКО) Россия Федерациясенең беренче вәкиле булдым. Бу конференция 61 илне берләштерә: анда 57 әгъза һәм 4 күзәтүче дәүләт бар. Күләмлелеге һәм илләр саны ягыннан ул БМОдан соң икенче оешма булып тора. Җитди һәм саллы берлек. Россия анда бары тик Президентыбыз Владимир Владимирович Путин тырышлыгы белән генә эләгә алды. Ул дөньякүләм масштабта бик дөрес сәясәт алып барып, тормышның бу тарафын да онытмады. Малайзиядә узган ил башлыклары саммитында Владимир Владимирович Россиядә 20 миллион мөселман яшәвен белдерде, һәм аларның читтән килгәннәр түгел, ә җирле халык икәнлегенә басым ясады, шуңа күрә безнең исламга туры-дан-туры бәйләнешебез булуын раслады. Үз чыгышы белән ул бу вакытта бөтен ислам дөньясын уятып җибәрде һәм безне күзәтүче сыйфатында конференциягә кабул иттеләр. Мине даими вәкил итеп билгеләделәр. Моңа беренчел нигез әле 2005 елда ук салынган иде, ул вакытта Россия Президентының Ерак Көнчыгыштагы тулы вәкаләтле вәкиле буларак эшли башлаганда, бездән Ислам конференциясенә катнашачак делегацияне җитәкләү миңа йөкләнде. 2005 елның декабрь аенда Ислам конференциясе оешмасы Мәккәдә ил башлыкларының чираттан тыш саммитын уздырачагын игълан итте. Анда Владимир Путин да чакырылган иде. Ләкин мөселман булмаган кешегә Мәккәгә юл ябык, ә мөселман Исхаков кул астында гына иде. Шул рәвешле мин җитди ислам оешмасына беренче тапкыр эләктем. Һәм ИКОда күзәтүче булган Россия Федерациясенең тәүге делегациясен җитәкләдем.

КИЛӘЧӘК КУНАКЛАРЫ

– Хәзер Болгар ислам академиясенә җитәкчелек итәсез һәм «Татарстан» журналының август санындагы төп тема – «Киләчәк кунаклары» темасына (Татарстанда тормышка ашырыла торган яки киләчәктә эшләнәчәк проектлар турында) эләктегез. Болгар академиясе әнә шундыйлар хисабында. Яңа уку елында академия укытучылар коллективы белән тулысынча тәэмин ителгән хәлдә эш башлаячакмы?

– Сезгә мәгълүм булганча, быел 1 сентябрьдә Корбан бәйрәме – ул мөселманнарның зур бәйрәме. Болгар академиясен әнә шул бәйрәм уңаеннан ачу планлаштырыла.

Укытучылар коллективына килгәндә исә, аны туплау – шактый катлаулы процесс. Аны халыкара дәрәҗәдәге эш дип билгеләргә дә мөмкин, ә андый эшнең нинди кыенлыклар белән бәйле икәнен чамаларга була. Әйтик, без бер чит ил укытучысын чакыру өчен бик озак вакыт сөйләшүләр алып бардык. Чөнки череп чыккан дәһрилек чорында, гыйбадәтханәләрне җимергән елларда, без үз кадрларыбызны тәмам җуеп бетердек. Галимнәр, тәҗрибәле остазлар юк... Тыелган зона иде бит ул. Шунлыктан хәзер, дөньякүләм дәрәҗәдәге белән тиң булырлык, лаеклы белем бирү өчен, чит ил белгечләрен чакырырга мәҗбүрбез. Каһирәдән шундый бер галим белән уртак тел таптык, ул Болгар академиясендә хезмәт куячак. Ләкин кешене эшкә чакыру өчен, без әүвәл РФ Хезмәт министрлыгыннан квота алырга тиеш. Әлеге квотаны сорап февральдә мөрәҗәгать иттек, июльдә генә алуга ирештек. Тәртип шундый! Әлеге галим күп еллар Каһирәдә яши, әл-Әзһәр университетында эшли, шуңа күрә квотаны Мисырга дип алдык. Баксаң, ул Палестина гражданы булып чыкты! Рөхсәт алу тәгәрмәчен тагын тәгәрәтеп җибәрсәң генә... Квота бирү эшен тизәйтү турында сөйләшү өчен, миңа ашыгыч рәвештә хезмәт министрына юл тотарга туры килде. Квоталар, визалар – тиз эшләнә торган нәрсә түгел, ә безнең күп гамәлләребез шуларга бәйле. Шуңа күрә укытучылар коллективы тулысынча тупланган дип әйтә алмыйм әле.

– Кояшлы, җылы Каһирәдә яшәгән кеше безнең шактый салкын төбәккә күчеп килергә ничек ризалашты соң?

– Иң әүвәл ул – бөек галим кеше, һәм аның өчен яңа урындагы яңа эш фәнни кызыксыну уята. Өстәвенә, алты ел Палестина мөфтие дә булып торган, тормышта күп нәрсәгә ирешкән шәхес. Чит ил укытучылары өчәү булачак. Аларның монда күченү эшен оештыруда вакыт-вакыт бик зур кыенлыклар чыкты. Ләкин, ил күзлегеннән фикер йөрткәндә, шулай дөресрәктер дә. Болай тәртип күбрәк.

– Ә студентлар составы ни хәлдә?

– Студентлар туплау өчен, телеге булганнардан документлар җыеп алырга кирәк. Ә без – 9 августта гына лицензия алган оешма. Җитмәсә, шундый вакыт туры килде: Россиядә 1 ел да 9 ай һичбер югары уку йортына лицензия бирелми торды.

Камил әфәнде бәрәңгене әрчеп бетереп, аны озынча нәни борысчыклар итеп турарга кереште. Түгәрәк бәрәңгеләр өеме күз алдыбызда әнә шундый «борысчыклар» тавына әйләнә.

– Кыздыра башлаганбыз икән, бөтен Казанга җитәрлек булсын инде, – дип елмая ул.

«Татарстан» каршы түгел. Тәмлене сизеп, эчтә бүреләр улый башлады инде.

БЕЛЕМ ЙОРТЫ

– Ник ислам академиясен Казанда түгел, ә Болгарда ачарга карар кылынды? Татарның ата-бабалары ислам динен кабул иткән җир буларак әһәмиятенә карамастан, республиканың башкаласы күпкә уңайлырак ич.

– Мин элегрәк кабул ителгән карарлар турында сөйләшеп торуга беркайчан да вакыт әрәм итмәдем. Файдасыз гамәл, кирәкме ул? Рөстәм Нургалиевич белән Минтимер Шәриповичның миңа күрсәткән ышанычын хөрмәт итәм,

PRESSA.RU

һәм минем туп бурычым – эшләргә! Ахыр нәтиҗәдә Россиянең иминлеген тәэмин итәчәк уку йорты булдырырга. Чит илдә белем алырга мәҗбүр яшьләребезнең акылларына, күңелләренә үтеп кереп, бу дәүләтләрнең махсус хезмәтләре бик көчле йогынты ясый. Балаларыбыз белемне читтән эзләргә тиеш түгел, алар лаеклы белемне монда алсын.

Әйе, билгеле бер проблема бар: Болгарга юл өч сәгать ала, кайтыр өчен тагын өч сәгать кирәк – якын җир түгел. Ләкин син белгечлек алырга, белем тупларга телисең икән, моннан да яхшысы була да алмый, чөнки академия шәһәрдән ерак урнашкан. Бер мисал китерим. Казанның Меңьеллыгына әзерләнгәндә, биш ел дәвамында «Идел – Нократ төбәгендә православие» һәм «Идел – Нократ төбәгендә ислам» темаларына фәнни конференцияләр уздырдык. Аларга бөтен дөньядан галимнәр җыелды, кызып-кызып фикер алышты. Башта ул фәнни җыеннар Казанда узды. Һәм мин шуңа игътибар иттем: танышлары, дуслары яшәгән зур шәһәрдә чит галимнәр тәнәфес вакытында шулар янына шылу ягын карый. Төп эшкә зыян килә, чөнки барысы да каядыр ашыга. Шуннан соң без «Казан» теплоходына күчтек. Тәһраннан Ослога кадәр Бөек Идел сәүдә юлын кайтарган теплоход ул. Ябык тирәлеккә эләккән галимнәр шулкадәр нәтиҗәле хезмәт күрсәтте ки! Качып китәр, ашыгыр урын юк бит! Болгарда да әнә шундый мөмкинлек тудырылган. Анда алты торак кампусы төзелгән. Укыр өчен дә, яшәр өчен дә, фән белән шөгыльләнер өчен дә искиткеч уңайлы шартлар. Моның үз өстенлекләре бар. Чөнки безнең төп эшебез – яхшы белгечләр әзерләү, ата-бабаларыбызның эшен дәвам итеп, гыйльми тикшеренүләр алып бару. 1080 елда нәкъ менә Болгарда Дәрүл-Голүм – Белем йорты дип атаган университет булдырылган. Анда фәнни кадрлар әзерләнгән, монда чыккан 30 меңләп гыйльми хезмәтне бүген ислам дөньясында бу өлкә белән кызыксынган, аларның әһәмиятен аңлаган һәркем файдалана.

ИҢ МӨҺИМЕ – БАШЛАП ҖИБӘРҮ

– Болгар ислам академиясе исемнәре бар дөньяга билгеле башка уку йортларыннан ни белән аерылып торачак?

– Безнең башлап җибәрү нигезебез бик кызык. Йөзьеллык атеизм мәйданында эш башлыйбыз. Мондый старт урыны ислам уку йортларының барысына да «тәтеми». Шуның белән кызыграк та. Коръән конституция итеп каралган, халыклары Коръән кушканча яшәгән дәүләтләрнеке белән чагыштырганда, безнең старт мәйданы иң талымсызы. Әйе, мәсәлән, нефть чишмә булып җир астыннан бәреп торган Согуд Гарәбстаны кебек бихисап табигый байлыклар белән мактана алмыйбыз. Безгә аны тырышлык куеп, суыртып чыгарырга туры килә. Бездә бер баррель нефть чыгару 20 доллар яки аннан да кыйбатрак хакка төшсә, аларда исә – 2 доллар гына. Гомумән, аларда акча күп, мәгарифкә гаҗәеп зур акчалар бүлеп бирелә. Согуд Гарәбстанының бөтен акчасы Америкада саклана, димәк, алар университет төзесә, аны шундук өр-яңа технологияләр, америкалыларга хас иң югары дәрәҗәдәге техник процесслар, уку-укыту документациясе белән тәэмин итә. Һәм без шул югарылыкка күтәрелергә тиеш.

– Ул дәрәҗәгә ирешербез дә, лаеклы белем дә бирербез, тик ул белгечләрне ничек үзебездә саклап калырга?

– Хәзер беренче төркем генә тупланачак. Магистр әзерләү өчен өч ел кирәк, уку йортын тәмамлаучыларны эш урыннары белән тәэмин итү, аларга юлламалар бирү өчен, әнә шул өч елда безгә барлык мәсьәләләрне хәл итү зарур. Без магистрлар әзерлибез, ә алар соңыннан бакалаврларны укытырга тиеш. Россиядә бакалаврлар әзерли торган ун югары уку йорты бар, бездән магистрлар чыгуга, аларда эш урыннары әзер булырга тиеш. Яки инде уку йортын тәмамлаучылар мәчетләргә имам булып эшкә килә ала. Ләкин бу процессны контрольдә тоту мөһим, бу тармакта тәртип булдыру таләп ителә. Фикер-ниятләр бар, әмма аларның барысын да ачып салырга иртәрәк. Буш сүзләр генә булмасын өчен, һәр якны уйлап бетерергә кирәк.

– Шартлары да яхшы булырга тиеш. Яшьләр бит хәзер акча күбрәк түләнгән урынны сайлый. Ә аларга чит илдә эш тәкъдим итеп куйсалар...

– Тәкъдим итмәячәкләр. Чит илдә әлегә безнең белгечләрнең бәясе нульгә тигез. Чөнки аларның үзләренеке яхшырак.

– Сез бит бер-бер нәрсә уйлап тапмый калмыйсыз?

– Беләсезме, эш нәрсәдә: мин Рөстәм Нургалиевичка әнә шуңа күрә дә бу вазыйфага алынырга ризалык бирдем. Нигездә, мин дәүләт эшендә бик зур тәҗрибә туплаган кеше кебек, ләкин әлеге академиядә нindидер мөмкинлекләргә ия шәхес кенә алга куелган максатларга ирешә ала. Бу очракта минем Кириенко киңәшчесе булу да роль уйный. Сораулар миллион, һәм аларны югары дәрәҗәдә хәл итәргә кирәк.

– Азрак елап алабызмы? – ашчыбыз теманы кинәт читкә бора һәм суганга тотына. Тиздән анысы эре шакмаклар рәвешендә турап та куела.

– Болай хуш исе күбрәк, – дип аңлата Камил әфәнде.

Ул зур түгәрәк табага май сала.

– Менә сиңа мә! Килеп җиттек! – май савытын селкеткәләп, ашчыбыз ачыклык кертә. – Май азрак бит...

Без савытка зәйтүн мае салган арада, Болгар академиясе президенты Камил Исхаков белән Казан мэры булган Камил Исхаковны искә алабыз.

ДӨНЬЯГА ТАНЫЛГАН МЭР

– Сез – исеме дөньяга танылган мэр. «Казанские ведомости» газетасында бер мәкалә шундый башисем белән чыккан иде. Шәһәр башлыгы вазыйфасында башкарылганнарның кайсын иң төп уңышыгыз дип саныйсыз?

– Бу башисем, мөгаен, мин, Казан мэры булган чакта, Бөтендөнья мэрлар оешмасы рәисе урынбасары итеп билгеләнгәч чыккандыр. Эш болай булды. Бу системага баш төрткән чакта мэрларның берлекләре, оешмалары күп иде. Ә БМО

исә «сезнең белән эш йөртәсебез килә, тик бер оешма булып берләшә алмыйсызмы соң», ди. Ягъни берничә вак оешма белән элемтә кору уңайсыз. Мин, әлбәттә, бик гадиләштереп сөйлим...

Шуннан соң берләштерү процессы башланды. Озак барды ул. Биш ел буе устав әзерләдек. Әйтик, бер бүлек турында фикер алышырга җыелабыз. Мэрлар бер-берсе белән бәхәсләшә, уртак фикергә килә алмый, әллә нинди саз-чоңгылларга кереп чума... Мин тыңлап-тыңлап тордым да: «Егетләр, әйдәгез, менә болай эшлик», – дидем. Һәм кинәт барысы да ризалашты. Күрәсең, әнә шуның өчен мине идарә органы составына сайлап куйдылар да. Шул рәвешле мин төп оешма составына эләктем. Аннары тагын бер мәсьәлә: һәр урынбасар нидер бер континенттан яки берләшмәдән булырга тиеш. Шулчак без Евразия бүлекчәсен уйлап чыгардык. Мине бу бүлекчәнең президенты һәм дөньякүләм оешманың вице-президенты итеп сайладылар.

– Казан турында ул вакытта планетабызда бик аз беләләр иде. Ул нәкъ менә сезнең белән дөньяга ачылдымы?

– Мин һәрвакыт казанлыларга хезмәт итәргә тырыштым. Борчак чәчү түгел бу. Һәм иң зур уңышым, минемчә, хезмәтемне бәяләп, Казанда хөрмәт итә башлаулары. Моның хакына яшәргә дә була.

– Казанда яраткан урыныгыз бармы?

– Монда яратмаган урыным юк. Һәр почмагы җанга якын. Кайдадыр нәрсәдер җитешсезрәк икән, моңа бик борчылам. Мин дә барысын да эшләп өлгермәдем бит.

Гомумән, Казанда кунак кешене теләсә кая алып барырга була, кызарырга туры килмәячәк. Аеруча Кремльне күрсәтергә яратам. Кич Елга техникумы ягыннан дамбадан караганда бигрәк тә матур ул. Утлар белән балкып янып торган Кремль гаҗәеп зур су киңлекләрендә чагылып күренә...

Әлбәттә инде, миңа җәяүлеләр урамы – Бауман урамы да бик кадерле. Мэр вазыйфасына килгән чагым гына иде, миңа кадәргеләр Бауманда транспорт хәрәкәтен япты. Анда элек троллейбуслар йөри иде бит. Шул вакытта дуслар миңа сүз катты: «Камил, халык моннан соң да сине якласын дисәң, киләчәктә дә мэр булып калырга теләсәң, анда хәрәкәтне янә ачып җибәр! Утырып килдең, утырып китеп тә бардың. Бөтенесе дә канәгать, һәркемгә уңайлы булачак». Үгетлиләр, ышандыралар мине. Ләкин күңелдә нидер туктатты, кирәкми, ди. Һәм мин Бауманны үзгәртеп корырга карар кылдым. Тик проблема нидә иде соң? Кесәң тулы акча булса, теләсә нинди эшкә ябышырга була. Ә урамны казу-чоку эшенә керешкәч, шундый мәхшәр башланды! Һәркем, хәтта үз тарафдарларым да мине каргарга-сүгәргә тотынды. Без үзебезгә үзебез шаккаткыч күләмле эш ясадык. Йорт нигезләре, диварлар юешләнеп, җимерелеп килә икән. Без ул чакта алынмасак, тарихи һәйкәлләребез әллә кайчан ишелеп төшкән булыр иде. Чөнки 1957 елга кадәр Иделдә су биеклеге 17 метрга түбәнрәк иде. Куйбышев ГЭСын төзегәч, су күтәрелде. Дамба салдылар салуын, болай караганда, су агып килми дә кебек, ләкин җир астыннан ул бары үз юлын тапты: шәһәр үзәгендәге бөтен подвалларга, йортларга керде. Биналарны саклап калу безнең бурычыбыз иде, ә бу – бик зур эш. Борынгы заманда эшләнгән имән канализация коллекторларын таптык. Хәтерлим, бер урында кызыклы нәрсә казып чыгардык: җир астында бура тора, ә аның эчендә тагын бер бура. Бу үзенчәлекле суыткыч булып чыкты. Ике бура арасына боз тутырганнар, ә эчке бурада бозмыйча-нитмичә ит саклаганнар.

1. Әрчибез!

2. Юабыз!

3. Кискәлибез!

4. Ваклап турыйбыз!

5. Майлыйбыз!


6. Кыздырабыз!

7. Салабыз!

8. Болгатабыз!


9. Өлешләп бүләбез!


10. Теләкләр юллыйбыз!

PRESSA.RU

КАМИЛ ИСХАКОВТАН БЕР КИҢӘШ:

– Бәрәңге янына аз тозлы кыяр бик шәп бара. Хатыным аны артык җитлеккән зурайган кыяр согында тозлый. Бик тәмле килеп чыга!

Җыеп әйткәндә, без барлык фундаментларны ачтык, киптердек, эшкәрттек, гидроизоляция ясадык...

ХЫЯЛ ТОРМЫШКА АШСЫН ӨЧЕН, ЭШЛӘРГӘ КИРӘК

– Бер хыялыгыз пәйда була икән, аны һичшиксез тормышка ашырачаксыз икәнен беләбез. Казанның Меңьеллыгын да, «дөньяга аваз салуы» белән шул исәптән сезнең хыялларга да бурычлы метрополитенны да, «Рубин»ның җиңүләрен дә һәркем хәтерли... Әлегә чынга ашыра алмаган хыялыгыз бармы?

– Нәрсәне дә булса тормышка ашырыр өчен, эшләргә генә кирәк. Метро мәсьәләсендә шик-шөбһәле фикерләр бик күп булды. Бер генә мисал китерәм. 1996 ел. Минтимер Шәрипович Шәймиев белән бергә метро төзелешенә тантаналы рәвештә тәүге ташны салабыз. Шул ук көнне Уфада да нәкъ шундый таш салалар. Без салдык та метро төзелешендә эшне гөрләтеп тә җибәрдек. Моны ничек эшләгәнебезне үзем дә аңламыйм. Вакыйгаларны кирегә әйләндереп карасак – могҗиза булган ул! 2005 елда мэр вазыйфасыннан киткәндә, биш станция эшли, поездлар 10 километр юл үтә иде инде. Урамда 2017 ел, Уфада теге ташны ничек салган булсалар, ул шулай ята да. Хәтта селкенмәде дә. Без эшләдек, ә алар – юк. Нәтиҗәсе – күз алдында.

Бүгенге хыялыма килгәндә исә... Казанлыларны интеллектуаль яктан тагын да югарырак үсештә күрәсе килә. Без һаман куллану ягына таба чума барабыз, бернәрсә белән дә кызыксынмыйбыз.

Әйтик, самолет төзелешен алыйк. Моңа нәрсәләр кирә? Авиация һәм вертолет берләшмәләре, шулай ук алар өчен белгечләр әзерли торган авиация институты. Болар өчен эшче кадрлар әзерли торган авиация техникумы һәм һөнәр училищеларының тулы бер челтәре. Белем бирү схемасын мәктәпләр һәм балалар бакчалары төгәлли. Завод самолетлар һәм вертолетлар җыя, төрледән-төрле йөзгә якын предприятие аларны детальләр белән тәэмин итә. Һәм менә бөтен гыйлем, интеллект монда, Казанда туплана, ул безнең кешеләрдә яши. Чынлыкта, барысын да БЕЗ ҮЗЕБЕЗ эшләгән чакта җыела иде. Хәзер елына 30 вертолет җитештерәбез, дип мактанабыз. Ә элек 300 не чыгара идек бит! Самолетлар турында әйтеп тә торасы юк! Америкалылар әле һаман да кабатлый алмый торган шундый самолетлар чыгарабыз. Ту-160 очкычы турында әйтүем.

Әмма, кызганычка, Оборона министрлыгының заказлары тәмамлангач, интеллектка да көн бетте. Хәзер безнең акыл дәрәҗәсе «ал да сат» дәрәҗәсенә төшә. Исәпсез-хисапсыз кибетләр, төрле хезмәт күрсәтү урыннары... Һәм халык шунда хезмәт куя да, кая барсын ул тагын? Үз чиратында, монда туган, монда үскән интеллект та югала. Аңлыйсызмы? Хыялымны беләсегез килә иде – әнә шул акылны кире кайтарырга телим мин. Менә кытайлар бик шәп эшләде: дөньяның теләсә кайсы илендәге кибеттә теләсә кайсы товарда – «Кытайда эшләнгән» ярлыгы. Булдыралар!

– Ислам академиясе белән бәйле рәвештә Казанда шундый ук «интеллектуаль җәмгыять» булдырырга ниятләмисезме?

– Белгечләрне әзерләгәндә, шуны гамәлгә ашырырга телибез: алар берьюлы ике – безнең Болгар академиясе дипломы да, шул ук юнәлештәге чит ил югары уку йорты дипломы да алып чыксын. Моның өчен андый уку йортлары белән килешү төзеп, бердәм модуль нигезендә уку-укыту эшен алып бару таләп ителә. Без хәзер ирешергә теләгән магистр дәрәҗәсе, үзебездә булмаса да, чит илдә – буа буарлык. Бу безнең әзерлекнең билгеле бер югарылыгы. Без, әйтик, Мисырдагы әл-Әзһәр университеты белән килешү төзегәндә нәрсәгә игътибар итәбез? Әл-Әзһәрнең дәүләт эчендәге дәүләт кебек булуына. Аларның мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре дә, мәктәпләре дә бар. Шул рәвешле фән докторына дәрәҗәсенә кадәр ирешергә була. Алар белән килешү имзаларлык югарылыкка ирешү өчен, безгә дә әнә шундый эзлекле система кору зарур.

– Тормышыгыздагы иң авыр сынау кайсы иде? Андый нәрсә булдымы?

– Казанны ташлап китү бик авыр булды. Мин монда 57 ел яшәдем, монда тудым, эшләдем, бөтен хезмәт баскычларын үттем... Менә шушы тормыш юлын үткәч, ул йөрәккә нык кереп кала, читкә чыгып китүе дә бик читен. Өстәвенә, Ерак Көнчыгышка. Авыр хис-тойгылар белән юл тоттым мин анда. Ә инде бераз вакыт эшләп алгач, хатыныма шылтыратам:

– Матурым, монда шундый яхшы, Владимир Владимировичка бу якка җибәргән өчен шулкадәр рәхмәтлемен.

Анда чыннан да шәп. Табигать байлыклары, балык күп... Ни кызганыч, без, Россия халкы, бәяләр көйләнмәгәнгә, юл хакына субсидияләр бирелмәгәнгә күрә, моны күрмибез-тоймыйбыз. Ясалма сулыкларда үстерелгән Норвегия балыклары ашап яшибез. Тын океанда йөзеп йөргәне белән аны берничек тә чагыштырып булмый!

Мин тагын сезнең белән телемә салындым инде. Бәрәңге әнә ничек матур булып кызарды. Хәзер без аны тәлинкәләргә салып чыгарбыз да аз тозлы кыяр, маринадланган гөмбә белән... Безнең белән булганнарга, монда, Казанда булганнарга «Ашларыгыз тәмле булсын!» дип теләр чак. «Казанга киттем димиләр, Казанга кайтам диләр» – татарлар моны юкка гына әйтми ул.



«Татарстан» журналы редакциясе аш-су бүлмәсе өчен «Белая сова» кулинария студиясенә рәхмәт белдерә.


Чубар Абдул
Ирекле
Якты Күл
Кәкре Елга
Чатыртау
Азнакай
«Азнакай»
шифаханәсе
Актүбә
Таллы Бүләк
Бугульма

PRESSA.RU

PRESSA.RU

96+ ТАТАРСТАННЫҢ ОЗЫН ГОМЕРЛЕЛӘРЕ

96 яшьлек «Татарстан» журналы үзенең яшьтәшләрен һәм, гомумән, озын гомерлеләрне эзли. Шул ук вакытта, озак яшәүченең әһәмиятен һәм тарихи кыйммәтен киметмәгән хәлдә, яше бу санны узып киткән һәм узуын дәвам итә торганнарын да – әйтик, ул һәйкәл булса да яки, бүгенге кебек, Азнакай ягында теркәлгән чатыр рәвешле биек тау булса да. Татарстан кешеләре аны Чатыртау буларак белә. Һәм аның яше якынча... 200–250 млн ел тирәсе!

НӘНИ ГЕНӘ КИМЧЕЛЕК

50 миллион ел теге якка, 50 миллион ел бу якка – озын гомерле тау өчен бу нәни генә кимчелек. Чөнки, үзегез беләсез, ул ерак заманнарда «яңа туганнарга» берәү дә туу турында таныклык бирмәгән. Якынча туу көнен яки һич югы якынча туу гасырын чокчынып табу – археологлар һәм тарихчылар эше. Һәм менә төбенә төшкәннәр бит! Бер уңайдан, Чатыртауны Азнакай районының төп истәлекле тарихи-мәдәни урыны итккәннәр.

Тау түбәсенең биеклеге 334,5 метрга җитә – табличкада мәңгеләштерелгән бу сан анда менеп җиткән һәр кешене каршылап тора, ә сөзәк ягының озынлыгы – 7 километр!

...ҺӘМ КУЫКЛЫ АСТРАГАЛ

Истәлекле урыннарга хас булганча, тау тирәсендә серләр һәм риваятьләр күп йөри (алар турында «риваятьләр» рубрикасында аерым сөйләнә). Әле тагын Чатыртау VIII гасырның мәгълүм немец галиме хезмәтләренә дә кереп калган. Петр Симон Паллас үзенең «Россия дәүләтенең төрле провинцияләре буйлап сәяхәт»ендә (ә ул бу сәяхәтен 1771–1774 елларда кылган) болай яза: «... Бу илдә юлның сул ягында һәм искә алынган авылдан туп-туры көнчыгышта катламлы биек тау күренә, ул, күтәрелә барып, аеруча биек Шатиртауга күтәрелә һәм көньякка таба юнәлгән яланнар белән бүленә. Миңа әйтүләренә караганда, ул тауда бакыр руднигы бар, якынлашып килүче яшенле яңгырга карамыйча, шунда киттем. Бакыр руднигы юлдан ике чакрым читтәрәк, һәм ул сәүдәгәр Мясниковның Иштерәк бакыр заводына карый... Анда эш моннан 12 ел элек башланган. Анда сөзәк тау буйлап үткәрелгән һәм урыны-урыны белән тау эченә кереп киткән, һәм аннан күп руда чыгарылган ике иске штольня таптык. Әмма алар инде өлешчә ишелгән; өстәвенә, узган көздә элекке эш җиреннән төньякка таба яңа штольнялар эшкәртә башлаганнар. Хәзер әле көньяк юнәлештә төрле урыннарда тауның койрыгында казыйлар. Барысыннан да төньяктарак урнашкан яңа штольнядан моннан алдагы кышта 10000 пот руда алганнар, аның 100 потында 2 пот бакыр бар. Рудниктан 40 чакрымдагы заводка руданы илткән өчен потына 1 тиеннән иректе бәя алалар.

Рудниклар торган җылы үзәнлектә бик күп ногыт сабагы, кыргый бадәм чәчәк аткан, кайбер урыннарда чияләр, таллар һәм Astragalus physodes (куыклы астрагал) беренче чәчәкләрен ача иде».

БӘЙРӘМ КӘЕФЕ

Бу тау һәрвакыт үзенә бәйрәмнәрне җәлеп итә, дип сөйлиләр. Сәпәй авылының өлкән кешесе Мөхәммәтхан Сәүбәнов искә алуынча, шундый бәйрәмнәрнең берсе 1917 елгы революциягә кадәр зур һәм күңелле итеп үткәрелә торган «Чатыр атнасы» дип аталган бәйрәм булган. Май аеның һәр пәнҗешәмбесендә тирә-як авыл яшьләре Чатыртау итәгенә җыелганнар. Бәйрәмчә киенгән кызлар-егетләр, гармуннар тартып, атларга утырып килгәннәр. Бер-берсенә бүләкләр (чиккән кульяулыклар, күлмәкләр һ.б.) әзерләгәннәр: бер атнада алар егетләргә бирелсә, икенче атнада бүләкләрне кызлар алган – чәкчәк, перәннек, ак алъяпкычлар... Самавырлар да алып киленгән, суны изге саналган «Чатыр чишмәсе»ннән алганнар. Җырлаганнар, биегәннәр, уйнаганнар, күңел ачканнар... Сәпәй картлары «Чатыр бәйгеләре» турында да искә алып сөйли. Июнь уртасында тау итәгендә ат чабышлары оештырылган. Бөгелмә, Әлмәт, Бакалының иң яхшы җайдаклары кызыклы бүләкләр өчен көч сынашкан, ә бүләкләр – тарантастан башлап, ат дирбияләренә кадәр – бик күп төрле булган.

ҺӘМ 7000 БАЙБАК

Хәзер Чатыртау – тыюлык зонасы. Биредә терлек көтү, нинди дә булса эшләр алып бару тыела. Табигатьне саклау чаралары алып барылганга күрә, табигать беренчел халәтендә тоела: Чатыртау итәгендә үсемлекләрнең сирәк төрләре үсә. Тыюлыктагы 50 төрдәге дала үсемлеге ТР һәм РФнең Кызыл китапларына кертелгән. Әле тагын тауда Татарстанда бердәнбер байбаклар колониясе яшәп ята – сөйкемле йомшак җәнлекләрнең саны җиде меңгә якын дип исәпләнә.

Чатыртаудан күренеш.

Фото: Александр Ефремов

ҖИРДӘГЕ ИҢ ШӘП УРЫН!

АЗНАКАЙ:
ТАУ ИТӘГЕНДӘГЕ ШӘҺӘР

Һәр шәһәр урамнарыннан тау күренеп торганлыгы белән мактана алмый. Ә Азнакай исә шундый таулы кала! Атаклы Чатыртау Азнакайга гаҗәеп гүзәллек өсти. Хәер, шәһәр үзе дә соңгы елларда шактый киңәйде һәм үзгәрде.

Азнакай буйлап сәяхәт иткәндә һәм Татарстанның һәр торак пунктының йөзен үзгәрткән таныш объектларны – парклар, скверлар, яр буйларын карап йөргәндә, без азнакайлыларның президент программалары буенча төзелгән барлык бу объектларга шәхси якын килүләрен билгеләп үтмичә булдыра алмадык. Парк икән – Игелек паркы. Монда бигрәк тә мөмкинлекләре чикле шәһәрлеләр өчен уңайлы икән. Фонтан булса, һичшиксез, җырлый торган, аның репертуарында татар җырлары шактый. Әгәр инде балалар мәйданчыгы икән, ул урта гасырлар замогыннан һич кенә дә ким түгел. Өлкән тылсымчылар тарафыннан төзелгән мәйданчыкта бәләкәй азнакайлылар үзләрен әкияттәгедәй хис итәләр, дип уйлыйбыз.

PRESSA.RU



Фото: Александр Ефремов

АЗНАКАЙ:
КҮР ӘЛЕ, СИН ЯШӘГӘН ДӨНЬЯ НИНДИ МАТУР!

PRESSA.RU

– МОНДА ҮЗ ВАТАНЫНА ГАШЫЙК КЕШЕЛӘР ЯШИ

Азнакай – гүзәл табигате һәм нефть чыгару, җирнең уңдырышлылыгы һәм халыкның хезмәт сөючәнлеге, гореф-гадәтләрнең саклануы һәм йолаларның үзгәрмәве, үткәннәргә хөрмәт һәм якты киләчәккә өмет бербөтенгә кушылган үзенчәлекле төбәк ул. Биредә тылсымлы риваять-легендалар белән өретелгән данлыклы Чатыртау балкып утыра. Азнакайлыларның социаль-икътисадый үсеш казанышлары да данлыклы таудан калышмый – алар һәрвакыт югары. Моның сере нәрсәдә соң? Бу сорауга җавапны Азнакай муниципаль районы башлыгы Марсель Шәйдуллиннан да яхшырак белүче юктыр, мөгаен.

ШӘҺӘРНЕ НИЧЕК МАТУРАЙТЫРГА

– Марсель Зөфәрович, сез районның үсешен ничек бәялисез? Ирешелгән темпларны ничек саклыйсыз?

– Сезгә дә мәгълүмдер дип уйлыйм, Азнакай муниципаль районы иң зур нефть табу үзәкләренең берсе генә түгел, ә республиканың алдынгы авыл хуҗалыгы районнарының берсе дә ул. Әлеге казанышларга ирешү тиз арада гына булмаган, бүгенге уңышларның нигезендә күп буыннарның фидакарь хезмәте ята: безнең шәһәрнең тарихы бик ерак үткәннәргә барып тоташа, һәм без үз тамырларыбызга аеруча хөрмәт белән карыйбыз. Ромашкинода гаять зур кара алтын ятмалары ачылу районның илленче еллардагы үсешенә куәтле стимул була, аннары нефть чыгару нәтиҗәсендә Азнакай гөрләп үскән заманча шәһәргә әйләнә.

Безнең бүгенге бурычыбыз исә – элгәрләребез ирешкәннәрне тагын да үстерү. Нәтиҗәләрдән күренгәнчә, без әлеге бурычларны лаеклы хәл итәбез. Алгарыш барлык тармакларда да күзәтелә – авыл хуҗалыгында да, икътисадта, төзелештә, социаль инфраструктурада да. Узган ел әһәмиятле юбилейларга бай булды. Без республика Президенты Рөстәм Миңнеханов катнашында районның 85 еллыгын, «Азнакайнефть» НГТИ оешу һәм Актүбә бистәсенә нигез салынуның 60 еллыкларын зурлап билгеләп үттек. Быел исә тагын берничә мөһим датаны билгеләп үтәбез: 30 ел элек Азнакайга шәһәр статусы бирелүне, Технологик транспорт идарәсенең 60 еллыгын, Автомобиль юллары идарәсенең 50 еллыгын. Районда яңа йортлар, юллар, парклар, спорт мәйданчыклары, мәгариф һәм медицина учреждениеләре төзелде, күпфункцияле мәдәният үзәге, төбәкне өйрәнү музее, сәүдә-күңел ачу үзәкләре, җитештерү объектлары ачылды. Болар барысы да республика җитәкчелеге, безнең нефтьчеләребез ярдәмендә булдырыла.

Районда торак төзелеше актив бара, былтыр барлыгы 25,2 мең кв.

м торак салынды. Азнакайда социаль ипотека программасы буенча 96 фатирлы йорт, Актүбә бистәсендә гражданнарны тузган торак фондыннан күчерү программасы буенча 24 фатирлы йорт файдалануга тапшырылды, ике 18әр катлы йорт төзелде, 33 фатирлы торак йорт салына башлады. «Татнефть» ГАҖ һәм аның структур бүлекчәләре хезмәткәрләренә социаль ипотека программасы буенча Азнакайда 60 һәм 90 фатирлы ике йорт төзелә, аларның беренчесе быел файдалануга тапшырылачак.

Азнакайда Кара елга ярлары төзекләндерелде, Җиңү, Игелек, Гаилә парклары төзелде, «Юбилейный» стадионына, Ишкаев исемендәге балалар паркына реконструкция ясалды. Бирдә яңа аттракционнар, уен мәйданчыклары, кече архитектура формалары, фонтаннар куелды. Экология һәм җәмәгать урыннары елы кысаларында Нефтьчеләр һәм Хәсәншина урамнарын төзекләндерергә карар кылынды. Азнакай үзәгендәге әлеге ике урам шәһәр юл челтәренең төп артерияләре дә, дүрт парк территориясен тоташтырган яшел каркас та булып тора, ул югары социомәдәни һәм экологик потенциалга ия. Шәһәрдә шахмат клубы төзелә, ачык бассейнга реконструкция ясала.

Районда төбәк әһәмиятендәге юллар салу һәм ремонтлауга, торак пунктларның урам-юл челтәренә һәм квартал эчендәге юлларга, сулыклар, буаларны ремонтлау, тәртипкә китерүгә аеруча игътибар бирелә. Соңгы елларда гына да, республикада гамәлдә булган программалар кысаларында, 20 буа капиталь ремонтланды, 26 спорт мәйданчыгы төзелде.

Республика программасы буенча, бөтен мәктәпләр ремонтланды, быел дүрт балалар бакчасына ремонт ясалды. Су белән тәэмин итү челтәрләре актив реконструкцияләнә, иҗтимагый үзәкләр, мәдәният йортлары, спорт заллары ремонтлана, кече торак пунктларны газлаштыру буенча эш дәвам итә.

Мин, бөтен оешма, предприятиеләрнең, район халкының бергә, бердәм хезмәтен планнарны тормышка ашыруның төп шарты, дип саныйм.

НЕФТЬ НИЧЕК ХАЛЫККА ХЕЗМӘТ ИТӘ

– Татарстанда ярты елда нефть чыгару өч процентка диярлек арткан. Монда азнакайлыларның да өлеше бардыр.

– Һичшиксез, бүген нефть тармагы районыбыз икътисадының нигезен тәшкил итә. Безнең шәһәребез һәм районыбызның инфраструктурасы нәкъ менә нефть сәнәгате хисабына үсә, аңа бәйле куәтле икътисадыбыз яңа кызыклы проектларны планлаштыру һәм гамәлгә кертү, өстәмә инвестицияләр җәлеп итү мөмкинлеген бирә. Республика җитәкчелеге һәм «Татнефть» ГАҖнең зур ярдәме нәтиҗәсендә Азнакай районы нефть төбәгенең иң эре үзәкләреннән берсенә, республикабызның гөрләп үскән районына әйләнде. Без үзебезнең нефтьчеләребезнең уңышлары белән ихластан горурланабыз, алар нефть чыгару буенча «Татнефть»тә әйдәп бара. Нефтьчеләрнең уңышы – безнең район халкының уртак хезмәт җиңүе ул. Районыбыз халкының төп өлеше нефть сәнәгатендә, шул исәптән кече нефть һәм сервис компанияләрендә хезмәт куя.

Иң эре сәнәгать предприятиесе – «Азнакайнефть» НГТИ, биредә Марат Залятов җитәкчелегендә мең ярымнан артык кеше эшли. Ә район нефть сәнәгате үсешенең башында легендар кешеләр, сугыш һәм хезмәт ветераннары буыны торган. Бездә яшәүче барлык халык исеменнән мин ветераннарга, район хезмәтчәннәренә Азнакай районын үстерүгә керткән өлешләре өчен зур рәхмәтемне җиткерәм.

НИЧЕК БАЙ УҢЫШ ҖЫЯРГА

– Азнакай районы товар җитештерүчеләренең төп казанышлары нинди?

– Авыл хуҗалыгы мәйданнарының күләме буенча Азнакай районы Татарстанда беренче урыннарның берсен алып тора. Шунлыктан район үсеше стратегиясенең иң мөһим бүлекләреннән берсе – авыл хуҗалыгы, ул сөт-ит терлекчелегенә, сарык үрчетүгә, умартачылыкка юнәлтелгән. Бездә бодай, уҗым арышы, арпа, карабодай, борчак игелә.

Без аграр комплекс хезмәтчәннәренең казанышлары белән горурланабыз. Ашлыкның тулаем җыемы һәм бөртеклеләрнең уңыш күләме буенча азнакайлылар республикада әйдәп бара. Былтыр безнең игенчеләр 170 мең тонна бөртек җыеп алды.

> **Социаль-икътисадый үсешнең күп кенә күрсәткечләре буенча Азнакай районы республика муниципаль берәмлекләре арасында алдынгы урыннарны били.**

PRESSA.RU

Быел райондагы 100 мең гектардан артыграк мәйданга бөртеклеләр һәм башка культуралар чәчелде. Хәзер уңыш җыю актив темплар белән бара, уртача уңыш гектарыннан 40 центнер тәшкил итә, 180 мең тонна югары сыйфатлы бөртек җыеп алырга өметләнәбез.

Терлекчеләрнең дә уңышлары шатландыра. Мөгезле эре терлекнең баш саны арта. Бүген районда 35 мең баш мөгезле эре терлек исәпләнә, көн саен 140 тонна – бер савым сыерыннан 17шәр кг сөт җитештерелә. Актүбә мегафермасындагы шартлар чит илләрдәге заманча терлекчелек комплексларындагылардан калышмый. Мегаферманы киңәйтүне, симертү төркемен арттыруны, нәселле таналар сатып алуны планлаштырабыз. Хәзер «Азнакай» агрофирмасы базасында 2000 савым сыерына исәпләнгән шундый ук терлекчелек комплексын Сукаеш авылында төзү буенча эш алып барабыз.

Азнакай май ясау заводы кискен көндәшлек шартларында уңышлы эшли. Икмәк заводы күп ассортиментта продукция чыгара, предприятиедә җитештерү җиһазлары яңартыла. Азнакай тегү фабрикасы махсус кием-салым тегү буенча Татарстанның көньяк-көнчыгышында лидер санала.

Эшкуарлык үсеше нәтиҗәсендә шәһәрдә һәм авылда яңа предприятиеләр пәйда була, халыкка хезмәт күрсәтү сферасы киңәйтелә, даруханәләр, кафелар, тегү остаханәләре ачыла, теплица хуҗалыклары, мини-фермалар төзү буенча проектлар гамәлгә ашырыла, төзү материаллары, чүкеп ясалган эшләнмәләр һ.б. җитештерү көйләнә.

Өстәмә эш урыннары булдыру максатыннан районда өч сәнәгать мәйданчыгы оештырылды, анда резидентлар төзү материаллары җитештерү, металлдан бизәкле эшләнмәләр чүкеп ясау, ашамлык ярымфабрикатлары, бетон, җиргә түшәлә торган таш җитештерү предприятиеләрен урнаштырды. «Азнакай» мәйданчыгы аеруча актив үсә.

ЯШЬЛӘР БЕЛӘН НИЧЕК ЭШЛӘРГӘ

– Сезнең районда яшьләргә ярдәм итүнең нинди чаралары бар?

– Федераль, республика һәм муниципаль программалар ярдәмендә без яшьләрне эшкә урнаштыру өчен бөтен шартларны тудырабыз, торак сатып алуда ярдәм күрсәтәбез. Республика программалары буенча 20 гаиләгә торак сатып алу өчен 400-500әр мең сум акча бүленде. Лениногорск политехника көллияте филиалын үстерәбез – әлеге уку йортын тәмамлаучыларга һәрвакыт ихтыяҗ бар, аларны хезмәткә урнаштыру буенча авыл хуҗалыгы һәм сәнәгать предприятиеләре белән килешүләр төзелгән. Быел язгы чәчү вакытында гына да 150 укучы эшләде.

Бүген районда шулай ук табиб, педагог, төзүче, агросәнәгать комплексы белгечләренә ихтыяҗ зур. Ел саен безнең мәктәпләрне тәмамлаучыларга максатчан юнәлеш буенча уку мөмкинлеге бирелә. Инде күп еллардан бирле без, республикада бердәнбер шундый район буларак, «50/50» муниципаль программасы буенча үзебезнең студентларны югары уку йортларында укытабыз.

Без һәрвакыт үз белгечләребезне конкурсларда һәм грантларда катнашуга җәлеп итәргә омтылабыз. Грант ярдәмнәре хезмәт эшчәнлегендә зур стимул булып тора бит.

Моннан тыш, районның җәмәгать оешмалары гаилә кыйммәтләрен саклау буенча эш алып бара. Алар тәкъдиме белән без ЗАГС бүлегендә тантаналы теркәлүдән соң никахлашкан һәр илленче парны хөрмәтлибез. Яңа туган бәбиләрне теркәү, гаилә тормышы юбилярларын хөрмәтләү тантаналары, йөкле хатыннар белән очрашулар, ана капиталы сертификатларын тантаналы шартларда тапшырулар үткәрелә... ЗАГС бүлегенә аерылышу турында гариза бирүчеләрне үземә чакырып, әңгәмәләр дә үткәрәм – моның да нәтиҗәләре бар.

– Марсель Зөфәрович, без сезнең буш вакытыгызда спорт белән актив шөгыльләнүегезне беләбез. Азнакайлылар физкультура һәм спортка өстенлек бирәме?

– Болар бөтен районыбыз өчен өстенлекле. Халык аңлый: физик культура – сәламәтлекне саклау һәм ныгыту өчен мәҗбүри шарт. Бездә һәр өченче кеше физкультура яки спорт белән шөгыльләнә. Мин үзем дә райондагы Милли көрәш федерациясе рәисе булып торам. Соңгы елларда бездә спорт корылмалары челтәре сизелерлек үсте. Бүген районда спортның 25тән артык төре белән шөгыльләнәләр, заманча стадионнар һәм спорт комплекслары бар. Балалар да, өлкәннәр дә шөгыльләнә алсын өчен, спорт мәйданчыклары барлык йорт комплексларында салынды. «Татнефть» ярдәмендә бөтен уңайлыклары булган хоккей мәйданчыклары төзелде.

Безнең спортчыларыбыз шорт-трек, хоккей, гер күтәрү, җиңел атлетика, волейбол, өстәл теннисы, милли көрәш буенча ярышларда уңышлы чыгыш ясый, Россия һәм Татарстан чемпионнары һәм призерлары бар. Актүбәдәге «Буцефал» ат спорты мәктәбендә тәрбияләнүчеләр республика ярышларында гел призлы урыннар яулый. Безнең горурлыгыбыз – Казан Универсиадасының көмеш призеры, стендка ату буенча Россия җыелма командасы әгъзасы Светлана Крашенинникова. Аның җиңүләре белән илһамланып, 100 бала стендка ату белән шөгыльләнә.

Районда ел саен Кышкы авыл спартакиадасы уздырыла, анда 16 спорт төрендә 26 авыл җирлегеннән 500дән артыграк кеше ярыша. Әлеге ярышлар авылда физкультура һәм спортны үстерүгә этәргеч булды. Спартакиада нәтиҗәләре буенча авыл җирлекләренә спорт инвентаре һәм җиһазлары алу өчен акчалата премияләр бирелә.



НИЧЕК ТАРИХТА КАЛЫРГА

– Сезнең төрле, әмма Азнакайга гына хас темалар буенча китаплар бастыру эшчәнлеге зур кызыксыну уятты. Әлеге юнәлеш сезнең практикада ничек пәйда булды һәм тугрылыклы укучыларыгызны тагын нинди китаплар көтә?

– Китапка мәхәббәт миңа балачактан ук салынган. Китапта кешелек тарихы тупланган бит. Үткәннәрне белмичә, киләчәкне төзеп булмый. Нәшер иткән беренче китабым көчле профессионал һәм легендар шәхес – әтием Зөфәр Газиз улы Шәйдуллин турында булды.

Аннан соңгы китапларның темалары үзләреннән үзләре туа торды, алар барысы да Азнакай төбәге тарихы һәм аның кешеләре турында: «Азнакай», «Азнакай – язмышыбыз», «Ташландык авыллар җылысы». Соңгы китапның идеясе ташландык авыллар территориясендәге зиратларны торгызу һәм тәртипкә китерү эшләре барышында туды. Бу китапны тәкъдим итү май аенда үткән «Көнчыгыш Татарстанда кеше һәм табигать. Юкка чыккан тарихи авылларны өйрәнү, саклау һәм торгызу проблемалары» икенче халыкара фәнни-гамәли конференция кысаларында булды.

ЙОРТ БӘЙРӘМНӘРЕН НИЧЕК ОЕШТЫРЫРГА

– Милли мәдәниятне һәм телне саклау буенча районда нәрсәләр эшләнә? Нинди зур мәдәни проектлар тормышка ашырыла?

– Азнакай районында яшәүчеләрнең 85%ы – татарлар. Бу көннәрдә 90 еллыгын билгеләп үтәчәк чуваш авылы бар. Районыбыздагы барлык милләт халыклары дус яши, милли бәйрәмнәрен бергә үткәрә. Шәһәрнең яңа микрорайонында мәчет каршында чиркәү төзелә. Безнең районгдагы милләтара мөнәсәбәтләрнең үзенчәлеге шундый – руслар татарлар белән «Исәнмесез!» дип, татарлар руслар белән «Здравствуйте!» дип исәнләшә.

Традицион милли бәйрәмнәрдән тыш, районыбызда төрки халыкларның «Чатыртау җыены» Халыкара фольклор фестивале уздырыла. Анда Азнакайның туганлашкан шәһәрләре Тарсус (Төркия), Ивье (Беларусь) һәм Бакчасарай (Кырым) вәкилләре дә катнаша. Быел фестивальгә кунак булып Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин килгән иде.

Җәен бездә Йорт бәйрәмнәре үткәрелә, анда йортта яшәүчеләр, аңа капиталь ремонт ясаган подрядчы оешмалар, депутатлар катнаша. Бик матур оештырылган бәйрәм барышында капиталь ремонт ясалган торак йортлар һәм төзекләндерелгән территорияләр кабул ителә. Әлеге чараларда барлык кызыксынган якларның аралашу, формаль булмаган шартларда проблемаларны тикшерү мөмкинлеге бар. Халык өчен конкурслар, концертлар, спорт ярышлары оештырыла. Программаның иң мавыктыргыч өлеше – йортта яшәүчеләр һәм администрация командалары арасында футбол һәм волейбол матчлары.

ТУРИСТЛАРНЫ НИЧЕК ҖӘЛЕП ИТӘРГӘ

– Азнакай районы искиткеч гүзәл табигате белән данлыклы. Сез туристлык тармагын үстерүдә потенциал күрәсезме?

– Районыбызда туристлар өчен кызыклы урыннар бик күп. Азнакай районындагы саклана торган иң зур табигый территория – төбәк әһәмиятендәге «Чатыртау» Дәүләт комплекслы табигать тыюлыгы. Бу – республикабызның иң югары ноктасы, аның биеклеге диңгез өсте тигезлегеннән 321,7 метрга тәңгәл. Җирле халык, тауның могҗизалы көче бар, ә аңа менү уңыш китерә, дип ышана. «Җилкән» спорт-техника базасында актив ял итәргә яратучылар өчен бөтен шартлар да тудырылган: салда йөзү, пейнтбол, тауга менү, атта, квадроциклда йөрү һ.б. Районыбызның сихәтле чишмәләре, искиткеч матур буалары, гаҗәеп гүзәл Ык елгасы исә үзләре бер җыр кебек. Теләгән кеше «Азнакай» шифаханә-профилакториенда дәвалана һәм ял итә ала, ул үзенең дәвалау ысуллары белән данлыклы.

ЯКТАШЛАРНЫ НИЧЕК БЕРГӘ ҖЫЯРГА

– Сез үзегез күрше Әлмәт районыннан. Башта – Ютазы районы белән, хәзер Азнакай районы белән җитәкчелек итәсез. Билгеле инде, Татарстанның башка районнарында да булганыгыз бар. Районыгызга нинди бәя бирәсез? Ул башкалардан яхшыракмы, әллә начарракмы?

– Әлбәттә яхшырак! Биредә җиргә гашыйк кешеләр яши. Алар искиткеч хөрмәт уята. Биредә бик матур, тормыш җанлы, тулы. Мине азнакайлыларның көндәлек батырлыклары илһамландыра. 200 мең тонна бөртек суктыру булсынмы ул (без ашлык буенча һәрвакыт беренче урыннарда), тау битендә 5 мең кешелек «Чатыртау җыены» фольклор фестивален үткәрүме – барысын да булдыралар! Азнакайда нәрсәне генә алма, барысы да визит карточкасы, бренд. Нефтьме ул, тегү фабрикасымы, Актүбә уенчыгымы. Күрдегезме? Бөтен дөньяга мәгълүм ул.

Районда якташлык институты актив эшли. Казандагы якташлар очрашуына 800 кешене җыйганнар иде. Әлмәттә 2 мең кеше җыелды! Азнакайлылар – зур, тату бер гаилә ул, алар үз ватаннарын ярата белә. Азнакай районының казанышы исә – искиткеч, гаҗәеп тырыш, чыннан да талантлы кешеләр, үз ватаннарының чын патриотлары. Районда ватанпәрвәрлек тәрбияләүгә аерым игътибар бирелә бит. Нәкъ менә халкыбызның риясыз хезмәте, аның үз шәһәренә булган мәхәббәте һәм хөрмәте нәтиҗәсендә без Азнакайның чираттагы юбилей елын лаеклы каршылыйбыз.

«АЗНАКАЙНЕФТЬ»НЕҢ СОЦИАЛЬ ОРИЕНТИРЛАРЫ

Азнакай һәм азнакайлылар өчен «Азнакайнефть» НГТИ – нефть таба торган гади предприятие генә түгел. Ул шәһәр, районның икътисадый тотрыклылыгы һәм анда яшәүче халыкның муллыгы нигезе.

ИҢ КЫЙММӘТЛЕ КАПИТАЛ

Әле оешып кына килгән чорында, 1956 елда, «Азнакайнефть» 146 скважина һәм 765 хезмәткәрдән торган эксплуатация фонды гына иде. Предприятиенең яшь җитәкчесе Николай Мальцев коллективында, югары класслы белгечләрдән тыш, нефтьче һөнәрен үзләштерә генә башлаганнар шактый була. Ул чакта алга Ромашкино чыганагының Павловск һәм Зеленогорск мәйданнарын эшкәртү һәм тәҗрибә рәвешендә эксплуатацияләү, ә аннан соң Азнакай мәйданын сәнәгать эшкәртүенә тапшыру кебек стратегик мөһим бурычлар куела. Коллективның әлеге бурычларны ничек хәл итүе турында түбәндәге факт сөйли: 1977 елда Мальцев инде СССР Нефть сәнәгате министрлыгын җитәкли.

Үзенең 60 елдан артыгракка сузылган тарихы дәвамында «Азнакайнефть» НГТИ мәктәбен нефть тармагының шактый күп күренекле шәхесләре үтә. Идарә фидакарь хезмәтләре предприятиенең рекордлары нигезен тәшкил иткән геройлары һәм орденнарга лаеклы хезмәткәрләре белән хаклы рәвештә горурлана ала. Татарстан ятмаларын эшкәртә башлаганнан бирле табылган өч миллиард тонна нефтьтә Азнакай нефтьчеләренең өлеше 15,2%ны тәшкил итә.

Бүген Марат Залятов җитәкләгән «Азнакайнефть» НГТИ – «Татнефть» ГАҖнең иң эре бүлекчәләренең берсе. Идарә структурасында – нефть һәм газ табуның биш цехы, катламнарга басым ясауга ярдәм итү, скважиналарны җир астында ремонтлау, нефтьне комплекслы әзерләү һәм суырту цехлары, җитештерүгә хезмәт күрсәтү участогы, спорт-савыктыру цехы һәм идарә аппараты. «Азнакайнефть» балансында 6 385 скважина исәпләнә, шул исәптән 3 047 табу скважинасы һәм 1 150 кудыру скважинасы. Иң кыйммәтле капитал – ул, әлбәттә, меңъярым кешелек коллектив. Аларга тәҗрибәле промысел хезмәткәрләре, геологлар, ремонтчылар, икътисадчылар, технологлар – үз хезмәтләре белән

углеводород чималын табуны тәэмин итүчеләр кирә.

ЯҢА ТЕХНОЛОГИЯЛӘРНЕҢ НӘТИҖӘЛЕЛЕГЕ

Нефть табу – өзлексез процесс, шуңа күрә җитештерү чылбырының барлык буыннары эше дә шәп итеп җайланган, тәүлекнең теләсә кайсы сәгатендә тел тидермәслек булырга тиеш. Даими рәвештә технологик процессларны кырыс контрольдә тоту, нормадан аз гына тайпылыш күзәтелгән очракта да бик тиз төзәтү – «Азнакайнефть» идарәсендә сыйфатлы хезмәт күрсәтү буенча һичшиксез үтәлә торган мәҗбүри шартлар. Башкача мөмкин түгел: кешеләр сәламәтлегенә һәм табигатькә зыян китерү бәрабәренә нефть табуга беркайчан да юл куелмый.

Бүген нефтьчеләр эшли торган шартлар җиңел түгел. Катламнарда сулылыкның югары булуы, запасларның кимүе эшкәртмәләрнең нәтиҗәлелеген күтәрергә, бары тик традицион методлар хисабына гына эксплуатация чыгымнарын киметергә мөмкинлек бирми. Азнакайлыларга яңа технологияләр һәм эш принципларын эзләү һәм аларны актив гамәлгә кертү ярдәмгә килә. Аерым алганда, горизонталь скважиналарда катламнарны су белән аеру, шул исәптән күп зоналы су белән аеру кулланыла. Әлеге юнәлеш буенча алга таба да эшләрне алып бару өчен тәүлегенә суммар нәтиҗәлелеге 950 тонна булган 100дән артык скважина билгеләнгән.

Алга куелган максатларга ирешү өчен сакчыл җитештерү ысуллары кулланыла, җитештерүчәнлекне арттыра һәм ресурсларны экономияли торган проектлар эшләнә һәм иң яхшы тәҗрибәләр файдаланыла. Әйтик, нефть табу сферасында узган елда суммар нәтиҗәлелеге 148 млн сум булган проектлар тормышка ашырылды. Күләмле көч насосларын эшкә җигү һәм агрегатларның басым характеристикаларын оптимальләштерү катламнарга басымны яхшырту буенча күркәм нәтиҗәләргә китерде. Соңгы өч елда су тутыруга киткән электр энергиясе чыгымнары 6%ка кимеде. Электр җайланмаларын аларның факттагы торышларына карап ремонтлау системасына күчү моңа кадәр китә торган чыгымнарны 63 млн сумга азайтты. Скважиналарга капиталь ремонт ясауның вакытын һәм бәясен киметү, бригадаларның операцион җитештерүчәнлеген күтәрү, транспорт чыгымнарын киметү буенча проектларны гамәлгә кертү дәвам итә.

«Нефть табу операторлары эшенең нәтиҗәлелеген күтәрү» проекты исә операторларның эш процессын механикалаштыру турындагы күптәнге хыялын чынга ашырырга ярдәм итте. Хәзер көн саен барлык скважиналарны әйләнеп-карап кайту җәен – квадроциклларда, кышын снегоходларда башкарыла. Бүген оператор карап кайтучы гына түгел, ул шулай ук гидродинамик тикшеренүләр, һава электр линияләрен тышкы яктан карау һәм алардагы өзекләрне ачыклау эшләрен башкара, торбаүткәргечләрнең торышын тикшерә. Нәтиҗәсе – вакытны экономияләү, югарыда саналган эшләрне башкару өчен аерым-аерым чыгып йөрүләрдән котылу, һәм, димәк, транспорт һәм сервис компанияләре хезмәтләре өчен чыгымнарның кимүе.

Әлбәттә, яңа вазыйфалар операторларның күнекмәләрен, компетенцияләрен күтәрүне таләп итә. Әлеге бурычны хәл итүгә «Нефть һәм газ табу процессы фабрикасы» проекты булыша. Агымдагы елда «ЦПК-Татнефть»нең Азнакай филиалы базасында «Азнакайнефть» НГТИ башлыгы инициативасы белән булдырылган уникаль уку-өйрәнү полигоны эшләп китте. Аның

Реклама

PRESSA.RU



төп максаты – сакчыл җитештерүне кулланып, укытуның заманча методларын кертү һәм максималь рәвештә чынбарлыкка якынайтылган макетларда операторларның база һәм махсуслаштырылган күнекмәләрен ныгыту. Шунысы мөһим: укыту программаларын төзү һәм күнекмәләр реестрын формалаштыру фактта башкарылган эшләр статистикасына нигезләнә, бу исә персоналны укыту вакытын киметергә мөмкинлек бирә.

ШӘҺӘРЕБЕЗ – ТУГАН ЙОРТЫБЫЗ

Җаваплы социаль сәясәт – районның бюджет булдыручы предприятиесе эшенең өстенлекле юнәлеше. Беренче Физкультура йорты, балалар бакчалары, Мәдәният сарае, өсте ябулы йөзү бассейннары, санаторий-профилакторий, Боз сарае – болар «Азнакайнефть» тарафыннан төрле елларда корылган объектларның кайберләре генә әле. Хәер, Азнакай авылының гаять зур адымнар белән башта нефтьчеләр бистәсенә, соңрак заманча инфраструктурага ия матур һәм уңайлы шәһәргә әверелүе турыдан-туры предприятиенең оешуына, үсешенә бәйле. Һәм бүген дә «Азнакайнефть» эшчәнлеге шәһәрнең һәм районның алга таба үсешенә ярдәм итә.

Соңгы елларда «Татнефть» компаниясенең финанс ярдәме, «Азнакайнефть» НГТИ көче һәм район администрациясе булышлыгы белән Азнакайны төзекләндерү буенча киң колачлы эшләр башкарыла. «Чатыртау-Арена» спорт комплексы, яктылыклы-музыкаль фонтан, туган якны өйрәнү музееның яңа бинасы, ипотека программасы буенча күпфатирлы кирпеч йортлар салынды. НГТИнең 60 еллыгына (2016 ел) шәһәр территорияләре танып булмаслык үзгәрешләр кичерде. Ташландык бакчалар урынында парклар пәйда булды, елга ярлары төзекләндерелеп, шәһәрлеләрнең яраткан ял урынына әверелде. «Юбилейный» спорт комплексы ясалма өслекле, йөгерү сукмаклары һәм тамашачылар өчен уңайлы урыннары булган футбол кырына тиенде, ә реконструкцияләнгән балалар паркы җете төсләр балкышына күмелде. Быел да шәһәрне төзекләндерүнең колачлылыгы кимемәде.

Идарәнең горурлыгы – Актүбә бистәсендәге ат-спорт комплексы (сүз уңаеннан, нефтьчеләр төбәгендә – беренче). Ул атларга битараф булмаганнарның җыелу үзәгенә әйләнде. Уңышлы эшчәнлек елларында мәктәптә талантлы җайдакларның берничә буыны тәрбияләнде, җиңүче чабыш атларының көнләшерлек токымы үстерелде. «Татнефть» ГАҖнең Татарстанның көньяк-көнчыгышында ат спортын үстерүгә ярдәм программасы кысаларында нефтьчеләр шәһәрләрендә, шул исәптән Актүбә бистәсендә, даими рәвештә конкур һәм ат өстендә йөрү (спортның Олимпия төре) буенча ярышлар оештырыла. Ярышларда биредә үстерелгән чабышкылар яхшы нәтиҗәләр күрсәтә.

«Азнакайнефть» НГТИнең җитди социаль җаваплылык зоналарының тагын берсе – балаларны савыктыру лагерьлары. «Каенкай» һәм «Бөркет» лагерьларында күңелле ял итү өчен идеаль шартлар тудырылган. Алар бик матур табигать кочагында урнашкан. Биредә барлык уңайлылыклары булган номерлар, өсте ябулы йөзү бассейны, спорт залы эшли, биш тапкыр туклану, күңел ачу чаралары оештырыла, ә яңа сезоннан башлап, балаларны ясалма өслекле, йөгерү сукмаклары, ябулы трибунасы, ГТО нормаларын тапшыру мәйданы булган футбол кыры көтә. Бер сүз белән әйткәндә, малай һәм кызларның күптәнге хыялы.

Азнакайның 30 еллыгы – «Азнакайнефть» НГТИ коллективы өчен истәлекле вакыйга. Азнакай – идарәдә хезмәт итүче күпләрнең туган шәһәре. Кече Ватанны кайгырту, туган җирне бизәү, төзекләндерү, аның алга таба да чәчәк атуына һәм үсешенә үз өлешеңне кертү – нефть табу белән беррәттән, нефтьчеләр язмышына тигән төп хезмәт тә.

Реклама

«АРЫГАН» ЯТМАЛАРГА
ЯҢА ТЕХНОЛОГИЯЛӘР БУЛЫША

Бораулау технологиясен камилләштерү, җитештерү процессына яңа эшләнмәләр һәм техник яңалыклар кертү – «Татбурнефть» ИК» ҖЧҖнең Азнакай бораулау эшләре предприятиесе эшчәнлегендә төп бурычлар. Авыр чыгарыла торган нефть ятмаларын нәтиҗәле үзләштерүне менә шул рәвешле генә тәэмин итеп була.

Бораулау – нефть чыгару тармагының иң күп көч һәм чыгымнар сорый торган өлеше. Бораулаучы – үзенең зур, авыр җиһазлары белән бер урыннан икенчесенә күчеп йөргән, һәрвакыт хезмәттә булган тырыш зат ул. Бу хөрмәтле эш йомшаклыкны сөйми, югары профессионализм таләп итә. Шуңа күрә дә җир асларын иңләүче бу хезмәткәрләрне нефть чыгару эшендәге зур оркестрның беренче скрипкасы дип, тулы ышаныч белән атарга була.

66 еллык тарихы дәверендә Азнакай бораулау эшләре предприятиесе узган юлны авыр да, мактаулы да, дип әйтергә була. Әле узган гасырның 50нче еллар ахырында ук, нефть скважиналары кору һәм җир асты ятмаларына тиз юл салуда беренчелек яулап, Азнакай бораулаучылары Татарстанны бөтен илгә танытты. Аларның эш тәҗрибәсенә Көнбатыш Себердә дә, башка нефть төбәкләрендә дә ихтыяҗ зур иде. Ә абыйле-энеле Михаил һәм Матвей Гриньнарның, Мөгалим Гыймазов, Гәрәй Баһманов, Василий Шинкиннарның бөтен илгә яңгыраган исемнәре тиңдәшсез профессионализм гына түгел, ә үз эшеңә ихлас бирелгәнлек символына да әйләнде. 70нче еллар – новаторлык чоры булса, бораулап юл ачуларның зур үрләргә күтәрелгән дәвере – киеренке 80нче еллар. 90нчы елларда исә икътисадый кыенлыкларны җиңеп чыгу һәм, гомумән, исән калу өчен көрәш башлана инде… Ул чакларда җитештерү потенциалын, белгечләрне саклап калу өчен, бораулау идарәсенең җитәкчелеге вакытында үзгәрә белеп, килеп туган вазгыятьтән иң аз югалтулар белән чыга алды.

Азнакайның бораулау осталарына бәхет гел елмая: коллектив башында һәрчак бу эшне яхшы белгән булдыклылар, кыю фикерле, идеяләргә бай, техник һәм технологик проблемаларны иҗади күзлектән чишәргә сәләтле кешеләр генә торды.

Реклама

PRESSA.RU

БУ-2000-125 ЭП бораулау җайланмасы.

Хәзерге заманда һәр бораулау станциясе – тулы бер җитештерү-көнкүреш комплексы. Предприятие активында – иң заманча таләпләргә җавап бирә торган бораулау блоклары, яңа чистарту корылмалары, сыйдырышлыгы зур блоклар, сыеклык килү куәтен көйләү мөмкинлеге булган бораулау насослары, компрессор блоклары. Ашханә, ял итү өчен йорт-вагон, сауна, слесарь остаханәсе – эш шартлары шул кадәр уңайлы ки, үзләре элек эшләгән предприятиедә экскурсиядә йөргәндә, ветераннар гаҗәпкә кала: «Без «шәп-шәрә» бораулау станциясендә эшләдек. Бер почмакта ятим будка гына тырпаеп тора иде. Ә анда исә кул астында нәрсә бар – йә утын, йә солярка белән ягып җылытыла торган мич кенә».

«Татбурнефть» идарәче компаниясе, шул исәптән Азнакай бораулау эшләре предприятиесе алдында торган төп максатлар – скважиналар кору циклын мөмкин кадәр кыскарту (бу исә бораулау җиһазларының техник халәтенә һәм кулланылган технологияләргә бәйле), чыгымнарны киметү, катлаулы конструкцияле скважиналар

«Татбурнефть» ИК директоры Л.Нәҗипов айлык нәтиҗәләр буенча иң тиз бораулап юл казыган И.Сәлимшин бригадасын бүләкли.

«Нефтяник» Әлмәт хоккей клубы Ф.Ханов бригадасында экскурсиядә.

И.Сәлимшин бригадасы.

2017 елгы һөнәри осталык конкурсы призерлары.

Реклама

бораулау эшен үстерү, бораулауның коммерция тизлеген арттыру.

Җитештерү процессларын камилләштерү кысаларында компаниядә проект белән, процесс белән идарә итү кебек ысуллар актив кулланыла, хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү юнәлешендә эш алып барыла. Скважиналар коруны планлаштырганда, төзелеш программалары үтәлешен үзәкләштерелгән күзәтү ысулы һәр очракны аерым тикшереп эш йөртү дә бораулауда яхшы нәтиҗәләр бирә. Эш башлар алдыннан, бораулауның һәр этабына җентекле план төзелә, моның өчен исә скважина кору процессында катнаша торган тарафлар – заказчы һәм сервис оешмалары вәкилләре чакырыла.

Профессионализм, техник белем, үсешнең инновацион юлларына омтылу коллективка барлык ниятләгән планнарын уңышлы тормышка ашырырга ярдәм итә.

Азнакайлылар әйтүенчә, һәр максатны чынга ашырып була. Алар МБУ 3000/170 ИЭ җайланмаларында горизонталь бораулау ысулын кулланып, файдалы казылмалы катламга 80 градустан югары зенит почмакта керүгә беренчеләрдән булып иреште, бу исә азнакайлыларның максатчанлыгына бер дәлил.

Азнакай бораулау эшләре предприятиесе «Татбурнефть» идарәче компаниясе, «Татнефть» ГАҖ уздыра торган зур спорт чараларында актив катнаша. Аның хезмәткәрләре «Татнефть» ГАҖ бораулау вахталары арасындагы һөнәри осталык бәйгеләрендә ел саен призлы урыннар яулый.

Предприятиенең традицияләрен бораулаучыларның яңа буыны кабул итеп ала, үз һөнәрләренең чын остасына әверелгән алтын куллар бай тәҗрибәне яшь хезмәткәрләргә тапшыра. Предприятие коллективының 50%тан күбрәге – 33 яшькә кадәрге хезмәткәрләр, оешмадагыларның уртача яше исә – 38 тирәсендә. Коллективта ипотека программасы буенча төзелгән яңа фатирлар бирелә, ветераннарга ярдәм күрсәтелә, яшьләр белән дә актив эш алып барыла.

Азнакай бораулау эшләре предприятиесенең үткәнгә карап искә алырлык тарихы да, хәзер горурланып сөйләрлек эшләре дә бар. Һәм аны һичшиксез ышанычлы киләчәк көтә!


СБУ 3000-170 бораулау блогы.

КНБКны күтәрү процессы.

Муниципаль район башлыгы М.Шәйдуллин Азнакай бораулау эшләре предприятиесенең атказанган ветераннары белән МБУ-3000 бораулау җайланмасында.

Көндәлек эшләр.

Хатын-кызлар волейбол командасы.

Реклама

PRESSA.RU

ЯРТЫ МИЛЛИАРД ЧАКРЫМ – **ЭШНЕҢ БАШЫ ГЫНА ӘЛЕ**

Азнакай технологик транспорт идарәсе (ТТИ) – шәһәрнең иң өлкән предприятиеләреннән берсе һәм «Татспецтранспорт» Идарәче компаниясе» Җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең (ҖЧҖ) иң зур структур бүлекчәсе.

Радик Махиянов,
«Татспецтранспорт НК» ҖЧҖнең Азнакай ТТИ башлыгы

Майда Азнакай ТТИ үзенең 60 еллыгын билгеләп үтте. Алты дистә ел эчендә транспортчылар коллективы югары профессиональ, күп нәрсәгә көче җитәрлек нык командага әверелгән. Предприятиенең төп бурычы – нефтьчеләргә сыйфатлы хезмәт күрсәтү. Скважиналарның һәм нефть чыгара торган башка объектларның көйле эше шуңа бәйле.

Сүз уңаеннан, ерак 1957 елда нәкъ менә автотранспорт цехы «Азнакайнефть» нефть табу идарәсенең тәүге бүлекчәләреннән берсенә әйләнә. Ул чакта яңа структурага «Бөгелмәнефть» тресты АТКнән 52 данә транспорт һәм махсус техника тапшыралар. Җитештерү базасы салыр өчен 10 гектар җир бүлеп бирәләр, шунда ук төрле хезмәтләрне урнаштыру өчен өч вагон куялар.

Раил Нургалиев,
баш инженер.

Нәфис Арысланов,
баш механик.

Эксплуатация бүлеге.

Реклама

60 ел эчендә Азнакай ТТИ машина йөртүчеләре барлыгы 515 миллион 119 мең километр юл үткән. Бу Җир шарын 13 мең тапкыр әйләнеп чыгуга тәңгәл.

Шул елның ахырында исә цехта инде 175 берәмлек техника исәпләнә, ике автоколонна төзелә.

Тагын бер елдан соң бирледә автомобильләргә техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау өчен вакытлыча остаханәләр пәйда була. Ә 1961 елда автотранспорт колоннасы составына баштарак нефть промыселларында һәм скважиналарны капиталь ремонтлау цехында торган махсус техниканың бөтен төрләрен тапшыралар. Шул вакытта ук махсус техниканың өченче колоннасы да төзелә.

1970 елда автомобильләргә техник ярдәм күрсәтү һәм ремонтлау буенча профилакторий бинасы файдалануга тапшырыла. Бу базада «Татнефть» берләшмәнең барлык транспорт предприятиеләрендәге автомобиль һәм агрегатларны капиталь ремонтлау өчен авторемонт остаханәсе оештыра. Тагын бер шундый остаханә махсус агрегатлар бинасы базасында булдырыла.

Аннан соңгы елларда 50 махсус техника берәмлегенә исәпләнгән җылы стоянка, машиналарны юу өчен ябык урын (анда су чистартыла һәм кабат кулланыла), җиңел автомобильләр өчен гараж, тәгәрмәчле тракторлар өчен җылы стоянка төзелә, диагностика посты һәм автомобильләргә техник контроль линияләре җиһазландырыла. 1965 елда Азнакай идарәсе составыннан чыгарылган Актүбә технологик транспорт идарәсе дә параллель үсә. Ике ТТИ, транспорт идарәләрен нефть-газ табу идарәләре составыннан чыгаруга бәйле рәвештә, 2006 елда кабат кушыла. Шулай итеп «Татнефтьнең» аерым структур бүлекчәсе – Азнакай ТТИ пәйда була. Аннан соңгы үзгәртүләр нәтиҗәсендә исә Азнакай транспортчылары «Татспецтранспорт» Идарәче компаниясе» ҖЧҖ структурасындагы ун технологик транспорт идарәсенең берсенә әйләнә.

Нефть табуның катлаулы җитештерү чылбырында коллективның бурычы – махсус транспорт

Альбина Хәкимова, эшне һәм аңа түләүне оештыру хезмәте.

Нияз Сафиуллин, сәнәгать иминлеге бүлеге.

Җитештерү-техника бүлеге.

PRESSA.RU

белән өзлексез тәэмин итү. Куәтле һәм көндәшлеккә сәләтле, сыйфатлы һәм оператив эшли торган Азнакай идарәсе – «Татспецтранспорт» компаниясенең иң эре транспорт бүлекчәләреннән берсе. Бүген «Азнакайнефть» НГТИ күрсәтә торган транспорт хезмәтләренең күбрәк өлеше ТТИ коллективы көче белән башкарыла.

Нефть табучыларның хезмәтендә көн саен төрле техниканың 150ләп берәмлеге катнаша. Күп еллардан бирле Азнакай транспортчылары хезмәтләреннән Вышкалар монтажлау предприятиесе дә, «Электро-Энергосервис» ҖЧҖнең электр-энергетика цехы да файдалана. Партнерлары фикеренчә, Азнакай транспортчылары белән хезмәттәшлек итү файдалы – автопарк яхшы хәлдә, эш шәп көйләнгән, транспорт вакытында һәм кирәк булган очракта бик оператив бүленә, заказчының бөтен теләкләре тулысынча үтәлә. Җитештерүдә авария килеп чыккан очракларда исә Азнакай ТТИндә һәрвакыт өстәмә техника һәм махсус транспортның тулы комплектын табып бирү мөмкинлеге бар.

Транспортчылар теләсә нинди һава шартларында, тәүлекнең теләсә кайсы вакытында эшли. Үзләренең һәр иртәсен нефтьчеләр идарәнең автобус вахтасыннан башлый һәм шуның белән өйләренә кайтып төгәлли. Шунлыктан хаклы рәвештә әйтеп була: транспортчылар, промыселдагылар кебек үк, казылмалар чыккан урынны үзләштерүдә, катламнарның нефть бирүчәнлеген арттыруда, скважиналарга хезмәт күрсәтүдә һәм аларны ремонтлауда, шулай ук тормыш һәм җитештерүнең социаль аспектларында катнаша.

Азнакай технологик транспорт идарәсе хәзергедәй заманча һәм тотрыклы булсын өчен, күп нәрсә эшләнгән. Транспортчыларның берничә буыны моңа үз көчен керткән. Һәм бүген предприятие коллективы тулы канлы тормыш белән яши, анда җитештерүгә дә, җәмәгать эшләренә дә урын бар. Транспортчылар «Татнефть» ГАҖ, төбәк һәм республика дәрәҗәсендә үткән спорт һәм иҗади ярышларда әледән-әле җиңүләр яулый. Азнакай ТТИ коллективы – теләсә нинди катлаулылыктагы бурычларны сыйфатлы һәм үз вакытында үтәргә сәләтле бердәм команда ул.

60
ел
эчендә предприятиедә 200дән артык династия барлыкка килгән! Шулардан иң олысы – Әхмәтовлар династиясе, аларның гомуми хезмәт стажы 351 елны тәшкил итә.

Предприятиедә төрле елларда
127
Бөек Ватан сугышы ветераны хезмәт куйган.

Ягъфәр Гарипов, автомобильләрне ремонтлаучы слесарь.

Юлия Әхмәдиева, диспетчерлык хезмәте хезмәткәре.

Склад хезмәткәрләре.

Әнис Нигъмәтуллин, токарь.

Ягулык аппаратурасын ремонтлау участогы белгече.

Электр җиһазларын ремонтлау участогы.

Реклама

Эшләү дәверендә идарә 3500 километрдан артыграк юлны капиталь ремонтлаган. Барлыгы 5 миллион тоннага якын асфальт-бетон катнашмасы җитештерелгән.

Фото: bykovo.otg.su

ЯХШЫ ЮЛЛАР РЕЦЕПТЫ

Югары технологияләр заманында «Татнефтедор» ЖЧЖ структурасындагы иң зур филиал – Азнакай автомобиль юллары идарәсе хезмәткәрләре дә үз алларына яңа һәм актуаль бурычлар куя.

Равил Гинатуллин, «Татнефтедор» ЖЧЖ филиалы – Азнакай автомобиль юллары идарәсе җитәкчесе

1967 елда оештырылган идарә, ел саен эш географиясен киңәйтә барып, Азнакай, Әлмәт, Буа, Сарман районнарындагы 866 километрдан артык гомумкуллану автомобиль юлларын ел әйләнәсе карап тотуны тәэмин итә.

Һичшиксез, ярты гасыр теләсә кайсы предприятие өчен дә – шактый озак вакыт. Һәм бу дәвердә Азнакай юл төзүчеләре тарафыннан гаять зур эш эшләнгән. Автотрактор колоннасының ике машиналык бокслы бытовкасы, бердәнбер төзек машина һәм ялан кырдагы кишәрлек – моннан 50 ел элек предприятиенең эш башлау шартлары менә шулардан гыйбарәт булган. Бүген исә идарә – иң җитди юл проектын гамәлгә кертүдә катнаша торган куәтле структура.

Равил Гинатуллин, «Татнефтедор» ЖЧЖ филиалы – Азнакай автомобиль юллары идарәсе җитәкчесе:

– Техника паркында бөтен кирәкле нәрсәнең, үзебезнең асфальт заводының, квалификацияле персоналның булуы безгә юл эшләренең бөтен комплексын (әзерлек эшләреннән башлап тәртипкә кертүгә кадәр) сыйфатлы итеп һәм кыска вакыт эчендә башкару мөмкинлеген бирә. Ютазы, Сарман, Бөгелмә, Баулы, Кукмара, Нурлат, Әлмәт, Аксубай районнарындагы йөзләрчә километр трассага һәм меңләгән квадрат метрлы мәйданчыкка безнең көч белән хезмәт күрсәтелә.

Биредә шунысын да аңлау зарур: күн саен нефть чыгаручылар, бораулаучылар, сервис хезмәтләре һәм скважина ремонтлаучыларга хезмәт күрсәтә торган йөзләрчә берәмлек авыр махсус транспорт үткән юлларны карап тоту ул – үзенчәлекле эш. Юл салучылардан да икеләтә күбрәк җаваплылык таләп итә – кешеләрнең иминлеге өчен дә, кыйбатлы транспорт, күчерелә торган матди кыйммәтләр өчен дә.

Идарәдә әйләнә-тирәлек турында кайгыртмыйча икътисадый үсеш була алмавын яхшы беләләр. Нәкъ менә шуңа күрә Азнакай юл төзүчеләре заманча экологик технологияләрне үстерүгә өстенлек бирә. Асфальт-бетон заводы белән дә шулай булган. Куелган беренче туглагычларның конструкциясе баштарак төтен газларын тузаннан чистартуны тәэмин итә алмаган – һавага гаять күп тузан һәм зарарлы матдәләр чыгарылган, бу, әлбәттә инде, шәһәр халкында һәм контроль органнарында байтак ризасызлык тудырган. Шунлыктан Азнакай юл төзүчеләре, «ТатНИПИнефть» белән берлектә, өстәмә «юеш чистартулы» тузантоткарлагычы уйлап тапкан. Бүген тузан суыртуның нәтиҗәлелеге 98–99% тәшкил итә һәм әйләнә-тирәлекнең пычрануына бөтенләй юл куймый диярлек. Ярты гасыр эчендә асфальт-бетон заводы асфальт-бетон катнашмасы чыгара торган заманча җайланма белән җиһазландырылган эре структур бүлекчәгә генә түгел, бәлки төзү материаллары җитештерү буенча тулы кыйммәтле базага әйләнгән. Аның территориясендә тоз эремәләре әзерләү җайланмасы, бетонны миксерларга

Реклама

PRESSA.RU

төйи торган узел-дозатор, төрле фракциядәге вак таш әзерләү өчен ваклау-аеру җайланмасы куелган.

«Татнефтедор» ҖЧҖнең барлык бүлекчәләрен битум эмульсиясе белән тәэмин итү өчен, предприятиедә җитештерүчәнлеге сәгатенә 6 тонна булган MASSENZA* җайланмасы җитештерүгә кертелгән. Биредә җитештерелә торган эмульсия асфальт-бетон катламын җәяр һәм юлларны «салкын ресайклинг» ысулы белән ремонтлар алдыннан нигезне ныгыту (грунтовкалау) өчен кулланыла. Заманча җиһазландырылган үз лабораторияләре бөтен чыгарыла торган продукциянең норма һәм стандартларга тәңгәллеген тикшерү өчен кирәкле сынауларны үткәрү һәм эш сыйфатын контрольдә тоту мөмкинлеген бирә.

Идарәнең профессиональ коллективына күп кенә мөһим проектларны гамәлгә кертүне ышанып тапшыралар. Һәм азнакайлылар, үзләренә хас тәҗрибәлелек һәм югары һөнәрмәндлек белән, аларны вакытында һәм һәрвакыт югары сыйфатлы итеп башкара. Мәсәлән, идарә Түбән Кама нефть эшкәртү заводын төзү процессында территорияне вертикаль планлаштыруны башкарганда да, «Алабуга» махсус икътисадый зонасына килү юлларын төзегәндә дә шулай була.

Азнакай автомобиль юллары идарәсендә алдынгы техноло-

Реклама

* Массенза.

гияләрне һәм эш ысулларын предприятиенең ышанычлылыгын тәэмин итүче тыгыз чылбырдагы бер боҗра, дип саныйлар. Биредә кадрлар белән эшкә, социаль мәсьәләләргә зур игътибар бирәләр. Юл төзүчеләр өчен дүрт 24 фатирлы, бер 33 фатирлы һәм бер 36 фатирлы торак йорт, шулай ук «Бирючевка» ярдәмче хуҗалыгында бер фатирлы һәм ике фатирлы йортлар салынган. Юл салучыларның авыр хезмәтен җиңеләйтү, тормышларын яхшырту өчен идарәдә бик күп нәрсә эшләнә. Соңгы елларда Татарстанның тарихи урыннарына экскурсияләргә бару оештырыла, әлеге сәфәрләргә, предприятие эшчеләре белән бергә, ветераннар да бик теләп чыга, алар беркайчан да игътибардан читтә калмый.



Идарә хезмәткәрләренең сәламәтлеген ныгыту өчен, спорт залы төзелгән һәм заманча спорт җиһазлары сатып алынган.

Азнакай АЮИ хезмәткәрләре инде 20 ел буе «Татнефтедор» ҖЧҖ бүлекчәләре арасында үткәрелә торган Спартакиадада катнаша һәм ел саен призлы урыннар яулап ала.



PRESSA.RU

БЕРДӘМЛЕКТӘ – КӨЧ

Илгиз Мөслимов,
«Азнакай» агрофирмасы директоры

Иң яңа технологияләр, туган җиргә сакчыл мөнәсәбәт, хезмәт сөючәнлек һәм бай тәҗрибә – болар барысы да Азнакай районы авыл хезмәтчәннәре казанышлары нигезендә ята. Районның авыл хуҗалыгы тармагы, «Азнакай» агрофирмасы кебек әйдәп баручы предприятиеләргә таянып, ышанычлы адымнар белән алга атлый.

Ул 2000нче еллар башында торгынлык кичергән 14 хуҗалык базасында 2009 елда оеша һәм «Агросила» холдингы составына керә. Бүген «Азнакай» агрофирмасы эшчәнлеге ике дистә авыл һәм салага җәелдерелгән һәм 800гә якын кешене эшле итә, чәчү һәм урып-җыю чорында исә бу сан 1000гә кадәр җитә.

«Азнакай» агрофирмасы заманча авыл хуҗалыгы техникасының барлык төрләре белән яхшы тәэмин ителгән, бу үз чиратында эшнең нәтиҗәлелегендә һәм тотрыклылыгында чагылыш таба. Агрофирмага техник базасын камилләштерергә һәм яңартырга «Агросила» холдингы да булыша, аның техника паркының куәте 100 гектарга 180 ат көче туры килә, шул ук вакытта Татарстан буенча бу күрсәткеч – 154 ат көче. Яңа техника сатып алу өчен холдинг ел саен 1 миллиард сумга якын акча тота.

Бүген «Азнакай» агрофирмасы составында 11 ферма исәпләнә. Мөгезле эре терлекнең баш саны – 7,4 меңнән артык, шуларның 2,3 мең башы – савым сыеры. Бер сыердан уртача тәүлеклек савым 17,8 литрга җитә. «Азнакай» агрофирмасында терлек азыгы әзерләүгә аерым игътибар бирелә. Агрофирманың киләчәккә планнарында – 2 мең баш савым сыерына исәпләнгән терлекчелек комплексын аякка бастыру.

Моннан тыш, предприятие үсемлекчелек юнәлешен дә интенсив үстерә. «Азнакай» агрофирмасы уңыш күрсәткечләре буенча район күләмендә лидерлар рәтендә. Сөрүлек җирләренең гомуми мәйданы – 37,6 мең гектардан артык.

Соңгы ике ел эчендә «Азнакай» агрофирмасы белгечләре яңа культураларны үзләштерү юнәлешендә тырышып эшлиләр. Узган елда беренче тапкыр көнбагыш утырттылар, һәм ул яхшы уңыш бирде – гектарына 20 центнер. Быел көнбагыш мәйданнары 8,9 мең гектарны тәшкил итте, уңыш та югары булыр, дип көтелә.

Агрофирма кырларында башка төрдәге югары маржага ия культуралар үстерелә, әйтик, майлы ачы торма һәм рыжик. Шактый зур мәйданны – 3,3 мең гектарны (2,3 мең гектар – силоска, 1 мең гектар – бөртеккә) кукуруз алып тора. Бөртеккә игелгән кукуруз уңышы да югары булырга охшаган – гектарыннан 50–60 центнер көтелә.

«Азнакай» агрофирмасында уңышны сату белән проблемалар

Реклама

БЕЛЕШМӘ:

«Агросила» – Идел буе төбәгендә әйдәп баручы авыл хуҗалыгы предприятиеләренең берсе. Үзенә бөртекле культураларны үстерүче, кош ите, шикәр һәм сөт продуктлары җитештерүче предприятиеләрне вертикаль интеграцияләгән холдинг. «Агросила» холдингы составына керә торган предприятиеләр Татарстан АСК үсешенең мөһим элементлары булып торалар. «Чаллы-Бройлер» Татарстанда кош ите базарының – 65%н, «Зәй шикәре» исә шикәр базарының 51%н били. Орлык заводы республика агрофирмалары өчен орлык әзерли, комбиазык заводы ит һәм сөт производстволарын комбиазык белән тәэмин итә.

юк, чөнки сыйфат югары һәм холдингның сату системасы да җайга салынган.

«Азнакай» агрофирмасында җитештерүчәнлекнең югары дәрәҗәсенә квалификацияле һәм намуслы белгечләрнең тырышлыгы бәрабәренә ирешелә. Тырыш хезмәт өчен лаеклы һәм тотрыклы хезмәт хакы түләнә. Аның зурлыгы, иң беренче чиратта, башкарылган эшнең сыйфатына һәм күләменә бәйле. Кыр эшләренә җәлеп ителгәннәр – аена 100 мең сумга кадәр, сыер савучылар аена 32 мең сумга кадәр хезмәт хакы алалар.

«Азнакай» агрофирмасының холдинг составында булуының күп кенә өстенлекләре бар, бу – югары җитештерүчәнлеккә ия авыл хуҗалыгы техникасыннан файдалану мөмкинлегеннән алып, теге яисә бу юнәлешне үстерүнең бердәм эчке сәясәте, сату һәм тәэмин ителешнең җайга салынган чылбыры булуга кадәр. Болар барысы да, әлбәттә, үзенә яшьләрне җәлеп итә, алар өчен яхшы шартлар тудырыла, федераль программа буенча торак төзелешендә ярдәм күрсәтелә.

Бүген Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгының атказанган хезмәткәре Илгиз Мөслимов җитәкләгән «Азнакай» агрофирмасы, берүк вакытта тупланган тәҗрибәне дә, иң алдынгы авыл хуҗалыгы технологияләрен дә кулланып һәм елдан-ел Азнакай районының гына түгел, Татарстан Республикасының да иң яхшы авыл хуҗалыгы предприятиеләренең берсе дигән статусын раслый барып, киләчәккә ныклы ышаныч белән карый.

PRESSA.RU

КАЙТАСЫ КИЛӘ ТОРГАН АВЫЛ

Ат чабышы буенча спорт мәктәбе, фонтанлы чишмәсе, пөхтә-матур чәчәк түтәлләре һәм шау бакча эченә күмелеп утырган балкып торган йортлары белән дан тота ул... Мәскәү янындагы берәр затлы бистә турында сүз бара, дип уйлагансыздыр, шулаймы? Ялгышасыз! Сүз Азнакайдан 15 километр ераклыкта урнашкан гап-гади татар авылы – Кәкре Елга турында бара.

880 кешедән чак кына артык анда яшәүчеләрнең исәбе. Рублевканың яңа әвәләнгән байлары түгел, юк, ә чын мәгънәсендә эш сөючән халык яши бирәдә. Туып-үскән җирләрендә – «Марс» ҖЧҖндә хезмәт куялар алар. Горизонтка барып тоташучы иген кырлары һәм басулары – бу төбәкнең төп байлыгы. Алар җиде мең гектарны тәшкил итә, шуларның алты меңе – чәчүлек җирләре. Хуҗалыктагы уңышның муллыгы турында да телдән-телгә сөйләнә. Хәтта узган ике елда – корылык хөкем сөргәндә дә – гектарыннан 25–28 центнер җыеп алганнар. Саклап куйганның 80 процентын арыш культурасы тәшкил итә. Тагын бер табыш чыганагы – терлекчелек. 2500 башның 500е – савым терлеге. Сөт уңышы да мулдан бирәдә: «Марс»та елына бер сыердан уртача алты мең килограмм сөт савып алалар.

МОНДА ИРКЕН СУЛАП ЯШИЛӘР

Аңлашыла инде, җир эше белән терлек асрауны җиңел эшләр рәтенә кертеп булмый. Мондагы халык һәр сумны чын мәгънәсендә тир түгеп эшләп ала. Нинди зур хуҗалык югыйсә (зурлыгы буенча районда – икенче), ә аны алып бару нибары 150 кеше өстенә төшә. «Барысы да үзебезнекеләр – Кәкре Елганыкылар», – дип, сөенүен яшерми «Марс» ҖЧҖнең директоры Рамил Зарипов. Үзебезнекеләр сынатмый, дигән девиз яши бирәдә. Артык керемнәр юк хуҗалыкта, әмма уңайлы шартларда яшәүләренә һәм булган керемгә шөкер итә беләләр бирәдә. Сүз бит шәһәрдәгечә уңайлыклар турында бара.

– Эш хакын вакытында түлибез, салымнарны да, – дип сөйли Рамил Шамилович. – Ә яшәү шартлары шәһәрдәгедән бер дә ким түгел. Балалар бакчасы, мәктәп, кибетләр, мәдәният йорты, урамнарга асфальт җәелгән, һәрбер йортта – газ, яшә кинәнеп! Юлларда «бөкеләр» бимазаламый, шәһәр ыгы-зыгысы юк, аның каравы. Ә ничек иркен суларга була бездә, яле, сулап карагыз!

Зарипов туган төбәгенә гашыйк кеше, ләкин күкрәк тутырып иркен итеп сулап карыйбыз, аның сүзләрендә чынлап та һичбер арттыру юк. Кәкре Елгада 361 шәхси хуҗалык бар, берсе дә ташландык хәлдә түгел. Җимерек йорт, каралты-кура да күрмәссең бирәдә, бакчалар да гөрләп утыра. Әгәр кем дә кем хуҗалыгын сатуга куя икән (тормышта бит төрле хәлләр була), бәяләре дә ихтирам уятырлык. Сәбәпләре икәү: беренчедән, мондый мөмкинлекне кулдан ычкындырырга ярамый, икенчедән, һәрбер сатып алучы анык белә: менә дигән инфраструктурасы булган авылда, саф һавада яшәү өчен мондый гына бәяне җәлләмәскә дә мөмкин.

БЕР ЙОДРЫК ШИКЕЛЛЕ...

Кешеләрне туган җирләрен яратырга һәм монда калырга этәргән сәбәп уңайлы шартлар гына түгел, әлбәттә. Сезне, әйтик, шул ук Рублевкада, нинди генә затлылык уратып алмасын, кирәк вакытта ярдәмгә килергә дә, шатлыгыгызны уртаклашырга да ашкынып торган бу кадәр туган-тумача һәм таныш-белеш, дус-иш уратып ала алмаячак. Туган хуҗалыгында бу исә – табигый күренеш.

– Бездә песнионерларга хөрмәт зурдан, – ди Рамил Зарипов. – Алар бит – безнең ветераннар, барлык көчләрен шушы колхозга биргәннәр. Хәзер инде аларны кайгырту – безнең бурыч. Картлар көненә бүләк

Реклама

хәстәрләү – моны эшләми калганыбыз юк. Җиңү көне, Яңа ел – аларына да тырышабыз. Өлкән яшьтәгеләрне көн дә кайгыртып, хәлләрен белеп торабыз. Хуҗалыкта булышырга кирәкме, азык-төлек алып кайтып бирергәме... Моны туган-тумача да, күрше-күлән дә гадәти бер бурычы буларак кабул итә, бу хакта артык сүз куертып тору да кирәкми...

Төп бәйрәмнәрне, билгеле, бөтен авыл белән үткәрәбез. Сабан туе – бу инде изге нәрсә, Кәкре Елгага илнең бөтен почмакларыннан кайталар. Кайчандыр авылдан читкә чыгып киткәннәр дә, монда көн күрүчеләрнең балалары, туганнары да. Күрше авыллар килә агылып... Сабан туенда да өлкән яшьтәгеләрне, ветераннарны искә алмый калмыйбыз. Шулай ук «Марс» хуҗалыгының иң шәп хезмәткәрләрен билгеләп узу – матур бер йола. Уңыш җыеп алганнан соң, хезмәткәрләргә бүләкләр хәстәрлибез, бәйрәм оештырабыз.

Монда тагын бер матур йола бар: үзеңнең шәхси байлыгың – ул әле тынычланып, башкаларга күз ташламыйча яшәү дигән сүз түгел, ә аларга ярдәм кулы сузу да. Ярдәмчеллек бик киң таралган Кәкре Елга авылында. Җирле мәчетнең хәзрәте дә шуңа өндәп тора. Өлкәннәрне дә, бала-чаганы да ярдәмләшергә чакыра. Балалар мәчет каршындагы лагерьга йөри – ислам кануннарын өйрәнә, игелекнең нәрсә икәнен тоеп үсә. Сүз уңаеннан, быел уздырылган Корбан ашына 90 кеше җыелган.

БЕЗ БУЛМАСАК, КЕМ?!

Авыл җирендә яшәүче халыкның буш вакыты әллә ни күп булмый. Коллектив хуҗалыкта эшләп кайтуына, һәркемне үз хуҗалыгындагы эш көтеп тора – бакчасы, дисеңме, терлегеме. Мәшәкатьнең бетеп торганы юк диярлек. Икенче яктан караганда, шәхси хуҗалык гаилә бюджетын да калынайта, димәк, уңайлылыгы – бәхәссез. «Марс» ҖЧҖ авылның һәр кешесенә ярдәм итәргә әзер тора – бу да бик мөһим. Әгәр терлек асрыйсың икән – печән, фураж, кирәкле продукция белән тәэмин итәчәкләрен беләсең. Шулай ук таналар белән кышка калган башмаклар китергән «эш хакын» да исәптә тотарга кирәк. Шулай булгач, хуҗалыкларда терлек артканнан-арта. Узган елда гына да «Марс» үз эшчеләренә 120 баш терлек бүлеп биргән.

Шулай да, кеше эш белән генә яшәми. Авыл халкының тормышы кызыклырак булсын өчен дә көч куялар биредә. Ат чабышы буенча спорт мәктәбе, яшерен-батырын түгел, авылга иң кирәкле объектлардан исәпләнә алмый, әмма авылныкылар башкача уйлый. Һәм уйлары дөрес!

– Бу мәктәп – безнең горурлыгыбыз, – дип, хисләре белән уртаклаша Рамил Зарипов. – Безнең профиль – юртаклар. Дөрес, без атлар гына түгел, пони белән ишәкләр дә асрыйбыз. Ә алардан хуҗалыкка нинди файда, диярсез? Ләкин бит бөтен нәрсәне дә акча белән генә бәяләп булмый. Мәктәп – ул җан таләбе. Без бик күп бәйгеләрдә катнашабыз, балаларны чабышларга йөртәбез, белсеннәр үзләренекен, горурлансыннар! Ә үзләре ничек яратып чабышка әзерләнә...

Мин атларны бик яратам. Улларыма да бу ярату күчкән, күрәсең. Билгеле, ат чабышы спорты – кыйммәтле өлкә, безнең иганәчеләребез дә юк, барлык чыгымнарны хуҗалык үз өстенә ала һәм капларга тырыша. Ләкин моның белән без шөгыльләнмәсәк, кем шөгыльләнер?!

Тагын шунысын да искәртеп узыйк: биредә яшьләргә зур өмет баглыйлар. Аларны яхшы эш, эш хакы белән тәэмин итү, тормыш шартларына зур игътибар бирү, ялларын күңелле итү – менә шушылар кадрларны «Марс»та калырга әйди дә инде. Ат чабышы спорты мәктәбе дә үз ролен үти, билгеле.

Яшьләргә монда юллар ачык. Матди яктан гына кайгыртып калмыйча, аларны ничек ихтирам итүләрен дә ассызыклап торалар. Күптән түгел генә «Марс»ның яшь белгечләре белән телевидение өчен тапшырулар циклы эшләгәннәр. Эшләре дә күренә, үзләре дә, дигәндәй...

– Ел дәвамында хуҗалыкка бер генә яшь белгеч әйләнеп кайтса да – бу инде зур җиңү, – ди Рамил әфәнде. – Бездә мондый җиңүләр булгалап тора, шөкер.

Әйтүенчә, алар яшьләрдән менә дигән команда туплаганнар. 17 яшь белгечнең күбесенә әле 30 яшь тә юк икән. Җидесе – югары белемле белгеч. «Марс»ның җитәкчесе сүзләренә караганда, яшьләр белән эшләү – үзе бер рәхәтлек. Аның уллары да биредә эшли. Берсе – терлекче, икенчесе – механизатор.

Бу елда Кәкре Елгага ике яшь кадр кайткан – ветеринарлар. Икесе дә – кызыл дипломлы белгеч. Директорның аларга өметләре зурдан: «Менә гаилә корып җибәрерләр дә, калырлар әле үзебездә», – дип елмая. Чөнки биредә кешеләр дә матур, табигать тә. Бу сезгә Рублевка гына түгел...

PRESSA.RU

КЕЧЕ ХУҖАЛЫКНЫҢ ЗУР ЭШЛӘРЕ

«Баланлы Бүләк» авыл хуҗалыгы кооперативы 1990 елда мөстәкыйль хуҗалык булып яши башлый. Соңрак ул үз эшен «Габдрахманов» крестьян-фермер хуҗалыгы буларак дәвам итә. Баланлы Бүләк авылында хуҗалыкның беренче җитәкчесе, якты дөньядан вакытсыз киткән Габделхәй Габдрахмановны әле бүген дә хөрмәт белән искә алалар. Бәхеткә, өлкән Габдрахмановның эшен лаеклы дәвам итүче табылды – эстафетаны Ленар Габделхәй улы кабул итеп алды.

– Әтинең эшен дәвам итү, аның исеменә тап төшермәү – төп бурычым, – ди Ленар Габдрахманов. – Иң авыр вакытларда хуҗалыкны саклап калып булды. Авыл халкы шуның өчен рәхмәтле.

Бүген «Габдрахманов» КФХ аягында нык басып тора. Кече хуҗалыкның зур эшләре мактауга лаек. 1100 гектар чәчүлек җирләре бар, шуларның 500 гектарында – бөртекле, 600ендә азык культуралары чәчелгән. Бөтен чәчүлек орлык материалын үз көчләре белән хәзерләгәннәр. Механизаторлар Илгизәр Бәхтиев, Айрат Мөхәммәдиев, Сәгадәт Вәлиев, Илнар Ярмиев шушы авылда туып-үскән. Бәхетләрен дә туган якта тапканнар.

Габдрахмановлылар ел саен югары уңыш алуга ирешә. Былтыр уртача уңыш гектарыннан 28 центнерны тәшкил иткән. Быел исә, һава торышы бик якты йөз күрсәтмәсә дә, 25 центнер уңыш алалар. Һәр гектардан 30ар центнер арыш суктырып алуга ирешкәннәр. Барлыгы 10600 центнер бөртекле ашлык җыелган.

Хуҗалыкның бүгенге мәшәкатьләре, авылның хәзергесе һәм киләчәге, аның алдагы язмышы һәркемне борчый, Баланлы Бүләктә битараф җаннар юк. Моның ачык мисалы – урып-җыю чоры. Авыл халкы өчен әлеге иң җаваплы чорда уртак эшкә пенсионерлар, укучылар, медпункт, мәдәният йорты, кибет хезмәткәрләре – һәркем хәленнән килгәнчә үз өлешен кертә... Аеруча тырышлык куючылар арасында – склад мөдире Зөфәр Миңнеханов, машинист Марат Фазуллин, ашлык чистартуда эшләгән Миләүшә Вәлиева.

Реклама

Терлекчелектә дә эшләр уң бара, бу тармакта хуҗалык район җитәкчелегенең чын ярдәмен тоеп яши: 2013 елда фермага сөт үткәрү җайланмасын көйлиләр. Үз көчләре белән башкарылган эшләр дә аз түгел: технологияләрне камилләштерәләр, мал тораклларында шартларны яхшырталар. Хуҗалыкта 400 баш мөгезле эре терлек бар, шуларның 100 башы – савым сыерлары, 70е – бозаулар.

«Габдрахманов»лылар көн саен 1,5 тонна сөт тапшыра. Бер сыерга уртача 16,5 килограмм сөт туры килә. Бу – бик яхшы күрсәткеч. Бер шартлы мал башына 36,5 центнер хисабыннан сыйфатлы азык әзерләп куйганнар. Ферма мөдире Ясыйр Ярмиев, автомат сөт саву операторлары Роза Газетдинова, Айдар Миңнеханов, Сәрия Муллина, Илсөяр Шәйхуллова, Зөлфия Нуретдинова, бозау караучы Рифат Фазуллин, Әлфирә Вәлиева – үз эшләренең чын осталары. Менә инде берничә ел рәттән Айдар республикакүләм бәйгеләрдә призлы урыннар яулап килә.

Әлеге хуҗалык – авыл халкының ныклы таянычы һәм ярдәмчесе. Яшелчә бакчаларын монда бушлай сөреп бирәләр. Бу – күптәннән килгән гадәт. Пай җирләреннән файдаланган өчен печән һәм ашлык һәр хуҗалыкка китереп бирелә. Җитәкчелек авыл кешеләренә бар эштә дә булышлык күрсәтергә тырыша. 50 генә хуҗалыклы кечкенә Баланлы Бүләктә бердәм гаилә булып, дус-тату гомер кичерәләр.

«Л.Г. Габдрахманов» КФХ терлекчеләре планны һәрчак арттырып үти, югары сыйфатлы ит һәм сөт җитештерә. Бу эшкә ферма мөдире Ясыйр Ярмиев зур өлеш кертә. Ул авыл хуҗалыгына бөтен гомерен багышлаган. Монда төпләнеп, җәмәгате – сыер савучы Гөлсәрия белән ныклы гаилә кора, йорт җиткезә. Уллары Илнар да әти-әнисе юлыннан китә – хуҗалыкта тракторчы булып хезмәт куя.

PRESSA.RU

ФЕРМЕРЛАР БАРЫСЫН ДА БУЛДЫРА

«Бу фермада чиста башмакларда йөрергә була», – дип шаяртырга яраталар Азнакайның авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсендә. Сүз Илзирә Габидуллинаның крестьян-фермер хуҗалыгы турында бара. Ирекле авылында урнашкан бу хуҗалыкта булып кайтканнан соң, без бу сүзләрдә шаяртуга караганда, хаклыкның күбрәк булуына инандык.

Бүлмә идәненең яртысы яңа юнылган йомычкалар белән тулган. Фермага илтә торган үзәк юл шулкадәр чиста, әйтерсең, ферма кичә генә төзелгән. Әйтерсең, аны биш кеше өр-яңадан ремонтлап чыкмаган. Һавада сизелер-сизелмәс печән исе шәйләнә.

– Безнең сыер абзарында, ягъни капиталь ремонт ясалган колхоз бинасында хәзерге көндә 160 баш мөгезле эре терлек яши. Савым көтүе – 80 баш. Бозауларга урын җитми башлады да, менә, иркенәергә булдык. Тагын бер абзар төзеп чыгарга җыенабыз. Быел симертү өчен 1,5 миллион сумга грант оттык та ремонт эшләрен башлап җибәрдек, тиздән тәмамлыйбыз инде, – ди Илшат Габидуллин.

Фермерларның мал-туар өчен нинди шартлар тудыруын саннардан күреп була. Кышын бер сыерга уртача тәүлеклек савым 20–22 килограммны тәшкил итә. Район буенча бу – иң яхшы күрсәткеч.

– Фермерлык белән шөгыльләнер өчен азарт кирәк. Унике еллап элек безнең районда зур авыл хуҗалыгы семинары һәм бәйге узды, анда без Илзирә белән Россия һәм Татарстанның 102 хуҗалыгы арасында өченче урынны алдык. Ул чакта әле дуңгызлар асрыйбыз, тагын өч баш сыерыбыз бар иде. Мөгезле эре терлекнең санын арттырырга карар кылдык. Тагын 3 баш сыер алдык. Булдыра алуыбызга инандык. 2012 елда Россельхозбанк грантына беренче сыер абзарын ремонтлый башладык. 2,9 миллион сумлык кредит алдык, Балтач районыннан 48 баш нәселле сыер кайтарттык. Бу бик кыйммәткә төште, әмма чыгымнар үзләрен аклады. Орлыкландыру буенча инде берничә ел дәвамында Татарстанның «Элита» оешмасы белән хезмәттәшлек итәбез. Алар безгә Канада җитештерүчеләреннән материал кайтарта, бозаулары яхшы була, – ди Илшат Габидуллин.

Хуҗалыктагы эш бик күп вакытны ала. Ун елдан артык вакыт эчендә фермерлар бөтен кирәкле күнекмәләрне үзләштереп өлгергән инде. Илзирә хәзер савучы да, бозау караучы да, бухгалтер да.

Ул грантлар отар өчен кирәк булган кәгазьләрне дә, кредит документларын да үзе тутыра. Баштарак авыр булган, күз яшьләре белән елаган чаклар була иде, ди. Әмма Азнакай авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсендә һәм район администрациясендә ярдәм кулы сузганнар. Хәзер инде үзләре дә иярләшкән. Лизинг буенча 4,2 миллион сумга техника алганнар, өч миллионын Икътисад министрлыгы кире кайтарган. Узган елны биш миллион сумга комбайн сатып алганнар.

Бүген фермада өч ялланган кеше эшли. Әмма мондагы эш биш кешедән артыкка да җитәрлек. Яхшы кешеләрне табу да җиңел түгел.

– Безгә Чирмешән районыннан бер гаилә күченеп килде. Аларны аерым йортка урнаштырдык. Беренче эш хакын алганчы, барысы да яхшы иде. Шуннан эчә башламасыннармы. Кешеләр хезмәт биржасында торып, берни эшләмәскә, аз гына акчалар алырга иярләшәләр, күрәсең. Ә фермада эшләмичә булмый, җитмәсә, хезмәте дә җиңел түгел. Әмма ни кызганыч, эш хакы алар өчен стимул була алмый, – дип борчылуын белдерде Илшат Габидуллин.

Әйтергә кирәк, Габидуллиннарда эш хакы шактый саллы.

– Хәзер, менә, сенаж хәстәрләргә кирәк, килешү буенча сезонлы эшчеләрне ялладык. Араларында үзебезнең авыл кешеләре дә бар, Башкортостаннан килүчеләр дә. Кешегә акчаны яхшы түләргә тырышабыз, – дип сүзен дәвам итә Илшат Җәүдәтович. – Эшчеләрне көнгә ике тапкыр ашатабыз, ашау ресторандагы кебек. Илзирә беренче һөнәре буенча – икмәк пешерүче-кондитер бит...

Реклама

АВЫЛ **ТАЛИСМАНЫ**

Азнакай районының иң читендә бер авыл бар. Район үзәгеннән ерак урнашкан булса да һәм анда 190лап кына кеше яшәсә дә, Мәндәйдә чын мәгънәсендә тормыш кайный.

Биредә хәтта гадәттән тыш хәлләр дә булгалап куя. Бүгенгә кадәр авылда гаҗәеп риваять яши: моннан ярты гасырлап элек бер ишегалдында ак барс пәйда булган. Бу сирәк җанвар туып-үскән Азиясеннән монда чаклы ничек килеп җиткәндер, ә менә җирле халык авылдан биш чакрым ераклыктагы урманда барслар элек күпләп яшәгән булган, дип сөйли.

Кем белә, бу яклар өчен барс, бәлки, үзенчәлекле бер талисман кебектер. Биредә яшәүчеләр ялкаулык һәм күңел төшенкелегенең ни икәнен белми. Алар өчен бар нәрсә дә кызык, бар да яхшы, теләсә нинди мәсьәләне үзара киңәшеп хәл итәләр. Менә, мәсәлән, бервакыт Мәндәйгә корычагач яфраклы өрәңге «ябырыла». Ике ел эчендә бу бик тиз үрчүче агачлар урамнарны «камап ала», җир кишәрлекләренә үрмәли. Авылдашлар, берләшеп, «бәйләнчек» куакларны кисеп ташлый, ә ботакларыннан һәм кәүсәләреннән җирле истәлек – читән коралар.

Авылда нәрсәгә генә тотынсалар да, җиренә җиткереп башкаралар. Берничә ел эчендә республика программалары буенча биредә урамны яктырттылар, сафтан чыккан иске суүткәргеч торбаларны алыштырдылар. Кайсы ишегалдына керсәң дә – чисталык һәм тәртип. Кече архитектура формалары – ягъни кул астындагы материаллардан ясалган кош, җәнлек сыннары, чатырлар һәр йортта бар диярлек. Кышын, хәтта көчле бураннардан соң да, урамнар кардан чистартылган була. Андый чакта җирле авыл хуҗалыгы предприятиеләре шунда ук кирәкле техника белән тәэмин итә. Узган ел район хакимияте Мәндәйгә «Районның иң төзек торак пункты» исеме бирде, – ул моңа, дөрестән дә, бик лаек.

Бу сөенечле вакыйганы, башка бәйрәмнәр кебек үк, ике ел элек республика программасы буенча җирле төзүчеләр эшләгән яңа, матур авыл клубында тантаналы төстә билгеләп үттеләр. Мәндәйлеләрне белмәгән кеше: «Кечкенә генә авылга мондый байлык ник кирәк?» – дип уйларга мөмкин. Чынлыкта, концертлар, бию кичәләре, юмор тамашалары биредә бәйрәм итеп түгел, тормышның аерылгысыз өлеше итеп кабул ителә. Иске клубта ничек булган булса, яңасында да музыка тынып тормый – әле Сабантуйга әзерләнәләр, әле Яңа ел бәйрәменә, яисә Нәүрүз кичәсенә. Әле «Шаян-шоу»га концерт программасы хәзерлиләр. Атна саен була торган бию кичәләрен әйткән дә юк. Бәлки, шуңадыр, башка тирә-юньдәге авыллар белән чагыштырганда, Мәндәйдән читкә китүче яшьләр азрак.

Хәер, киткәне дә соңыннан кире кайта. Рафаэль Шәфигуллин белән дә шулай булган. Мәктәпне тәмамлагач, ул Казанның Авыл хуҗалыгы академиясенә укырга кергән, аны тәмамлагач, ярты ел шәһәрдә эшләгән. Аннары аны туган авылы үзенә дәшкән: хакимият башлыгы Рафаэльне Хәмит Мөстәкыймов (авыл язмышы турыдан-туры аның язмышы белән бәйле) исемендәге ҖЧҖне җитәкләргә чакыра.

Рафаэль алдында шактый катлаулы бурыч тора – хезмәткәрләрнең берничә буыны төзегән байлыкны саклап калу. 90 нчы еллар башында Хәмит Мөстәкыймовның үзен Азнакайда гына түгел, аннан читтә дә бер дигән җитәкче һәм үз һөнәренең остасы буларак яхшы беләләр; аның чакыруы буенча Мәндәйгә башка авыллардан һәм районнардан күп кенә яшь белгечләр күчеп килә. Озак еллар дәвамында аның җитәкчелеге астында кайчандыр гөрләп яшәгән, үзгәртеп кору елларында бөтенләй диярлек юкка чыккан хуҗалык кабат торгызыла. Соңыннан әлеге җаваплылыгы чикләнгән яңа җәмгыять үзенең беренче директоры исеме белән аталып йөртелә башлый.

Рафаэль Шәфигуллин легендар җитәкченең исемен аклый – бу Мәндәйдә ничек яшәүләреннән дә, ничек эшләүләреннән дә күренә. Яшь директор җитәкли торган предприятие, зур булмаса да, районның иң яхшы унлыгына керә. Ә бер гектардан уңыш җыеп алуда Россия күләмендәге уртача нәтиҗәләрдән дә югарырак тора ул.

Без аның белән кызу эш вакытында очраштык: үлән чабуның кызган чагы, иртәгә исә комбайннарны карарга кирәк...

– Кыенга туры киләдер сезгә?

– Мин биредә, шушы авылда, шушы кырларда туып-үстем. Аларның барысын да бик яхшы беләм. Шуңа күрә... кыен дип әйтеп буламы икән? – дип елмая Рафаэль. Тиз генә саубуллаша да кабат үз мәшәкатьләренә чума – Мәндәйдә тормыш тагын да яхшырак, матуррак булсын өчен эшен дәвам итәргә ашыга.

Реклама

PRESSA.RU

ҖЫРЫМ – ТУГАН ҖИРГӘ...

«Тукай» АХ ҖЧҖ директоры Габделәхәт Рәфиковның профессиональ язмышы – чын талант иясе һәркайда һәм һәрвакыт талантлы икәнен раслаучы факт ул. Әйе, әйе, педагогика өлкәсендәме, идарә итү эшендә яисә авыл хуҗалыгындамы – барысында да.

Чубар Абдулның үзәгендә урнашкан урам Совет урамы дип атала. Биредә авылның барлык төп объектлары – мәчет, Мәдәният йорты, мәктәп һәм, билгеле, авыл хуҗалыгының «Тукай» ҖЧҖ офисы урнашкан.

Без Габделәхәт Гатуф улының кабинетына күтәреләбез. Мондагы шартлар бик гади: язу өстәле һәм директор кәнәфие, тагын бер кечерәк өстәл, урындыклар, хуҗалыкның берничә мәйданчыгын күрсәтүче видеомонитор һәм грамоталар белән тулы стеллаж. Хуҗалыкка һәм аның җитәкчесенә бирелгән бүләкләр исемлеген узган ел Габделәхәт Рәфиков өчен иң әһәмиятлеләрдән булган тагын бер бүләк тулыландырган: Республика көне уңаеннан үткәрелгән тантанада Президент Рөстәм Миңнехановн аңа «Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгының атказанган хезмәткәре» билгесен тапшырган.

– Ә бит кайчан да булса хуҗалык белән идарә итәрмен дигән уйның башыма да килгәне булмады. Белемем буенча мин – педагог. 20 елдан артык мәктәптә эшләдем – Чубар Абдулда, Татар Шуганында, туган Буралымда. Башта биология һәм география укыттым, аннары директор булдым. Берара Чубар Абдулның авыл советы рәисе булып тордым. Аннары – кабат мәктәп директоры... Кыскача әйткәндә, тәҗрибәм зур һәм киңкырлы иде. Ә инде «Тукай»ны җитәкләргә тәкъдим ителгәч (бу – 2003 ел, хуҗалыкта хәлләр бик үк шәптән түгел иде), башта ни дип җавап бирергә дә белмәдем, – дип искә ала Габделәхәт Рәфиков.

Шулай да үзен сынап карарга кирәк дип, мәктәп директоры ул вакытка бурычлары йөз меңнәрчә сумга җиткән авыл хуҗалыгы предприятиесенең директоры булып куя.

– Җитәкче һәм оештыручы тәҗрибәсе һәм, ни гаҗәп тоелмасын, минем биология һәм география укыту буенча белемем ярдәм итте... Ничек тәртип урнаштырырга кирәклеген белә идем, хайваннар дөньясы һәм җир турында да мәгълүматларым күп булды, яхшы уңыш алу өчен җир турында ничек кайгыртырга кирәклеген дә белдем... Хуҗалык мөмкинчелеген исәпләдем дә, биредә бөтен нәрсәне дә җайга салырга була икәнен аңладым, – ди «Тукай» директоры.

Аның җитәкчелеге астында хуҗалык берничә ел эчендә алга таба сикереш ала. Бүген «Тукай» – Азнакай районы аграр комплексы вәкилләре арасында иң яхшылар исәбендә. Район Сабан туйларында ике тапкыр бирегә төп приз – автомобиль кайта. Хуҗалык кыр эшләрен беренчеләрдән булып башлый һәм тәмамлый, бөртекләләрнең күләме һәм терлек азыгы әзерләү буенча бик яхшы күрсәткечләргә ирешә. Авыл хуҗалыгы паркы системалы һәм нәтиҗәле рәвештә яңартылып тора.

– Соңгы биш ел дәвамында без бөртекләләрнең уңышын күтәрә алдык, аны гектардан 30–33 центнерга җиткердек. Монда берни дә сер юк: туфрак эшкәртүнең бөтен технологиясен дә төгәл үтибез, басуның барлык мәйданында тирәнгә сөрү үткәрәбез, – ди Габделәхәт Рәфиков. – Бездә 1200 баш мөгезле эре терлек бар, аларның 278е – савым сыер, шуңа күрә азык культурасына да күп чыгымнар билгелибез. Бер башка ел саен якынча 33 центнер азык бирәмлеге туры килә, бу – яхшы күләм. Районның ярдәме өчен рәхмәт – тотрыклылыкны саклауда һәм хуҗалыкның соңгы еллар эчендәге үсеш дәрәҗәсен төшермәүдә алар безгә зур таяныч. Торак төзелешенә процентсыз заемнар, мәсәлән, хуҗалык эшләренә яшь белгечләр тарту мөмкинчелеген тудыра. Авылда яңа тормыш кору, Чубар Абдул һәм күрше авылларның урамнарын төзекләндерү, җирле мәктәпкә ярдәм итү, яңа мәчет нигезенә беренче таш салуның кемгәдер кирәге булачагы эшкә дәртләндерә.

Габделәхәт Гатуфович белән офис ишеге төбендә саубуллашабыз. Табличкадагы «Тукай» сүзе кабат күзгә ташлана.

– Тукай белән сезнең хуҗалык арасында нинди уртаклык бар соң? – дип сорыйм.

– Исемне үзгәртә дә ала идем, шулай да тимәдем. Беренчедән, Тукай – мәдәният һәм мәгърифәтебезнең төп каһарманнарының берсе, бик көчле шәхес, – дип аңлата Габделәхәт Рәфиков. – Икенчедән, ул үз ягының чын патриоты булган. Биредә эшләүчеләрнең һәркайсы кебек. Безнең кебек үк, ул үзенең хезмәтләрендә туган җиренә дан җырлаган.

Реклама

ҖАВАПЛЫЛЫКНЫ – МИРАС ИТЕП

Авыл хуҗалыгы предприятиесе җитәкчесе булу – һәрвакыт көрәшкә әзер тору дигән сүз. Тәртип өчен, уңыш, ярдәмләшү, хуҗалыгыңның иминлеген саклау өчен… Кайвакыт җиңүгә ирешергә бөтенләй бүтән яссылыктагы көрәш тактикасын һәм стратегиясен белү ярдәм итә.

90нчы еллар уртасында Наил Мотыйгуллин авыл хуҗалыгындагы карьерасын әле башлап кына җибәрә. Әмма шул вакытта ук инде, армрестлинг буенча Россия чемпионы буларак, республикада билгеле кеше исәпләнә. Чыдамлылык, булдыклылык, җиңүгә ирешкәнче көрәшергә әзер булу – әнә шул сыйфатлар Наил Фоат улына спорттан тыш та кирәк булып чыга. Машина йөртүче вазифасыннан башлап, чирек гасыр эчендә ул озын һөнәри юл уза һәм Таллы Бүләк авылында авыл хуҗалыгы җитештерү кооперативы җитәкчесе булуга ирешә.

– Бабам бирегә ачлык чорында – узган гасырның 20нче елларында Әсәй авылыннан, үзенеке белән кала тагын алты гаиләне ияртеп, күченеп килгән. Килгәч, алар үз хуҗалыкларына нигез салганнар. Сугыш башланганда Таллы Бүләк тирә-юньдә иң яхшы авыл булып исәпләнгән. Казаннан концерт белән килгән артистлар бирегә туктала торган булган, чөнки монда гына әйбәт ашатканнар дип сөйли иде әнкәй безгә, – ди Наил Мотыйгуллин. – Сугыштан соң без Карамалы авылына кушылганбыз, ә 1991 елда тагын бүлендек. Шул чакта мин кабат оешкан «Ярыш» совхозында эшли башладым.

Ул елларда Таллы Бүләк халкына эшне өр-яңадан башларга туры килә. Ындыр табаклары һәм гараҗлар төзү, иске фермаларны торгызу… Колхозда сарык үрчетә башлыйлар, ярты мең баш мөгезле эре терлек асрыйлар. Бүген авыл хуҗалыгы җитештерү кооперативында аларның баш саны – 700, шуларның 200е – савым сыерлар. Уртача тәүлеклек савым 16,5 литрны тәшкил итә. Сөт Азнакай май заводына җибәрелә, анда тәмле, даны районга һәм республикага таралган сыйфатлы атланмай ясыйлар. Сөтнең сатып алу бәясе зур булмаса да (быелның июнь аенда литры 16,8 сум булган), хуҗалыкта аның сыйфатын сакларга тырышалар, ә сөт җыю сыер абзарында да, җәйге лагерьда да урнаштырылган автомат сөтүткәргечләр аша башкарыла.

60 хуҗалыклы авыл өчен бу кооператив, чынлыкта, бик зур предприятие санала. Җәен авылның чиреге – 45–50 кеше нәкъ менә шушы хуҗалыкта хезмәт куя. Эш күп – терлекчелектән тыш, бөртекле культуралар үстерү белән дә шөгыльләнәләр. Эшкәртелә торган җирнең мәйданы – 3,5 мең гектар. 800 гектар – уҗым чәчү, 1700 гектар язгы культуралар өчен файдаланыла.

– Узган елның 20 июлендә без бодай уру эшен башлаган идек инде, әмма быел, һава шартлары уңайсыз булу аркасында, бу эш бер айга чигерелә, шулай да урып-җыярга өлгерербез, дип уйлыйм, – ди Наил Фоатович. – Авыр булачак, шулай да ерып чыгарга тиешбез. Менә бүгенге көнгә безнең керем – 14 млн сум, ә узган ел 12 млн сум булды. Өстәвенә, былтыр 3 млн сум субсидия килгән иде, ә быел – 2 генә. Шулай да дәүләттән тотрыклы ярдәм аласы килә. Чөнки фермерның хезмәте һәрчак куркыныч астында. Быел менә кукуруз һәм карабодай утырттык. Федераль программа буенча безгә карабодай сатып алу өчен субсидия килергә тиеш, бу акчаны инде бик көтәбез. Сату эшендә дә ярдәм итәрләр, дип уйлыйм.

Хуҗалык барлык дәүләт программаларында да катнаша. Лизингка трактор биргәннәр, комбайннар һәм терлек азыгы хәзерләү техникасы сатып алынган. Республика программалары буенча узган ел – силос чокыры һәм ферма, быел тагын бер ферма һәм гараж төзегәннәр.

– Тырышабыз, хуҗалык аягында нык басып торсын өчен бөтенесен дә эшлибез. Әниемнең йортында «Биредә мактаулы колхозчы яшәде» дигән такта эленеп торды, – дип сөйли «Таллы Бүләк» җитәкчесе. – Ә мин гаиләдә чын җитәкче булган беренче кеше. Бу гаять зур җаваплылык. Бабам төзегәнне саклау – хәзер инде минем бурыч.

Реклама

PRESSA.RU

СӘЛАМӘТЛЕККӘ ФАЙДАЛЫ ЯЛ

Атаклы табигать һәйкәле Чатыртаудан ерак түгел генә урнашкан «Азнакай» санаторий-профилакторие инде ярты гасырдан артык Татарстанның иң популяр шифаханәләренең берсе булып тора. Чатыртау башында теләгән теләк һичшиксез чынга ашачак дигән легенда да яши.

Хәер, бирегә Чатыртауны гына түгел, «Азнакай» шифаханәсендә башкарыла торган күп кенә дәвалау ысулларының шифалы тәэсирен үзеңдә тоеп карау өчен дә килергә кирәктер. Савыктыру процедураларының югары дәрәҗәсе буенча санаторий-профилакторий Европа шифаханәләреннән һич кенә дә калышмый. Кунакларга диагностик тикшеренүләр, гидромассаж һәм дәвалау ванналары, ингаляторий, гирудотерапия, микротоклы электростимуляция, психоэмоциональ йогынты һәм стресслардан котылуның аппаратлы методикалары, кислород һәм озонлы терапия, массажның төрле төрләре, лазер һәм магнит терапиясе, криоген җайланма һәм башка бик күп савыктыру ысуллары тәкъдим ителә. Шифаханәдә теләсә нинди катлаулылыктагы бурычларны хәл итәргә мөмкинлек бирә торган актуаль медицина аппаратурасы урнаштырылган. ТРның атказанган табибы, санаторий-профилакторийның баш табибы Рөстәм Дәүләтшин җитәкчелегендә эшли торган белгечләрнең гаять зур тәҗрибәсе монда дәвалануны нәтиҗәле генә түгел, уңайлы һәм рәхәт итә. Ә уңай эмоцияләр, тәҗрибә раслаганча, үзләре үк шифа булып тора.

Дәвалау кабинетлары, торак бүлмәләр, ашханә урнашкан заманча уңайлылыклары булган өч катлы бина физик мөмкинлекләре төрле һәркем өчен каршылыкларсыз мохит белән бер комплекска берләштерегән. Бу ял итү һәм дәвалану өчен менә дигән урын. Шифаханә бер үк вакытта 180 кешене кабул итә ала.

Шифаханәдә олылар өчен – дүрт мәртәбә, балалар өчен алты мәртәбә ашау оештырылган. Табиб күрсәтмәсе буенча пациентлар махсус диетик туклану да алырга мөмкин. Меню төрлелеге һәм һәрвакыт яңа китерелгән җиләк-җимеш һәм яшелчәләрнең булуы белән аерылып тора.

Актив ял яратучылар, һичшиксез, шифаханәнең инфраструктурасыннан канәгать калачак: тренажер залы һәм бассейны булган яңа спорт комплексы, видеозал, кичке дискотекалар. Велосипедлар, квадроцикллар, электромобильләр, өсте ябулы батут та бар бирәдә. Ә актив ялдан соң сезгә өч сауна, хаммам, массаж, «Пирамида» психоэмоциональ бушану комплексы, тоз бүлмәсе, аромотерапия һәм берәр чынаяк үлән чәе хәл алырга булышыр. Ханымнар һәм туташлар югары квалификацияле косметологиягә дә әйбәт бәя бирерләр, өстәвенә, бу хезмәтләр янчыкның калынлыгына сукмый. Шифаханәдә шулай ук стоматология кабинеты эшли. Ә инде савыгу циклын хыяллар тавы – Чатыртауга экскурсия тәмамлый. Тау башыннан ачылган манзара сезне икенче тапкыр бирегә килгәнче җитәрлек тәэсирләр белән баетыр.

«Азнакай» санаторий-профилакторие – ел дәвамында ял итәрлек мөмкинлекләр тупламасы ул. Ел фасылына карамастан, шифаханә үзенең һәр кунагына сыйфатлы дәва һәм күңелле ял гарантияли.

ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ. НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТА

ТР Сәламәтлек саклау министрлыгы лицензиясе, № ЛО-16-01-003755, 2014 елның 22 октябре. Реклама

Реклама 16+

PRESSA.RU

Хобби кайчагында шундый җитди нәрсәгә әверелә, бу эш белән мавыгып киткән кешегә генә түгел, әйләнә-тирәдәгеләргә дә шатлык китерә башлый.

АНЫҢ ҖЫРЛАРЫ ХӘТТА ЯҢГЫРЛЫ ҖӘЙНЕ ДӘ КОЯШЛЫ ИТӘ АЛА

Җырларын туйларда, юбилейларда, сабантуйларда һәм концертларда ишетә башлаганчы, үзешчән композитор Ландыш Шәрәфиева иҗаты белән никадәр тирәнгә кереп китүен үзе дә аңлап җиткерми әле.

Ландыш Шәрәфиева 100дән артык җыр язган. Бүгенге көндә өченче альбомын әзерли.

Автор:
Алсу Троицкая

Илдус Мәрдәншин сүзләренә язган «Каеннардай якты булсын» – аның беренче җыры. Һәм җырга бәяне иң элек кызы бирә: «Әни, бик шәп бит бу!» Дебют җыры беренче альбомының исеме итеп куела. Аннары «Гомер җебе» дигән икенче альбом туа, ул якташ шагыйрьләре белән иҗади хезмәттәшлектә языла...

Хәзер Азнакайның музыка-бәйрәм ландшафтын аның Гөлгенә Кәримова сүзләренә иҗат иткән «Рәхмәт сиңа, табиб!» җырыннан башка күз алдына да китереп булмый. Шәһәрдә һәм районда ул медицина хезмәткәрләренең рәсми булмаган гимны статусын алган. Әйе, гимн, аны беләләр, җырлыйлар һәм яраталар. «Минем төп хезмәтем дә бар бит, югыйсә», – ди композитор үзе. Ландыш Гайсә кызы – район-шәһәр Мәдәният сарае директоры. Ә җырлар язу – «анысы күңел өчен». Ләкин кешеләр бергә җыелып, синең җырларыңны җырлый икән, бу талант түгелмени? Ландышның җырлары яңгырлы җәйне дә кояш нурларына күмә, дип мактыйлар үзен якташлары. Бәлки бу «нурлылык»ның сәбәпләре аның моңсу текстларны читләтеп узуыннан киләдер?

– Миңа күбесенчә якты хисләр ошый. Күңел тартмаган шигырьләрне алмаска тырышам. Безнең һәммәбез өчен дә мәхәббәт төрле яшьтә моңарчы күренмәгән төрле яклары белән ачыла – туган җиргә, әти-әнигә... Минем өчен кинәт каяндыр иңгән, ләкин анык музыкаль идея шул инде. Ә калганы техника эше – язу, җырлап карау, яздыру.

Бүген аның җырларын Гүзәл Уразова, Салават Миңнеханов, Фәридә – Алсу дуэты, Динә һәм Рафаэль Латыйповлар, Эльвира Хамматова, Равил Галиев җырлый. Ул үз иҗатын юмарт өләшә, бик матур тавышка ия буларак, үзе дә җырлый:

– Кайчакта ниндидер җырны җырлый башлыйсың, аны беренче ноталарыннан ук эләктереп алалар – иң ышанычлы штрих шул инде: димәк, килеп чыккан! Мин бит шоу өчен язмыйм, ә тамашачылар өчен. Мондый чакта мин бик бәхетле.

#ҺӘР КУРЧАКНЫҢ – ҮЗ ХОЛКЫ

Бүген бу курчакларны республика шәһәрләрендә һәм районнарында гына түгел, чит илләрдә дә күрергә була. Шәһәр кунаклары якыннарына бүләккә, бик шатланып, Азнакайдан зифа буйлы, матур милли күлмәкләр кигән курчакларны алып китә.

Халык һөнәрләре йорты дистәгә якын халыкны эшле иткән, алар арасында күбесе – мөмкинлекләре чикле кешеләр, инвалид балалары булган ата-аналар.

– Әйе, үз эшеңнең ерак илләргә бүләк булып китүе бик күңелле, әмма курчакларымның аерым характерга ия булуы минем өчен тагын да мөһимрәк. Чөнки аларның һәркайсына без җан өрергә тырышабыз, – ди Галина Герк, «Азнакай курчаклары» Халык һөнәрләре йорты җитәкчесе.

Галина Альвисовна «Халык сәнгати һөнәрләре остасы» исемен йөртә. Ләкин аның персонажларын бары тик халык иҗаты предметлары дип кенә атарга тел әйләнми. Аның курчаклары шулкадәр затлы һәм нәфис. Сүз уңаеннан, бу яклары белән алар үзләренең авторларына охшаган. Галина Альвисовна күп еллар буе Азнакай балалар сәнгать мәктәбендә рәсем сәнгате укытучысы һәм сәнгать бүлеге мөдире булып эшләгән. Бүген аның укучыларының күбесе иҗат белән шөгыльләнүләрен дәвам итә, инде үзләре укыта.

– Минем әтием немец, ә әнием Азнакай районының Иректе авылыннан. Мөгаен, әнием ягына тартканмындыр, мин татар бизәкләренә, чигүләренә, милли костюмнарына битараф түгел, – дип елмая Галина Альвисовна. – Халык һөнәрләре йортының нәкъ менә Азнакайда ачылуы бик сөенгерде. Кибетләрдә примитив кытай сувенирларын күреп җан әрни. Бер-берсеннән аерылып тормаган мондый уенчыклар урынына без үз осталарыбызның уникаль эшләрен тәкъдим итәбез. Без бу юнәлештә эшли белгән талантларны, төрле әйберләр ясау белән мавыгучы кешеләрне эзлибез, – кыскасы, эшчәнлегебез юнәлешен бик тырышып үстерәбез.

Чыннан да, күргәзмәгә куелган курчаклар һәм сувенирлар күңелләрне әсәрләндерә, аларда халыкның җаны яши кебек. Алар, рухи кыйммәтләрне һәм халык традицияләрен саклап, безне үткәннәргә кайтара, гүзәллек бүләк итә.

PRESSA.RU

Авылга исем биргән күл.

Якты Күл авылы чишмәгә якын урнашкан.

ЯКТЫ КҮЛ: ТУГАННАРДАН ДА ГАЗИЗ БЕРКЕМ ЮК

12 августта Якты Күл авылы үзенең 90 еллыгын билгеләп үтте. Бик җитди итеп. Урманда концерт мәйданчыгы, кунаклар, якташлар, табын тулы милли тәм-томнар, күңелле авазлар, чуваш дәүләт ансамбле башкаруында җыр-биюләр, «Якты Күлнең тарту көче» дип аталган китапны тәкъдир итү... Якты Күл – Азнакай районындагы бердәнбер чуваш авылы.

Автор:
Алсу Троицкая

Туксан яшьлек авылга килеп кергәч үк, Зиновий Степанов йортын табарга тырыштык – аның турында биредә легендалар йөри. Юлыбызда очраган кешеләр, авылның бердәнбер урамына күрсәтеп:

– Туп-туры барыгыз, иң зур йортны күрсәгез, шул була инде аның хуҗалыгы, – диделәр.

«Зур йорт» дигәнебез бик зур кечерәйтү булып чыкты. Чыннан да йорт бик ДӘ-Ә-ӘҮ икән! Каршыбызга чыккан хуҗа, күптәнге танышларын күргәндәй, безне өйгә чакырды. «Нигә кирәк моның кадәр зур йорт?» – дип аптыравыбызга елмая гына:

– Туганнар күп бит. Барысына да урын җитсен өчен.

«САНДУГАЧЛАР САЙРЫЙ... ӘНИ ДӘ – ЯНӘШӘДӘ...»

Озак еллар зур шәһәрләрдә яшәгән Зиновий Степанов көннәрдән бер көнне бабалары туфрагы – Якты Күлгә күченеп кайтып киткәч, күп кенә дуслары: «Сиңа нәрсәгә кирәк булды инде бу?» – дип аптырашканнар.

– Кайберәүләр турыдан-туры: «Башыңа суктымы әллә?», – дип тә әйткәләделәр. Инде аннан бирле 23 ел вакыт үтеп китте. Ләкин сезне, мөгаен, миңа боларның барысы да ни өчен кирәк булуы кызыксындырадыр, – дип көлде авыл кырыендагы әлеге зур коттеджның хуҗасы.

Ничек кенә кызыксындыра әле!

– Чын тормыш биредә. Сандугачлар сайрый. Әни дә янәшәдә генә.

ОЗЫН ГОМЕРЛЕ ӘБИДӘН – ЧӘЙ ҺӘМ СЫЙ

Үзенең хезмәтне шактый күргән кулларын күрешергә дип сузган әни кеше елмая:

– Чәчбикә Петровна Паймуллина. Әйдәгез, үзегезне чәй белән сыйлыйм әле. Алма вареньесы белән. Үзем кайнаттым.

Алма вареньесы янына чиянеке һәм карлыганныкы да куела, тәмле конфетлар һәм печеньелар пәйда була. Әбекәй: «Зиновий алып кайтты», – ди.

– Чәйне тәмләп эчәргә яратам. Баягынак бәрәңге өеп кердем, бакчада чүп утадым. Арып киттем, чәй эчеп җибәрүгә, хәл кереп китә. Ә инде себерке белән парланып, мунчадан чыкканнан соң да эчеп җибәрсәң! Ух... – ди әбиебез, безне шаккатырып.

– Әйе, Аллага шөкер, әни әле мунчада чабына да, бакчада эшләргә дә көч таба, үзенә инде 93 яшь булса да, – дип, хәйләкәр генә күзен кысып ала Зиновий Дәүләтбаевич. – Газета-журналлар да укый. Менә «Маяк» район газетасына яздырган идем, ә ул алардан төп бүләк – «Азнакай» шифаханәсенә юллама отып куйды.

БЕР УРАМЛЫ АВЫЛ

Якты Күл авылында нибары бер генә озын урам бар. Йортлары тип-тигез булып аның ян-ягы буйлап тезелешкән. Йортлар, каралты-куралар монда барысы да матур-пөхтә, хуҗаларның зәвыгы да, осталыгы һәм үзенчәлеге дә күренеп тора. Һәр хуҗалыктан торна муенлы кое башын сузган, җирне йомшак үлән каплаган, боларны күреп, аяк киемен салып ташлыйсы, ялантәпи атлыйсы килә. Авылның төньягы каен-имән урманына барып тоташа, көнбатышта ярларын зирек агачлары каплаган көмеш сулы елга ага, ул плотинага терәлә. Буада кыргый үрдәкләрне күрергә дә, кәрәкә балыклары тотарга да була, дип сөйләде безгә авыл кешеләре. Нинди гүзәллек!

Нәкъ менә әлеге табигый гүзәллек, гаҗәеп тынычлык Әлмәт районы Бусеряк (хәзерге – Яңа Суркино) авылында яшәгән чувашларны бирегә тартып китергәндер дә. Аларның чукынырга теләмәгән мәҗүси бабалары Әлмәт якларына XVI гасырда ук хәзерге Чувашия территориясеннән күченеп килгән булган.

КҮЧЕНЕП КИЛҮЧЕЛӘР

– Бусерякта кешеләрнең җирләре бик кечкенә булган, шуңа күрә гаиләне туйдыру кыенга туры килгән. Бабаларыбыз гомер буе уңдырышлы кырлар турында

Фотолар Зиновий Степановның шәхси архивыннан

Бөек Ватан сугышында һәлак булган авылдашлар хөрмәтенә куелган һәйкәл. 2017 ел.

Паймуллиннар утары.

хыялланган, бай җирләрдә яшәргә омтылган, – дип сөйләде безгә Зиновий Дәүләтбаевич. – Кученеп китү турында уй әнә шулай барлыкка килгән. Бусеряк халкы, киңәшләшеп, бирегә элеккеге алпавыт җирләренә күз салырга дип делегация җибәргән. Ирләр яңа җирләрне үзләштерергә дигән ныклы карар белән кайтканнар авылларына. Иң беренче булып бу төбәккә 1927 елның язында гаиләләре белән алты кеше күченеп килгән. Алар арасында минем бабамның әтисе Степан Паймуллин да булган. Безнең фамилия дә аның исеменнән киткән – Степанов. Картлар аны арбага салып алып килүләре турында сөйлиләр иде. Үз куллары белән ясалган табутта, чиста бәйрәм күлмәге кигән килеш...

Ул шул ук 1927 елда үлгән һәм Якты Күл зиратында күмелгән беренче кеше булган. «Теге дөньяда да сезне мин алга алып барачакмын!» – дигән ул үләр алдыннан.

ТАТАР-ЧУВАШ ДУСЛЫГЫ

Бабасының атасы турында сөйләгәннән соң, Зиновий Степанов туган авылы тарихына күчте:

– Ык елгасы яр буйларын карап чыкканнан соң, беренче күченүчеләр күлгә якын җирдә, хәзерге вакытта Якты Күл авылы урнашкан урында тукталганнар. Башлыклары: «Дусларым, туганнарым, без моңардан да матуррак җирне таба алмаячакбыз, әйдәгез шушында авылыбызга нигез салыйк», – дип мөрәҗәгать иткән. Соңрак килүчеләргә дә бу урыннар бик ошаган. Матур күлгә якын булгангадыр, авылга Якты Күл дип исем биргәннәр, дип уйлыйм. Халык нигәдер аны әле Байкал күле дип тә йөртә. Соңрак, ике ел дәвамында, бирегә тагын 24 гаилә күченгән. Күченеп килүчеләр үзләре белән арбаларына төяп кирәк-яракларын, эш коралларын алып килгәннәр, әлбәттә, арбага сыйган кадәрен. Кем ничек булдыра ала, шулай яшәп киткән. Таштан һәм кирпечләрдән мич чыгарганнар һәм чиратлап ипи пешергәннәр. Яңа җирләрнең калкурак урынында мунча ясаганнар: җирне казып, стеналарын таш белән әйләндереп алганнар, балчык белән сылаганнар.

Һәм чирәм җирләрне үзләштерә башлаганнар, бүлеп бирелгән җирләрне эшкәрткәннәр, ашлык чәчкәннәр, бәрәңге утыртканнар. Җир йортларда яшәгәннәр, салкыннар бәргәч, күп кеше авырый башлаган. Ярдәмгә Үчәлле авылы халкы килгән. Безнең күп кенә гаиләләр аларның йортларында кыш чыккан. 1928 елның җәендә барлык хуҗалыкларда да йортлар төзелеп беткән, һәм яңа җирдә яңа тормыш башланган. Шул заманнардан бирле Үчәлле һәм Якты Күл авылы халкы арасында аерым бер дуслык яши. Без бүген дә барлык бәйрәмнәрне бергә үткәрәбез, кайгы-шатлыкларны бергә уртаклашабыз. Менә шундый озын гомерле татар-чуваш дуслыгы яши бирдә.

БАРЫБЫЗ БЕРГӘ

– Без, авылдашлар да, бер-беребез белән бик матур итеп яшибез, – дип сүзне дәвам итте Чәчбикә Петровна. – Сугыш башланган көнне бик ачык хәтерлим – әлеге хәбәрне кырга Пуяндай Юлтимеров – уникe яшьләрдәге малай алып килде. Ул иярсез генә атка атланган да, күлмәген болгый-болгый, нидер кычкыра. Ниһаять, барысы да әлеге коточкыч хәбәрне ишетте, ир-атлар һәм яшь егетләр, эш коралларын ташладылар һәм, атка атланып, район хәрби комиссариатына киттеләр. Дошманны бик тиз, бер-ике атна эчендә җиңеп, яңадан өйгә кайтырбыз, дип уйладылар. Ә ул, күрәсез, күпмегә сузылды. Фронтка чакырылган Якты Күл ир-егетләре арасыннан 20 кеше кире әйләнеп кайтмады, кайсы һәлак булды, кайсы хәбәрсез югалды. Быел авылда һәлак булган авылдашлар истәлегенә һәйкәл ачылды. Яше-карты – барысы да катнашты: тирә-юньне чистарттык, чәчәкләр утырттык... Узган елны чишмәне тәртипкә китердек. Беркем читтә калмады, уртак эшләрдән беркем дә качып йөрми.

ИҢ МӨҺИМЕ – ГАИЛӘ

Чәчбикә Петровна бабаларының авылга нигез салуларын хәтерлисезме дигән сорауга, юк дип, баш чайкый:

– Каян хәтерлим? Мин бик бәләкәй булган бит. Соң авылның бөтен тарихын Зиновий казып чыгарды! Безнең нәселне сигезенче буынга кадәр өйрәнде, авылдашларның кайсысының – бишенче буынга кадәр, кайсысыныкын – алтынчы-җиденчегә кадәр тапты. Мин моңа бик куандым. Инде бабаларымның туган җирендә яшәргә күп тә калмагандыр, ләкин гаилә кыйммәтләре барыннан да мөһимрәк. Һәм аның тарихын белергә, нинди дә сәяси идеяләрне түгел, гаиләне сакларга-якларга кирәк. Без бит туганнар – аннан да газизрәк юк.

НИЧЕК БАРЫП ҖИТӘРГӘ:

Якты Күл авылы Азнакай районында урнашкан, Азнакай шәһәреннән төньяк-көнчыгышка таба – 23 км Үчәлле авылыннан Тымытыкка таба асфальт юлдан барырга уйласагыз, сезне гаҗәеп матур катнаш урман (күбрәк каен, имән һәм нарат үсә торган) каршы алыр. Урманны үтүгә, юл сезне көнчыгышкарак борып, туп-туры Якты Күл авылына китереп җиткерер.

НӘРСӘЛӘРНЕ КҮРЕП ГАҖӘПЛӘНЕРГӘ:

Авыл кешеләренең берсе сөйләвенчә, бервакыт кибетләренә аркасына зур биштәр аскан бер ир-ат килеп кергән, ди. Сатучы Чикеспи аны чәйгә чакырган, кунак өйгә кергән. Авылда ят кеше турындагы хәбәр бик тиз таралган. Һәм тиздән урядник килеп җиткән, чөнки Япониядән качып кайткан революционер булырга мөмкин, дигән шик туган. Ләкин кунакны күрә алмаганнар. Ул монда өч төн үткәргән, ди. 1906 елда авыл кешеләре Владимир Ильич Ульянов сурәтләнгән газетаны күргәннәр. Теге кунакка бер тамчы судай охшаган булган ул сурәт.

PRESSA.RU

facebook.com/protatarstan

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

twitter.com/protatarstan

instagram.com/protatarstan

Реклама 16+

БЕЗНЕҢ ТӨРКЕМНӘРГӘ РӘХИМ ИТЕГЕЗ!

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫНЫҢ ӘДӘБИ ПРЕМИЯСЕ

«Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы һәм «Татарстан» журналы әдәби премиягә бәйге игълан итә

«Татарстан» журналы әдәби премиясе Татарстан матур әдәбиятына сизелерлек өлеш керткән әдәби әсәрләр иҗат итүче авторларны барлау һәм иҗатларына игътибарны арттыру максатыннан игълан ителде.

Премиягә түбәндәге жанрларда иҗат ителгән кульъязмалар дәгъва итә ала: роман, повесть, хикәяләр циклы. **Әсәрләрнең Татарстан турында яки Татарстан авторы тарафыннан иҗат ителгән һәм моңарчы беркайда да басылмаган булуы – бәйгенең төп шарты!**

Кульъязмалар Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә – русча һәм татарча – кабул ителә.

2017 ел дәвамында «Татарстан» журналы Экспертлар советы тарафыннан сайлап алынган текстларны журнал битләрендә һәм журнал сайтында protatarstan.ru басылып барачак.

Гран-при – китабыгызның басылып чыгуы.

2017 елның декабрендә бәйгенең жюрие ике телдә иҗат ителгән әсәрләр арасыннан җиңүчеләрне сайлап алачак – татар телендә бер әсәр һәм рус телендә бер әсәр. Икесе дә китап булып басылып чыгачаклар.

Бәйгенең шартлары:

1. Кульъязманың электрон версиясе.
2. Номинант турында мәгълүмат – әсәр авторының фамилиясе, исеме, атасының исеме, контактлары – белешмә өчен телефоны, адресы).
3. Авторның кыскача иҗади биографиясе (әгәр әдәби әсәр берничә автор тарафыннан иҗат ителгән булса, һәрберсенеке).
4. Әсәрнең синопсисы.

Кульъязма таләп ителгән материалларның тулы пакеты белән килмәгән очракта, жюри рәисе әсәрне кабул итмәскә хокуклы.

Кульъязмалар tatarstan@tatmedia.com электрон тартмасына «КОНКУРСКА» тамгасы белән кабул ителә.

Конкурсны үткәрү вакыты 2017 елның 19 гыйнварыннан 2017 елның 15 декабренә кадәр.

Тулырак мәгълүмат protatarstan.ru сайтында.

Реклама 16+

Кәримова Ралия Гата кызы 1951 елның 12 мартында Башкортостан Республикасы Яңавыл районы Салих авылында туган. Урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, Башкорт дәүләт университетының татар филологиясе бүлегендә белем алган. 1973 елда гаиләсе белән Татарстанга, яңа төзелә торган яшь шәһәр – Түбән Камага күченеп килгән. Озак еллар мәгариф өлкәсендә эшләп, лаеклы ялга чыккан. «Мин табигать баласы», «Бәхет бүләк итеп», «Яшәү яме» исемле шигырь җыентыклары, «Ташлы туфрак» исемле проза әсәрләре тупланган китап авторы. Шигырьләре, язмалары Татарстан һәм Башкортостан газета-журналларында даими басылып тора.

Ралия Кәримова

ЯРАЛЫ ЖАН

Шушы авылның пешекчеләре бик остамы, икмәк пешерүнең ниндидер серен беләләрме, узганда мин анда туктылам, кабарып торган хуш исле икмәк алмый калмыйм. Чакрымнарга сузылган озын урамнан әкрен генә, икмәк пешерә торган кечкенә пекарняны узып китмәскә дип, карап барам. Йортлар биек, төзек, авылда яши беләләр хәзер! Арада кечкенә, иске өйләр дә күренә икән. Мин юл читенәрәк чыгып туктадым да машинамнан төштем.

Менә кечкенәрәк кенә иске бер йорт, аның урам якка караган тәрәзәләре кояшта балкып тора. Тәрәзәләрнең ниндидер хикмәте бар идеме, урамнан узган һәр кеше ирексездән шунда күз сала. Карамаслык та түгел икән шул: өч тәрәзәнең һәрберсендә күз явын алырлык матур гөлләр үсеп утыра! Чүлмәгеннән күтәрелгән зәңгәр кыңгырау гөле, өскә элеп куйган савыттан асылынып төшкән тамчы гөлгә үрелеп, серләшеп тора кебек. Тамчы гөл шау чәчәктә, шәмәхә, ал төсләргә күмелгән. Ә икенче тәрәзәне кызыл, алсу эре чәчәкле яраннар каплап алган. Алар да төсләргә бай, күзләрен ачып текәлгәндәй, нәфис таҗларын кояшка борганнар. Өченче тәрәзә төбендә, уттай янып торган йолдыз гөле янәшәсендә, аксыл-яшькелт төстәге балалар башлыгы сыман кабарып торган эре гортензия кукраеп утыра. Бу урамда үсәргә тиешле гөл монда ялгыш кына, адашып килеп кергән баһадир кебек күренә. Бакча якка караган тәрәзәләр дә буш түгел ахры, анда да яшеллек, чия җете төсләр күп кебек. Монда минем кебек чәчәкләр яраткан кешеләр яши, күрәсең.

Менә аякларым мине үзләреннән-үзләре шушы йортның капкасына таба китерде, ирексездән капка келәсенә үрелдем. Капка шалтырап ачылуга, өйдән өстенә чәчәкле күлмәк кигән, ак яулыклы җыйнак кына бер әби килеп чыкты. Ул ялтырап торган галошларын ак оекбашлы аягына эләктерде, аннары, таныырга теләгәндәй, миңа текәлде:

– Исәнмесез, әбекәй!

– Аллага шөкер әле... Кем дип әйтим, таныш та кебек, әйдә, уз!

Ул татар әбиләренә генә хас кунакчыллык белән эскәмиягә таба күрсәтте. Мин яшел чирәм каплаган ишек алдын күздән кичердем дә, йорт буена таба юнәлдем. Монда аулак, тыныч. Янәшәдә генә кура җиләге куаклары чәчәк ата.

– И, әбекәй, ачуланма инде, мин узып барышлый гына тукталдым, исемем – Сәрия, Казаннан күрше авылга кунакка кайткан идем. Сезнең тәрәзәдәге матур гөлләрне күреп, узып китә алмадым, – дидем мин.

Әби үзалдына гына кеткелдәп алды, аннары миңа карап канәгать елмайды:

– Үзем үстердем, кечкенәдән калган гадәт – гөлләр яратам!

– Мин дә гөлләр буенча белгеч, фитодизайнер. Үзем шигырьләр дә язгалыйм.

– Гөл яраткан, шигырь язган кеше начар күңелле яки усал булмас! Ашыкмасаң, утыр!

Әби белән шулай танышып киттек. Сиксән ике яшьлек Гөлсем әби кемнәргә кайтуымны белеште, сөйләшә торгач, ачылып китеп, мине чәй эчәргә өенә чакырды. Мин машинадан авыл күчтәнәчләрен – каймак, эремчек алып кергәндә, ул өстәл әзерли иде инде. Йорт эче җыйнак, түрдәге караватта кабартып өеп куелган мендәрләр, кырыйда – иске генә диван. Һәр тәрәзә чәчәккә күмелгән! Әби миңа өстәл янынннан урын күрсәтте, чәй ясады. Чәй эчкәндә ашыкмый гына үзе турында сөйләде.

* * *

– Минем бабам – кырым татары, бик булдыклы, эшчән, мөхтәрәм кеше иде, – дип, еракта башлады әби сүзен. – Хәтеремдә, җыйнак кына түгәрәк сакаллы, башында – түбәтәй, кулында һәрчак эш кораллары булыр, ә сөйләме бераз башкачарак иде аның. Дәү әнием кара күзле, кыйгач кашлы, чибәр иде, беләгендә берничә катлы көмеш беләзек, бармагында көмеш балдак, ак яулыгы астыннан толымнары күренеп тора. Үзе гел көләч йөзле. Бик матур, тату яшиләр иде алар. Диңгез буенда ак баганалы, яшел түбәле биек кенә йортлары, йорт янында зур җимеш бакчалары бар иде. Дәү әни үзе Казан кызы булган, укымышлы гаиләдән. Без Казанда яши идек. Мине, ун яшемдә авырып киткәч, Казаннан шунда – Кырымга, дәү әниләремә алып килделәр. Кырыгынчы елның апрель ахыры иде бу. Бүгенгедәй күз алдымда әле, искиткеч матур кич. Без,

ашап-эчкәч тә, бакчага чыктык. Кояш инде диңгез эченә керепме, җир читенә төшепме, яртылаш ышыкланган, ә икенче яртысы үз янында алланып торган йомшак болытлар күчен алтынсу төскә манган. Без яр буеннан зәңгәрсуланып торган диңгез өстендәге баржаларга, ерактагы ак пароходларга карап, сокланып озак тордык. Бакча тулып үскән төрле төстәге гөлләр хуш ис тарата. Дәү әнием зур горурлык белән әнигә гөлләрен күрсәтә. «Оныгым да гөлләр үстерер әле, исеме дә Гөлсем бит», – диде ул, елмаеп. Ә мин минут саен төсен үзгәртеп торган серле диңгездән күзләремне ала алмыйм, ул инде шәмәхә төскә кереп бара.

Әбекәй, күптәнге танышым төсле, әллә кайчангы вакыйгаларны исенә төшереп, шундый бирелеп сөйли. Аның ягымлы тавышында йомшак аһәңнәр ишетелә, күз төпләрендәге вак җыерчыклары язылып киткәндәй, үзе, ничектер, яшәреп киткәндәй булды. Сөйләме матур, тигез, теле бай аның. Нинди һөнәр кешесе булды икән бу әби яшь чагында?

– Иртән йокыдан торуга, мин тагын бакчага чыктым, – дип, хикәясен дәвам итте ул.-Анда инде иртә белән язгы кояш уйный. Каяндыр сирәк кенә юка ак кар катламыдай болыт кисәге йөзеп килә дә, шундук эреп юкка чыга. Һавада ниндидер тибрәлү, калтырау бар кебек. Җир күкрәге сулыш ала, үз җылысы белән, хуш исе белән мине дә урый, назлый сыман. Мин сукмак буйлап аскарак төштем. Бакчада тезелеп киткән алмагач, чия, груша агачлары шау чәчәккә күмелгән, алар арасыннан яфраклар яшеллеге күренми дә диярлек! Әйтерсең лә бөтен агачларны чәчәкле җәтмә белән каплап алганнар...

Минем дә күз алдымда алмагачлы бакча, шунда хуш исле алсу-аксыл чәчәкләр арасында йөрүче үсмер кызчык, Кырымның җылы сулы чиксез зәңгәр диңгезе – гүзәл манзара пәйда булды! Бу карт кына әбинең табигатьне оста рәссам кебек тасвирлавы күңелнең иң тирән почмакларына үтеп керә. Шагыйрь күңеле, әлбәттә, ишеткәннәрне йөрәк аша кичерә. Бу минутларда минем җаным киеренке кыллы арфаны хәтерләтә иде: тормыштагы вакыйгалар, матур күренешләр аның сизгер кылларына кагылуга, ул яңгырый башлый сыман.

– Гөлсем апа, ничек матур сөйлисез, кем булып эшләдегез соң сез?

– Һөнәрем буенча укытучы идем мин, – диде ул, минем бүлдерүемә кәефе киткәндәй, – яза да идем, тик язган әйберләремне китап итеп бастыра гына алмадым.

Бераз туктап торгач, ул хикәясен дәвам итте:

– Озак кына яшәдем мин анда, дүрт ай тордым. Диңгез һавасы шифалы икән, терелдем. Дәү әнием гөлләрне карау, күчереп утырту серләрен өйрәтте. Ә бабай диңгездә йөздерде, төрле җимешләр белән сыйлады. Нәселебезнең затлылыгы турында сөйләде.

Икенче елны, июнь урталары узуга, шатлык-куанычлар белән кабат Кырымга барырга дип юлга чыктык, тик илдә кинәт кенә башланган сугыш аркасында, Казанга кире кайтуыбызны, сугыш вакытында кичергән авырлыкларны, әтиемнең сугышка китеп һәлак булуын сөйләп тормыйм.

Әбинең тавышында әрнү, югалту, чарасызлык сизелде.

– 1944 елның унсигезенче маенданиләр булганын сөйлисем килә сиңа, – дип дәвам итте ул сүзен. – Үзең дә укып беләсеңдер инде... Кырым татарларының фаҗигале язмышы – «сатлыкҗаннар» дигән гаеп белән туып-үскән җирләреннән сөрелү булган вакыт... Кырым тарихи яктан Төркия белән бәйле булган бит, әллә шуңа ышаныч булмаган, нимес ягына чыгучылары да булган, диләр. Болай була бу хәл: Кырымга язын бик күп милиция килеп тула. Сталин фәрманы белән, Берия кушуы буенча, һич уйламаганда, бөтен кешене яшәгән йортларыннан куып чыгаралар. Кием-салым, ризык алырга рөхсәт итәләр итүен, тик әйбер салырга урын гына булмый. НКВД солдатлары этләр белән ике көн эчендә барлык кырым-татар халкын мәҗбүри рәвештә куып, җитмешләп эшелонга, мал вагоннарына шыплап төйиләр дә аларны еракка – Казахстан далаларына, Үзбәкстан чүлләренә озаталар. Ни кичергәннәренен үзләре генә белгәндер, мескеннәр. Калырга, качарга уйласаң – 20 ел каторга! Сугыш вакыты бит. Юлда су, азык җитмәүдән бик күпләр – балалар, олылар чирли, күбесе үлә... Станцияләрдә мәетләрне вагоннардан чыгарып кына аталар. Алар кемнәрнеңдер кадерле кешеләре булган бит инде. Көч-хәл белән, мең бәлаләр аша үтеп, ачык далага барып егылалар бабайлар. Күршеләре белән бергә бераз салам юнәтеп, балчык изеп, кышка кадәр сәмәннән куыш ясыйлар. Чарасызлык чигендә була алар. Нинди дөньялары торып калган бит... Атна саен барып, милициядә билгеләнеп торырга да кирәк. Минем дәү әни белән бабай биш ел җәфа чигә шунда. Бабайның туганнары, энеләре дә бик интегеп яшиләр, коточкыч була тормышлары. Һай, сөйләргә дә авыр... Мин дә шунда булырга мөмкин идем бит, Алла саклагандыр... Башка күрүләр насыйп булмады аларны... Икесе дә бер-бер артлы китеп барган, мәрхүмкәйләрем. Искә алуым дога булып рухларына ирешсен... Бу вакыйгалар ничә еллар авыр яра булып йөрәк түремдә ятты. Улым шул якларда булды, бөтенесен белеште, исәннәр белән сөйләште. Кадерле кешеләремнең каберләрен генә таба алмады... Менә шулай, балакай...

– Исән калган Кырым татарларына бик озак кире үз җирләренә кайтырга рөхсәт бирми интектергәннәр икән. Нинди тәмуг аша үткәнәр... Милләтне хәтер яшәтә, диләр...

– Әйе, улым кайткач сөйләгән иде.

– Ул кайда соң?

– Вертолетта очучы иде, военный. Чернобыльдә булды, реактор шартлагач, ком ташып сипкәннәр. Шунда алган нурланыштан зарарланды, үлде, балакаем. Атасы да шул кайгыны күтәрә алмады.

– Алла ярдәм бирсен сезгә!

Хәтирәләргә чумып байтак утырдык без. Шушы хәлләрне хасият белән сөйләп, җан әрнүен бушаткан Гөлсем апа, күңелсез уйлар сазлыгыннан котылгандай, кесәсеннән яулыгын чыгарды. Ул күз яшьләрен сөртеп алды да тәрәзә төбендәге алсу гөлләрен кояшка таба бора башлады. Читтәрәк торган нечкә, авыру гөленә су сипте. Хәсрәт-сагыш дәрьясында ялгызы гомер кичерсә дә, матурлыкка мөкиббән бу әбкәйнең тормыш тарихы, бабалары, улы язмышы сәер хисләр, куркыныч уйлар уятты миндә. Мин аның үзен дә яралы гөлгә охшаттым...

(Дәвамын сайтыбызда укыгыз: www.protatarstan.ru)

PRESSA.RU

ӘДӘБИ СЕРФИНГ, ЯКИ КЕМНӘР УЛ – «ТЕРЕ КЕШЕЛӘР»?

«Китап» төшенчәсе инде шактыйдан фәкать кәгазь вариант кына булудан туктады. Без аларны электрон форматта – ноутбуктан, планшеттан, телефоннардан – укыйбыз. Аннан да бигрәк, «язучы» төшенчәсе үзе дә китап авторы буларак кына кабул ителми башлады. Хәзер аны еш кына «блогер» дигән мөһер белән дә тамгалыйлар. Дөньядагы хәлләргә фикерен махсус сайты, аккаунтлары, блоглары аша белдереп баручылар көннән-көн арта бара. Бу язучының – үзе өчен дә, фанатлары өчен дә уңай. Җаның теләгән теләсә кайсы вакытта бер дулкында булыр өчен.

«КӨЛСӘҢ – КӨЛ, ЕЛАСАҢ – ЕЛА»

Минем яшь журналист танышыма көннәрдән бер көнне интервью әзерләргә кирәк булды. Әңгәмәдәше олыгаеп килгән, заманында гаять популяр булган җырчы ханым иде. Һәм менә ул аны ВКонтакте челтәреннән, Фейсбуктан, ахыр чиктә, Одноклассникидан дөнья бетереп эзләргә тотынды. Тапмады. Үз дөньясы чак җимерелмәде. «Ул беркайда да юк, бәлки, исән дә түгелдер, без генә ишетми калганбыздыр», – дип пошынды. Бәхеткә, җырчы ханым исән иде. Нибары – Интернетта гына түгел.

«Көлсәң – көл, еласаң – ела» дияргә яраталар безнең якларда. Әмма мин танышымны бик яхшы аңлыйм. Ул – замана баласы. Аның өчен ВКонтактеда утырмаучылар тере кешеләр түгел.

«МИН – ТАТАР, ДИМӘК, БУ МИҢА ХАС ТҮГЕЛ...»

Татар Интернеты, ничек кенә «хәзер без дә Интернетта» дип шапырынмасыннар, блогер-язучылары белән әллә ни мактана алмый әле. Фейсбуктагы лентаны «чүпләп» утыру белән кайбер шәхси «мавыгуларны», гафу итегез, блог дип үк атап булмый. Глобаль рәвештә китапханә сайтларына урнаштырылган текстлар һәм биографияләр, рецензияләр дә моңа мисал була алмый. Гәрчә «без Интернетта» дигәндә, өлкәнрәк буын каләм әһелләре нәкъ менә шуны күздә тотса да.

Блог төшенчәсе «бүген һәм шушында» дигәнне аңлата, заманның ачык киңлектәге үзенә бер көндәлек форматы ул. Әйтергә кирәк, интим көндәлек кенә түгел, ә нәкъ менә – язучының социаль-экспериментал лабораториясе дә. Хәзерге Мюссе белән Байроннарга «Исповедь сына века» белән «Паломничество Чайльд-Гарольда» әсәрләренең кайчан нәшрияттән чыгып, замандашларына таралсын, алардагы фикерләр кайчан хатка оешып киләсен көтеп утырырга кирәкми. Төймәгә бер басуың җитә, вәссәлам...

Әмма безнең менталитет икенче төрлерәк корылган. «Бу татарга хас түгел» дигән төймә кабына бездә иң беренче чиратта. Ә бит сүз социаль лакунада иҗатың белән уртаклашып бару мөмкинлеге турында гына бармый, ә чын мәгънәсендә, актив рәвештә гражданлык позицияң һәм дөньяга карашларың призмасы, фәлсәфәң белән бүлешеп, дөньяга таралып яшәп яткан халкыбызга, башка милләт вәкилләренә алып чыгучы элемтә – күпер турында да, асылда.

Аңлагансыздыр инде, бу санда мин әдәби гурманнарны бүгенге көндә популяр булган кайбер язучыларның блогларына сәяхәт итеп кайтырга, үзенә күрә «әдәби серфинг»ка чакырам. Кабул иту-итмәү, кызыксынып китеп, алга таба индивидуаль кемнәрнедер эзләү – күңел эше. Мин әле монда Дмитрий Быков, Дина Рубина, Виктор Пелевин, Януш Леон Вишневский, Татьяна Толстая һ.б. бик күпләрнең популяр блогларына тукталмадым. Бераз экзотигракларына өстенлек бирдем. Блоглар арасында төрлесе бар – кайсылары язучының үз сайтында, кайсылары ЖЖда, кайсылары Фейсбук аккаунтында. Кайберләре һәр өчесендә дә кабатлана, бигрәк тә уңайлы – кайда да үз укучысын эзләп таба, дигән сүз.

«ТАРИХКА МӘХӘББӘТ», ЯКИ БОРИС АКУНИН БЛОГЫ

Нуленче елларның иң популяр мәйданы булган ЖЖ позицияләрен акрынлап зур тизлектә популярлашып өлгергән ВКонтакте, Фейсбук һ.б. шундый челтәрләргә тапшырды тапшыруын. Әмма кайбер эстетлар өчен актуаль булудан барыбер дә туктамады. Дөрес, аның хәзерге аудиториясе өлкәнәйде. Шуның белән бергә – тирәнәйде дә.

Борис Акунин исеме соңгы 15–20 ел эчендә әдәбият тирәсендә нiләр барганын күзәтеп, барлап торучыларга яхшы таныш. Аның нинди язучы, тарихчы, эзләнүче-галим булуына, һ.б. статусларына тукталып тору артык булыр, дип уйлыйм. Сүз монда блогер Акунин турында бара. Һәм, блогер буларак та, ул үзенең «фишка»ларын, аннан да бигрәк, менә дигән юморын, ирониясен саклап кала бирә.

Блогны ачуга ук, беренче булып күзгә ташланган кереш сүз – түбәндәге: «Когда-то ЖЖ был живой, потом стал полуживой, а теперь умер. К сожалению, умер некрасиво». Миңа, ЖЖның даими «серфер»ларының берсенә, Акунинның сарказмы аңлашыла. Кайчандыр мин әлеге чыганактан чынлап та күп нәрсә ала идем. Хәзер бу алгысу кими төште. Блогерларның да иҗтимагый-иҗади юнәлгәнлеге суынды, дисәк, ялгыш булмастыр. Әмма, шулай да, «үлде» дигән вердикт белән тулаем килешә

Автор:
Луиза Янсуар

алмыйм. Чөнки соңгы дистәгә якын ел эчендә генә дә (ә Интернет-киңлек өчен бу бик тә зур вакыт аралыгы) нәкъ менә шушы «мәйдан» миңа Дана Сидерос (Шутник) һәм Лемерт (Алонсо Кехано) кебек авторларны «бүләк итте». Һәр икесенең дә ЖЖдгы битенә сәяхәт итми калган кенем – сирәк. Белеп торыр өчен – нәрсә белән яшиләр бүген Мәскәүдә, Украинада һәм, гомумән, глобальләшкән чынбарлыкта. Нәкъ менә шагыйрьләр нәрсә белән яши – алар бит заманының пульсын чагылдыручылар. Шул пульсны тойганнан соң, инде Пелевин белән Лукьяненко блогларына аяк атларга да була...

Сүз башым бит Шүрәле иде, дигәндәй, Акунинның үз алдына куйган максаты – анык. Ул биредә укучысына китапларының үзләрен, аларга язылган рецензияләрне, аларның таралу-сатылу локацияләрен, маршрутларын тәкъдим итә. Бигрәк тә – яңа идеяләре белән уртаклаша, проектларына апробация уздыра. Аның максаты үзпиар белән шөгыльләнеп утыру түгел, моның өчен ул болай да артык популяр. Акунин өчен иң беренче чиратта аралашу, үзенә ниләр ошый, шулар белән безне дә мавыктыру кызыклы. Элек язучыларны очрашуларга алып чыгалар иде. Хәзер дә бар бу традиция, әмма бераз сүлпәнәя төште. Шунда абый-апалар үзләренең кызыксынулары белән таныштыра. Иҗат кешесенең үзен «кабызган» нәрсәләрне башкалар белән уртаклашудан туктый алганы юк әле. Шушы көнгә кадәр. Чөнки, ул – яшенүткәргеч. Ә блог – моның өчен бик тә кулай замана ысулы.

Акунинның битендә серфингка чыгучыларга аерым аның тарихка кагылышлы язмаларына – постларына игътибар итәргә киңәш итәр идем. Чөнки ул тарихның альтернатив булганын – без дәреслекләрдән укып белмәгәнен яза... Бәлки, безгә дә язып карагадыр? Сүз уңаеннан, ВКонтакте төркемендә бар андый альтернатив төрки-татар тарихын язу белән мавыгучылар. Монда иң мөһиме – чиктән-чиккә ташланмау...

«ШАЯРЫП КЫНА...», ЯКИ ДАНА СИДЕРОС (LLLYTNIK) БЛОГЫ

Кайчандыр Хейзинга формалаштырган «уен фәлсәфәсе» безнең чор өчен үтә дә актуаль булып әверелде. Постмодернмы, постның постымы без хәзер, анык кына әйтүе кыен, әмма «шаярып кына» күп нәрсәләр эшләнә. Кайчак – артык куркыныч нәрсәләр дә...

Шул ук ЖЖ. Көннәрдән бер көнне аның киңлекләрендә Дана Сидерос исемле сәер һәм серле исемгә ия кулланучы пәйда була. Имештер, ул 1985 елда Болгариядә туган. Имештер, ул кеше күзенә күренә, интервьюлар бирә, чыгышлар ясый алмый... Ә, гомумән, бармы соң ул?! ЖЖ кулланучылары, бу серле төенне чишәргә тырышып, миф арты миф тудыралар.

Кыскасы, XX гасыр башы Көмеш чор әдәбиятында Максимилиан Волошин Черубина де Габриак хакында тудырган миф янә бер гасырдан соң кабатлана, дисәк тә ялган булмас. Дана Сидероснең шигырьләрен әләм итеп күтәрәләр, үзен «заманның күзгә күренмәс җырчысы», хәтта ки «яңа пәйгамбәре» буларак кабул итә башлыйлар. Шутник сәхифәсендә утыручылар да артканнан-арта. Аның шигърияттен инде 30лар тирәсенә җитеп килеп тә, әле һаман «кечкенә принц»лар, Питер Пэннар булып калырга, могҗизада яшәргә теләгән юзерлар шунда ук үз итә. Гәрчә бу шигърияттнең катламнары күпкә тирәнрәк булса да.

Дети уходят из города
к чертовой матери.
Дети уходят из города каждый март.
Бросив дома с компьютерами, кроватями,
в ранцы закинув Диккенсов и Дюма...

Пишет Кристина:
«Сами учитесь пакостям,
сами играйте в свой сериальный мир.
Стану гадалкой, ведьмой, буду шептать костям
тайны чужие, травы в котле томить».

Пишет Вадим:
«Сами любуйтесь закатом
с мостиков города.
Я же уйду за борт.
Буду бродячим уличным музыкантом.
Нашел учителя флейты:
играет, как бог».

Взрослые
дорожат бетонными сотами,
бредят дедлайнами, спят, считают рубли.
Дети уходят из города.
В марте.
Сотнями.
Ни одного сбежавшего
не нашли.

Ахыр чиктә, Дана Сидерос үзебезнең Казан кызы Мария Кустовская булып чыга да, беренче китабын бастырыр алдыннан битлеген салып ташлый. Ә китабын нәшриятлар күз текәп көтә, сорап ала. Кемнәрдер аның бу инкогнито алымын үзен популярлаштыруның бер ысулы буларак тәнкыйтьли, әмма Маша исә аны бик гади генә аңлата: «Текстларымның, үземнең түгел, нәкъ менә авторсыз текстларның, укучыга чын-чынлап ничек тәэсир итәчәген беләсем килде», – ди. Мин аны тулаем аңлыйм. Текст беренчелеме укучы өчен, әллә синең тирәңдә хасил булганы антуражмы, дигән мәңгелек сорау белән бимазалануы бу каләм иясенең.

«Шутки кончились» һәм «Ученик дурака» җыентыклары басылып чыкты, Маша һаман да шул ук Мәскәвендә рәссам-иллюстратор булып эшләп ятуын дәвам итә. Һәм яза. «Бомба» шартлаганнан соң, популярлыгы артмады да, кимемәде дә кебек. Нәкъ менә аның укучылары шул ук ЖЖда калды, ВКонтактедагы битендәге яңалыкларны күзәтеп бара, Фейсбукта. Һәм, ничек кенә сәер булмасын, китапларын көтә, заказ бирә, сатып ала. Сүз, ничек кенә сәер булмасын, кәгазь китаплар турында бара.

«ЙӨРӘКСЕЗ МУСКУЛАТУРА», ЯКИ ЯШКА КАЗАНОВА БЛОГЫ

Чорыбызның икенче бер шагыйре, сетература вәкиле, шулай ук актив блогер Яшка Казанова бу җәһәттән социаль эксперимент ясарга батырчылык итте – краудфандинг ысулын кулланып, «Бессердечная мускулатура» китабын бастырыр өчен акча җыюны оештырды. Юк, үзе түләп чыгара алмаганлыктан яисә нәшрият аны бастырырга әзер тормаганлыктан түгел. Киресен-

PRESSA.RU

чә, аның челтәрдәге популярлыгын исәпкә алсак, теләсә кайсы нәшрият бишкуллап тотыныр иде. Сүз уңаеннан, хәзерге әдәби мохиттә бу табигый күренешкә әверелеп бара: язучыларны челтәрдән эзләү, аулау. Әдәби агентлар моны яшерми дә.

Яшка Казанова бары тик үзе теләгән нәшрияттა, үзе теләгән бизәлеш белән генә басылуны кулай күрде. Моннан кала, тагын бер бик мөһим үзенчәлекне ассызыклады ул: «Болай эшләгәндә, укучым минем белән бергәлекне ныграк тоя, ә мин – аның өчен кирәклегемне». Көнбатышта җырчылар шулай альбомнар яздыра, һәм аларның тыңлаучылары: «Безнең дә тарихта урыныбыз бар, эзебез калды», – дип сөенә. Ә кемнең тарихка кереп каласы килми безнең чорда?! Инстаграмны гына актарып чыгу да җитә...

«ЧОРНЫ ЯЗАРГА ҖЫЕНМАГАН ИДЕМ...», ЯКИ ЛЕМЕРТ БЛОГЫ

Поэзия бүген чыннан да челтәрдә яши. Тагын бер мисал – Украинада яшәүче Лемерт исемле автор. Чын исеме – Анна Долгарева. Мин аны 5-6 еллап күзәтәм. Анна – журналист. Күптән түгел «Из осажденного десятилетия» китабы дөнья күрде. Украинадагы хәлләрне кайнар нокталарга йөреп белгән, шушы иттарткыч эчендә яраткан кешесен, дусларын югалткан дәверебез каһарманы. Әйе, челтәрдә аның ситуациясен җентекләп күзәтеп барды: бергә еладылар, дулады, борчылды, кайгырды, кичерде, аңлашты, сөенде, дуслашты укучылары. Сүз, беренче карашка, гади бер кешенең әрнүе һәм кичерешләр гаммасы турында гына бара кебек. Әмма бу очракта – алай гына түгел. Никтер Анна Ахматованың Михаил Булгаков хатыны Елена Сергеевнага мәрхүм Булгаковка багышланган шигырен укытып-ятлатуы һәм аннары ул кәгазьне... яндыруы турындагы истәлек хәтеремә килеп төшә. Лемертның бу шигырен, шөкер, безгә әле укырга рөхсәт:

И приходят они из желтого невыносимого света,
Открывают тушенку, стол застилают газетой,
Пьют они под свечами каштанов, под липами молодыми,
Говорят сегодня с живыми, ходят с живыми.

И у молодого, зеленоглазого капитана
Голова седая, и падают листья каштана
На его красивые новенькие погоны,
На рукав его формы, новенькой да зеленой.

И давно ему так не пилось, и давно не пелось.
А от водки тепло, и расходится омертвелость,
Он сегодня на день вернулся с войны с друзьями,
Пусть сегодня будет тепло, и сыто, и пьяно.

И подсаживается к ним пацан, молодой, четвертым,
И неуставные сапоги у него, и форма потертая,
Птицы поют на улице, ездят автомобили.
Говорит: «Возьмите к себе, меня тоже вчера убили».

Шагыйрьнең нервлары – шигырьдә. Лемерт бүгенге чорның чын мәгънәсендә талантлы, үзенчәлекле шагыйре. Һәм үз чорының елъязмасын язучы булырга да туры килде аңа. Монысын инде кеше үзе сайламый. Язмыш эше. Лемерт үзе бу хакта бер постында: «Һич кенә дә чор турында язарга җыенмаган идем, күбрәк – мәчем турында һәм мәхәббәт...» – дип шаярта. Әйе, глобаль челтәр безне никадәр генә якынайтмасын, арабыздагы киртәләрне ничек кенә җимереп ташламасын, күршебездә хәлләр шаярырлык түгел. Йөрәк мускулатурасы чыдый күрсен берүк кызларның, дип теләргә генә кала.

«БЕРДӘНБЕР ҺӘМ КАБАТЛАНМАС», ЯКИ МАРАТ КӘБИРОВ БЛОГЫ

Әйткәнемчә, безнең язучылар ЖЖ белән дә, үз сайтларын булдыру, әсәрләрен цифр форматында конвертизацияләү идеясе белән дә артык нык «җенләнмәде». Дөрес, матур иттереп, ыспай-җыйнак кына сайтлар эшләп куйдылар күбесе үзенә. Әмма эшләп куелган ул сайт асылда эшләми икән, аның мәгънәсе дә әллә ни сизелми. «Азатлык» радиосы, «Сөембикә» журналы, «Калеб» сайты, «Әдипләр», «Язучылар» һ.б. шундый рәсми порталлар популяррак язучыларга, шәхесләргә үзләрендә блог алып бару мөмкинлеге бирә. Һәм бу – безнең өчен шактый уңайлы, файдалы юл. Социаль челтәрләрдә үз иҗатын популярлаштыру һәм укучысы белән диалог коруны һәркем кирәк дип тапмый, шулай да Фейсбукта, мисал өчен, Фәузия Бәйрәмова моның белән шөгыльләнә. Бу яктан ул – үзенең «зона»сын тапкан кеше. Әмма, зурдан кубып, бердәм сайт эшләү һәм язучыларның үз махсус блогосферасын булдыру идеясе белән чын-чынлап янып йөргән берәүне генә беләм мин – ул да булса Марат Кәбиров.

Үз сайтында шактый актив һәм продуктив эшли ул. Сер түгел, 90нчы – нуленче еллар татар әдәбиятында Марат Кәбиров кебек экспериментларга алынган кешеләр бармак белән генә санарлык. Ул татар прозасын яңа баскычка күтәрү, аны мәгърифәтчелек чорыннан калган, сөрсегән шаблоннардан арындыру теләге белән яши торган кеше. «Сары йортлар сере»ннән соң үз укучысын әллә ничә сискәндерде. Соңгы басылган китабы – «Бердәнбер һәм кабатланмас» – шуның янә бер ачык мисалы.

Марат Кәбиров – язучының мин күзаллаган бүгенге портретына туры килә, шуның белән ул күпләрдән аерылып тора. Тынгысызлыгы, эзләнүләре, теләсә нинди эксперимента алынырга әзер булуы белән күбрәк көнбатышча фикер йөртү тарафдары, дияр идем мин аны. Шуңа өстәп, ул чын мәгънәсендә – бунтарь һәм хулиган. Такташча, Маяковский, Есенинча. Хыялый бер романтигы һәм цинигы безнең заманның.

Сайты да, блогы да – үзенең чагылышы. Анда без Кәбировның лирик-романтик шигърияте белән беррәттән, романнарыннан өзекләрне дә, иронияга корылган үзанализны да, тәүбә-көндәлекләрен дә, әрнүле-шаярулы язмаларны да очрата алабыз.

Марат Кәбировның «Чиксез табут» дип аталган бер әсәре бар. Андагы каһарман, уянып китә дә, башта – үз бүлмәсенең, аннан – җәмгыятьнең, аннан инде дөньяның ук чиксез бер табут булуын ваемлый. Сартр ноталары да, Кафка чалымнары да, көнчыгыш классиклары сирпелеше дә бар әсәр гаммасында. Марат Кәбировка кунакка керергә кызыктырып торган тагын бер үзенчәлек: монда аның җилкәсе артыннан тагын йөзләгән шәхес үрелеп караячак – язучының үз мавыгулары, аңгәмәдәшләре. Әйе, әйе, һичшиксез караячаклар: «Тере кешеләр бармы әле?» – диеп.

МАХСУС ПРОЕКТ

— 24нче чыгарылыш —

Татарстан юбилярлары

PRESSA.RU

ИННОВАЦИЯЛӘРНЕҢ
УН БИШЬЕЛЛЫГЫ

Ярты гасыр эчендә Россиянең иң эре нефть-химия комплексларының берсе тирәсендә тормыш итүнең югары стандартларына җавап бирердәй заманча мегаполис формалашты, алай гына да түгел, фәнне алга җибәрердәй инновацион технологияләрне генерацияләүче Татарстанның куәтле сәнәгать кластеры пәйда булды, дисәк тә ялгышмабыз. «Түбән Кама Нефтехим» эшчәнлеген башлап җибәргән көннән тышкы базарда конкуренцияне тотардай, яңадан бүлүнең иң югары дәрәҗәсенә туры килердәй продукцияне генә чыгара.

1967 елның 31 июлендә Түбән Кама нефтехимия комбинаты Үзәк газ фракцияләү җайланмасыннан беренче продукциясен ала. Бу көннәрдә компаниянең эш коллективларында һәм шәһәрдә дә вакыйгага бәйле чаралар уздырыла. 30 июльдә, әйтик, Түбән Кама Нефтехим ярыммарафоны үткәрелә, аның бер дистанциясенең озынлыгы символик мәгънәгә ия 1967 метрны тәшкил итә. 31 июль иртәсендә «Түбән Кама Нефтехим» ГАҖ үзенең беренче булып бу өлкәне үстереп җибәрүче ветераннарын олылый – иң башта Халык иҗат йортында, аннары, кичен, алар өчен, һәм барлык түбәнкамалылар хозурына Нефтехимиклар паркында зур бәйрәм программасы оештырыла. ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов катнашындагы рәсми юбилей тантанасы 8 сентябрьгә билгеләнгән.

МОДЕРНИЗАЦИЯЛӘҮ – ТОРМЫШ СТИЛЕ

Үзәк газ фракциясе җайланмасының беренче блогын эшләтеп җибәрүдән башлангыч алган Түбән Кама нефтехимия комбинаты бүген Россия нефть химиясе өлкәсендәге әйдәп баручы предприятие, шулай ук Европадагы иң эре нефть химиясе комплексларының берсе дә. Бу җитештерү куәтләрен даими арттыру белән беррәттән, яңа технологияләр кертү һәм көчле фәнни-технологик нигез булдыруның нәтиҗәсе.

Изопрен каучукның беренче брикеты чыгарылган 1970 елдан башлап, ТКНХда яңа җитештерүләр ел саен диярлек кертелә бара. 70нче еллар бутил каучук җитештерү белән дә, изопрен-мономер, этилен, пропилен, бензол һәм бутадиен, этилбензол, стирол җитештерүне башлап җибәрү белән дә билгеле. 80нчеләрдә «Түбән Кама Нефтехим» ГАҖнең тагын берничә яңа заводы продукция белән тәэмин итә башлый. Бу традиция 90нчы елларга кадәр дәвам итә. Башка кайбер оешмалар ничек исән-имин калу турында уйлаудан артыгына ирешә алмаган бер чорда ТКНХ үсә, җитештерүгә альфа-олефин һәм триэтилалюминийны кертә. Нуленче елларда инде җитештерүгә этаплы рәвештә полистриол, полипропилен, полиэтилен һәм АБС-пластик – бәрелүгә чыдам синтетик һәм югары эластик сыйфатка ия полимерлар кертелә. Неодим катализаторга (СКД-L) көйләнгән галобутилкаучуклар белән полибутадиен каучуклар чыгару җайга салына. Литийлы катализатор (СКД-L) нигезендәге полибутадиен каучукны һәм дивинол-стирол каучукны (ДССК) аерып алу һәм киптерү буенча яңа линияләр кертелә, шул исәптән – еллык чыгару күләме һәрберсе 50 шәр тоннаны тәшкил иткән полистиролның дүрт линиясе дә.

Этилен комплексын модернизацияләү аның куәтен елына 600 тоннага кадәр арттырырга мөмкинлек бирә, әмма, төп чимал буларак, этиленга ихтыяҗ арта бара. ТКНХның өстенлекле юнәлешләре арасында түбәндәгеләр бар: 2021 елга этиленны елына 1,2 миллион тоннага кадәр җиткереп чыгарырга мөмкинлек бирә торган яңа олефин комплексы төзү, комплексның күрсәткечләрен 2025 елга исә 1,8 миллион тоннага кадәр арттыру күздә тотыла.

Петербург икътисад форумы барышында «Түбән Кама Нефтехим» ГАҖ генераль директоры Азат Бикмурзин һәм Linde AG оешмасының идарә итүче директоры Джон ван дер Велден лицензияле килешүгә нигезләнгән контрактларны тормышка ашыру, проектлаштыру буенча хезмәт күрсәтү, материаллар һәм җиһазлар белән тәэмин итү, булачак җитештерү өчен техник консультация уздыруны күздә тоткан килешүгә кул куйдылар. Нәкъ шушындый ук этилен комплексын төзү каралган икенче этап турында да сөйләшү булды.

ТКНХ – синтетик каучуклар, пластик, этилен буенча үзебезнең әйдәп баручы җитештерүче. Ул 120 дән артык төр продукция чыгара. «Түбән Кама Нефтехим»ның тышкы базарга 2016 елда барлык төр продукция күләме арасында чыгарган каучуклар өлеше генә дә 75 процентны тәшкил итте. Предприятие Россиягә импортланучы күпчелек каучукларны алыштырырга да сәләтле. 2021 елга аларны җитештерүнең күләмен елга миллион тоннага кадәр җиткерү күздә тотыла, моңа изопрен һәм бутил каучук җитештерүне арттыру һәм ДССК эретү полимерлаштыру ысулын үзләштерү ярдәмендә ирешмәкче булалар. Аның тәҗрибәдәге партиясен инде куллланучылар хәзер үк сыный.

Тагын бер өстенлекле юнәлеш – түбән тыгызлыктагы полиэтиленны чыгаруны арттыру. Элегрәк аның 75 проценты импортка китсә, соңгы ике ел эчендә ТКНХ Россия базарының бу сегментында үзенең продукциясен 19 дан алып 62 мең тоннага кадәр арттырды, агымдагы елда исә сатулар күләмен 100 мең тоннага җиткерергә ниятли.

– Импортны алыштыру буенча зур программа гамәлгә кергәч, линия-

Реклама

* Линде АГ

дәге полиэтиленны импортлау 20 процентка кимеде. Бу күләмнәрне безнең продукция алыштырды, үзебезнең Татарстанныкы, – дип, түбәнкамалыларның уңышларын телгә алды ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов.

Линиядәге полиэтиленны чыгару күләменең артуы бутен-1 белән гексен-1 гә булган ихтыяҗны да көчәйтте, алар әлек чит илдән кертелә иделәр. Узган елны линиядәге альфа-олефиннарны җитештерү сафка бастырылды, күләме елына 37,5 тоннаны тәшкил итте. Бу импортны үзебездәге фракцияләр ярдәмендә алыштыруның бер үрнәге.

Предприятие инженерлары һәм КФУ галимнәре шулай ук изопрен-мономер белән синтетик каучук җитештерү катализаторын чыгару буенча проектка да нигез салдылар. Елына элек импорт буларак кертелә һәм сатып алына торган продукциянең 2 мең тоннадан артыгы алыштырылды.

Узган елның иң әһәмиятле вакыйгалары исәбендә бутил каучук заводында эретү аппаратының чираттагы бишенчесен урнаштыру һәм эшләтеп җибәрү, пластиклар һәм этиленгликоль заводында исә пропиленны чистарту төеннәрен сафка бастыру булды. Ротацияле рәвештә формага салуга тәгаенләнгән полиэтилен маркаларын җитештерүне, капкачлар коюны, торба үткәргечләрдәге каплауларның составын коррозиягә каршы итүне җайга салу буенча тәҗрибәләр ясалып, тагын бер адымга алга киту күзәтелде. Көч үткәргеч кабельләрнең тышчасын җитештерүдә бимодаль полиэтилен куллануны сынау бара хәзерге көндә.

«Иннокам» Кама инновацияләр территория кластерының мөһим үзәге буларак, ТКНХ «Кама Аланы» индустриаль паркына нигез салуны үз өстенә алды. Парк инде Россия сәнәгать мәйданчыгының полимерларны яңадан эшкәртү буенча иң эреләреннән берсе буларак танылды. Ул үзенә нефть химиясе өлкәсендә эшләүче башка предприятиеләрне дә сыендырды.

СОЦИАЛЬ СТАНДАРТЛАРНЫ ИСӘПТӘ ТОТЫП

Предприятиенең регион үсешенә керткән өлешен бәяләп бетереп булмый. Барлык дәрәҗәдәге бюджетларга 2016 елда гына да алар тарафыннан 16,3 миллиард сумнан артык салымнар белән түләүләр кертелгән. Түбән Камада ярты гасыр эчендә генә ТКНХ торгызган объектларны санап бетереп булмаслык, алар шәһәрне «нульдән» төзеде, дисәк тә, ялгышмабыз. Балалар бакчаларын санап чыксак кына да, 1961 елдан алып 1996 елга кадәр аларның саны 69ны тәшкил итәчәк. Ел саен мәктәпләр аякка бастырылды, институт, техникумнар, һөнәр училищелары турында да әйтми узарга ярамас. Сәламәтлек саклау өлкәсенә караган объектлар: предприятие хастаханәсе, шифаханә-профилакторий, балалар хастаханәсе, күппрофильле хастаханә, бала тудыру йорты. Ял базалары белән балаларның сәламәтлеген торгызу лагерьлары, кинотеатрлар, спорт сарайлары, спорт мәктәпләре, ике боз сарае һәм парк сафка кертелде. Коммуналь-көнкүреш юнәлешендәге объектлар, азык-төлек, сәүдә һәм туклану төзелде. «Түбән Кама Нефтехим» шәһәр өчен төзегән тулы торак мәйданын исәпләп чыгарсак (ә ул аны 1994 елга кадәр бердәнбер заказчы буларак башкарды), барысы бергә 3,5 миллион квадрат метрны тәшкил иткән булыр иде.

Үзләре төзегән шәһәрдә ТКНХ үзен, аңлашыла ки, кунакчыл, кайгыртучан хуҗаларча тота. Оешманың идарә итү һәм энергоменеджмент системасы гына түгел, ә тирә-юньне саклау буенча башкарган эшчәнлеге дә халыкара стандартларга тәңгәл килә.

Предприятие инде дүртенче экологик программасын (2020 елга кадәр башкару каралган) тормышка ашыра, ул 7,2 миллиард сумны тәшкил итә.

Түбән Камада яшәүчеләр өчен уңайлы шартлар тудыру – компаниянең социаль сәясәте әнә шуңа корылган. Оешма үз эшчеләрен социаль ипотека программасы һәм өстәмә торак төзү программасы буенча яхшы торак белән тәэмин итә. 2016 елда, ТАИФ КТнең үз эшчеләренә торак белән тәэмин итү буенча моңарчы күрелмәгән карары нигезендә, 477 нефть химиясе өлкәсендә эшләүче гаилә әйбәт фатирларга кереп урнашты. Алар өчен 47 нче номерлы махсус микрорайон торгызылды, эш дәвамында тагын берсенә нигез салынды, анысы 49 нчы номерга ия булды.

Социаль җаваплылык өлкәсендәге традицияләрнең дәвамчанлыгы хакында компаниянең эшләре сөйли.

Нефть химиясе өлкәсендә хезмәт куючылар шәһәрдәге храмны торгызу һәм ике боз сараен төзүдә дә зур тырышлык күрсәтте. 5 меңнән артык агач һәм куак утыртып, ташландык урында Нефтехимиклар паркы төзеделәр. Бүген шәһәр күләмендәге генә түгел, ә республика масштабындагы күп кенә чаралар да шунда уза.

«КаДетство» проекты кысаларында оешма Татарстанның Советлар Союзы Герое Гани Сафиуллин исемендәге Кадетлар корпусына ярдәм күрсәтә. ТКНХ Халыкара спорт чараларын, республика һәм шәһәр ярышларын оештыруда хәйрияче сыйфатында булышлык итә, «Нефтехимик» футбол һәм хоккей клубларына ярдәм күрсәтә, узган елдан «Рубин» футбол клубының генераль иганәчесе булып игълан ителде. ТР Мәдәни һәм тарихи һәйкәлләрне торгызу фондына Болгар белән Свияжскины торгызу өчен нефтехимиклар 680 миллион сум акча күчерде.

2016 елга нәтиҗәләр ясаганда, ТР Президенты «Түбән Кама Нефтехим» ГАҖнең җитештерү буенча уңышларын гына түгел, ә аның Түбән Кама шәһәре юбилеен оештырудагы катнашын һәм социаль мәсьәләләрне хәл итү өлкәсендәге ролен дә аерып билгеләп узды. Юбилей елында оешма Чулман буен торгызу, «Святой Ключ» чишмәсен аруландыру һәм юлларны төзекләндерү өчен генә дә 283 миллион сум сарыф иткән. Ә алдагы елда, үзенең юбилеенда, Лемаев мәйданын төзекләндерү өчен 60 миллион сум бүлеп биргән. Компания шулай ук «Нефтехим-Арена» Боз сарае янындагы территорияне җәяүлеләр йөри торган зоналар калдырып башкарып чыгар өчен 50 миллион сум сарыф иткән, ул әле тагын Соболеково автомобиль юлын реконструкцияләүне дә финансларга әзерләнә.

50 ЛЕТ НИЖНЕКАМСКНЕФТЕХИМ

PRESSA.RU

Илебез нефть химиясе тармагының иң эре предприятиеләренең берсе – «Түбән Кама Нефтехим» гаммәви акционерлык җәмгыяте күренекле датаны – үзенең 50 еллыгын билгеләде. 1967 елның 31 июлендә кулланучыларга нефть химиясе комбинатының тәүге «җимеше» – үзәк газ бүленеше җайланмасының беренче продукциясе җибәрелде.

Рушан Шәмгунов,
«ТАИФ-НК» ГАҖ генераль директоры, техник фәннәр кандидаты, Татарстан Республикасының атказанган химигы

50 еллык иҗади хезмәт

Хөрмәтле Азат Шәүкәтович!
Хөрмәтле «Түбән Кама Нефтехим» ГАҖ хезмәткәрләре һәм ветераннары!

«ТАИФ-НК» ГАҖ коллективы һәм үз исемемнән Сезне һәм предприятиенең барлык коллективын күренекле дата – беренче продукция җитештерүнең 50 еллыгы белән тәбрик итәм! Яңа зур профессиональ бурычларны хәл итүдә ихлас күңелдән зур уңышларга ирешүегезне телим. Буыннан-буынга күчеп баручы хезмәт традицияләре илнең иң эре нефть химиясе компанияләренең берсе булган предприятиенең уңышлы эшләвендә ышанычлы дәлил булып калсын!

«ТАИФ-НК» ГАҖнең формалашуы барлык нефть химиясе тармагы үсеше тарихыннан аерылгысыз. Ярты гасыр эчендә предприятие зур һәм катлаулы юл үтте, әмма компания эшчәнлегенең барлык этапларында аның төп максаты – республиканың социаль-икътисади үсешенә ярдәм итү үзгәрешсез калды. Бу еллар эчендә бик зур тәҗрибә тупланды, данлы традицияләр барлыкка килде, зур масштаблы проектлар тормышка ашырылды. Нефтехимиклар шәһәре – хаклы рәвештә илнең нефть химиясе башкаласы дип исәпләнә торган гүзәл Түбән Каманың төзелүе дә нәкъ менә химкомбинат белән бәйле.

Гигант промышленность предприятиеләренең вакыт исәпләре үзгә, һәм алтын юбилей – ул «Түбән Кама Нефтехим»ның данлы тарихының башы гына әле. Бүген «ТАИФ» компанияләре төркеменең бу иң эре күппрофильле предприятиесе Татарстан Республикасының куәтле нефть химиясе комплексының нигезен тәшкил итә. Россия Федерациясендә синтетик каучук һәм пластиклар җитештерү буенча әйдәп баручы һәм Европаның иң эре нефть химиясе компанияләренең берсе буларак, «Түбән Кама Нефтехим» нефть химиясе һәм нефть эшкәртү сәнәгатенең комплекслы мәсьәләләрен иң заманча дәрәҗәдә уңышлы хәл итеп килә. Компаниянең үсеш стратегиясе, аның югары квалификацияле кадрлары һәм куәтле җитештерү базасы булу «Түбән Кама Нефтехим» ГАҖнә Россия һәм чит ил товар базарларында үзләштерелгән сегментларда үз позициясен ныгытырга, җитештерелә торган продукциянең конкурентлыкка сәләтен арттырырга мөмкинлек бирүче уңышлы эшнең нигезе булып тора.

Хөрмәтле Азат Шәүкәтович! Бу истәлекле көндә Сезгә һәм предприятиегезгә билгеләнгән планнарыгызны тормышка ашыруда тайпылышсыз алга баруыгызны, ә компаниянең барлык хезмәткәрләренә тотрыклылык, бәхет һәм иминлек телим! «Түбән Кама Нефтехим» ГАҖ туплаган үсеш темпы, югары җитештерү мөмкинлеген арттыра барып, Татарстан Республикасы һәм туган Россиянең алга баруы өчен югары нәтиҗәләргә ирешергә ярдәм итсен!

Реклама

Денис Синицын,
«ГСИ-Гипрокаучук» ЖЧҖ генераль директоры

Илнең иминлеге хакына 50 еллык хезмәт

«ГСИ-Гипрокаучук» ЖЧҖ («Глоболстрой-Инжиниринг» АҖнең бүлендек предприятиесе) – Синтетик каучук сәнәгате дәүләт проект һәм фәнни-тикшеренү институтының хокукый дәвамчысы. Ул Татарстанның ягу-энергетика комплексы белән тыгыз хезмәттәшлек итә – аңа нефть химиясе һәм нефть эшкәртү тармакларын үстерергә ярдәм итә.

«Түбән Кама Нефтехим» ГАҖнең туган көне дип 1967 елны исәплиләр, нәкъ менә шул вакытта «Гипрокаучук» проекты буенча Үзәк газ фракциясе җайланмасының (ҮГФҖ) беренче блогы тапшырыла. Әйтергә кирәк, уртак эш моңа кадәр үк башланган була инде: әле 1959 елда, «Гипрокаучук» Дәүләт проект институты химкомбинатның генераль проектлаучысы буларак билгеләгәннән соң ук.

Түбәндә санап үтелгән барлык производстволар да «Гипрокаучук» проектлары буенча эшләтеп җибәрелгән. Нефть химиясе комбинатының тиз арада үсеп китүе 1970 елдан башлана. Шушы чорда биредә 60 мең тоннадан башлап, алга таба 100 мең тоннага кадәр җиткән (1973 ел) изопентанны дегидрацияләү аша изопрен (изопрен каучук җитештерү өчен чимал) җитештерүе сафка бастырыла. Шул ук 1970 елда куәте елына 60 мең тоннадан башлап, алга таба – 120 мең тоннага (1973 ел), аннан – 150 мең тоннага (1975 ел) һәм 200 мең тоннага (1983 ел) җиткән СКИ изопрен каучугын җитештерү эксплуатациягә тапшырыла. Химкомбинатның планлаштырылган куәтен үстерү һәм продукция номенклатурасын киңәйтү буенча адымнарына алшарт булып 750 мең тонна куәт белән эшләүче ҮГФҖның икенче блогын төзү һәм аның 1971 елда режим күрсәткечләренә чыгуы тора. Нефть химиясе гигантының үсешендә чираттагы этап булып елына 90 мең тонна куәтле бер стадияле д гидрацияле бутан җитештерүне эксплуатациягә тапшыру була. Бу, үз чиратында, елына 35 мең тонна куәтле, алга таба – елына 45 мең тонна куәткә (1990 ел), 60 мең тонна куәткә (1996 ел) ия булачак бутилкаучук (1973 ел) җитештерүен сафка бастырырга мөмкинлек тудыра.

Изопрен каучукны эшләп чыгаруны арттыру өчен изопренны ДМД аша җитештерү җайга салына. Җитештерүнең куәте елына 60 мең тоннага (1975 ел) кадәр җитә. Киләчәктә җитештерү куәтен елына 120 мең тоннага (1976 ел) һәм 185 мең тоннага (1985 ел) җиткерү күздә тотыла. Бу, үз чиратында, куәте 120 мең тоннага җиткән, алга таба 250 мең тоннага (1984 ел) кадәр күтәрүне исәптә тоткан СКИ производствосының икенче чиратын эшләтеп җибәрергә мөмкинлек бирә.

«ГСИ-Гипрокаучук» ГАҖ проектлары буенча шулай түбәндәгеләр төзелде:

- этилен окисе җитештерүнең куәте 120 мең тоннага (1980 ел) һәм 200 мең тоннага (1986 ел) җиткән I һәм II чиратлары;
- стирол һәм пропилен производствосы (1982 ел);
- куәте елына 100 мең тоннага җиткән алкилфенол производствосы;
- куәте елына 250 мең тоннаны тәшкил иткән өслекле-актив матдәләр производствосы;
- куәте елына 30 мең тоннаны тәшкил иткән этилен-пропилен каучук җитештерүе.

2004 елда галобутилкаучук (ГБК) производствосын эшләтеп җибәрүне аерып искә алып үтәсе килә. Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов тарафыннан «Түбән Кама Нефтехим» ГАҖ юнәлешен үстерүгә аеруча игътибар бирелүе амбициоз проектларыбызны тормышка ашырганда ышанычыбызны арттыра. Ә алар, үз чиратында, предприятиене заман таләпләренә җавап бирердәй яңа дәрәҗәгә чыгарырга мөмкинлек бирә. Бу, беренче чиратта, пластиклар җитештерүне интеграцияли торган һәм куәте елына 1,2 миллион тоннага кадәр җитәрлек яңа олефин комплексын төзүгә кагыла.

«Түбән Кама Нефтехим» ГАҖ партнерлары алга куелган техник бурычларны хәл итүдә уңышлы ярдәм күрсәтер, дигән ышанычта калабыз.

ГЛОБАЛСТРОЙ ИНЖИНИРИНГ

«ГСИ-Гипрокаучук»ЖЧҖ
105318 Мәскәү, Ибраһимов ур., 15, корп. 1
Тел. (499) 973-75-75 (өст. 7072, 7678)
Факслар: 402-89-63, 973-75-75 (өст. 7785)
E-mail: welcome@gpkauchuk.ru
www.gpkauchuk.ru



Хөрмәтле Азат Шәүкәтович!

«ГСИ-Гипрокаучук» ЖЧҖ Сезне һәм «Түбән Кама Нефтехим» ГАҖ коллективын чын күңеленнән 50 яшьлек юбилее белән тәбрик итә. Әлеге вакыт аралыгында күпсанлы инновацион технологик процессларга нигез салына, һәм алар уңышлы эксплуатациягә дә тапшырыла. «Түбән Кама Нефтехим» ГАҖ коллективы алдына куелган олы бурыч – олефин комплексын төзү бурычы уңышлы тормышка ашырылыр, дип ышанабыз. Сезгә һәм «Түбән Кама Нефтехим» ГАҖ коллективына зур уңышлар, сәламәтлек һәм иминлек телибез!

Реклама

PRESSA.RU

МИНЗӘЛӘ АЮЫ

Казан–Уфа автотрассасын узганда, юл өстендә Аю авылы кала. Янәшәдәге рус салалары арасында бердәнбер татар авылы ул. Җай чыкса, һичшиксез, әлеге үзенчәлекле исемле авыл белән танышып чыгарга кирәк, дия идем. «Җаны теләгән елан ите ашаган» дигәндәй, андый мөмкинлек туды. Җәйнең кояшлы бер көнендә Аюны күреп кайттык.

«МЕДВЕДЕВО?»

Аю авыл җирлегенә Маткауш, Дыреевка, Степановка авыллары, Урта Ружевка бистәсе керә. 2010 елның маеннан Дружба авылы да шушы җирлеккә кушылган. Халык биредә руслашкандыр дип уйлаган идем, ялгышканмын. Милли җанлылар, хәтта үзләренең «Ак калфак» фольклор ансамбленә кадәр булдырганнар.

– Әйе, безнең җирлектә халык җыелышлары рус телендә уза, – диделәр Аю авылы җирлегендә. – Ә калганы, барысы да үзебезчә. Балалар мәктәптә татарча укый, сөйләшә. Бәйрәм-кичәләр ана телендә уза.

Аю мәдәният йорты директоры Роза Гыйльфанова белән китапханәче Вәсилә Әхмәтҗановадан авылның атамасы турында кызыксындым. Зыялы, мөлаем ханымнар менә нәрсәләр сөйләде:

– Ике төрле фараз бар. Беренчесе (күренекле профессор Гомәр Саттаров фикере): Аю дигән борынгы төрки кеше исеме яки башкортларның Үсергән кабиләсенә карый торган «айыу ыругы» исеме белән бәйле. Шулар әлеге җирләргә килеп төпләнгән дигән фараз бар. Икенчесе (ата-бабалардан калган сүз): бу урында аюлар күп яшәгән. Шуңа күрә әлеге хайван исемен авылга да биргәннәр. XVIII–XIX гасырларда авыл, русчалатып, Медведево дип аталган. Ә менә 1940 елдан аның бары хәзерге татарча атамасы гына теркәлгән. Юныс абый Йосыпов авылыбыз тарихына багышлап зур булмаган китап чыгарды. «Басу моңы яралган җирдә...» дип атала ул. Менә шул китапны эшләгәндә бик күп документлар табылды. Мисал өчен, 1795 елда авылда 30 хуҗалык булган һәм 186 кеше яшәгәнлеге билгеле. Ә 1884 елда хуҗалыкларның саны 81 гә җиткән, халык саны да 442 гә әйләнгән. Ачлык башланганчы, ягъни 1921 елда 708 кеше яшәсә, 1923 елда 600 кеше калган...

Бүген Аю авылында 424 кеше яши, 185 хуҗалык бар. Биредә төп проблема – юлсызлык. Автотрассага орынып ук торган авылга язын-көзен кереп булмый икән. Быелгы яңгырлы җәйдә дә интеккән халык. Күптән түгел Аю җирлегенә башлыгы алышынган. Яңа җитәкче Руслан Ильинның беренче эш көне иде, аерым сорауларга җавап бирә алмады ул. Алай да быел җыелган үзара салым акчасына юл салу нияте барлыгын әйтте.

УМАРТАЧЫ БАЛТА ОСТАСЫ

Без Аюга барган көнне кояшлы иде. Шуңа күрә начар юлның нинди булуын үз күзләребез белән күрә алмадык. Авыл халкы көзге пычраклар вакытында килергә чакырды. Ә нәрсә, бәлки, чынлап та үзара салым акчасына ясалган юлны килеп күрербез? (Берочтан авыл кешесеннән җыелган акчаның да ни дәрәҗәдә акыллы файдаланганын күрербез). Аю безнең күңелдә, һичшиксез, матур табигате, яшел чирәм үскән урамнары белән истә калачак.

Иң беренче булып авылның атаклы балта остасы, умартачысы Нурлыбаян абый Хәлиуллин янына кердек. Тормыш иптәше Гөлфинә апа белән 52 ел бергә яшиләр икән. Бер ул һәм бер кыз үстергәннәр. Вильсур гаиләсе белән – Минзәләдә, Алсу Чаллыда яши. Гөлфинә апа гомере буена Аю урта мәктәбендә тарих укыткан. Аларның җиләк-җимеш, яшелчә бакчасын күргәч:

– Картлыкка бирешмәгәнсез. Бу кадәр бакчаны үзегез генә карыйсызмы? – дигәнемне сизми дә калдым.

– Бабай белән икәү, – диде Гөлфинә апа. – Зур эшләргә балалар

Автор:
Руфия Фазылова

Фото: Александр Ефремов

да кайта. Алабута үстереп булмый бит. Җәй буе бакчадан кермибез. Картлыкка бирешеп торырга вакыт юк шул.

Хәлиуллиннарның вакытлары чынлап та юк. Дистә баш тавык, чеби, индоутка... Шуңа өстәп 12 баш умарта да тоталар. Егерме ел элек Нурлыбаян абый уң кулын циркулярда өздергән. Тик бәхетсезлек килде дип, төшенкелеккә бирелмәгән, сул кул белән ашарга да, эшләргә дә өйрәнгән. Алай гына да түгел, юкә агачы башына менеп, оядан аерылып чыккан кортларга кадәр җыеп төшә икән:

– Һәр эшкә дә кеше чакырып булмый бит, – диде Нурлыбыян абый. – Балаларны да борчыйсы килми. Яшәсәң, кешегә авырлык китерергә кирәкми. Уң кулның көче дә сулга гына күчте: бакчаны да казыйм, балта эшен дә эшлим. Кулсыз калдым дип, елап утырмадым. Ирләр булырга кирәк!

– Агач башына ничек менәсез? – дим.

– Аллага шөкер, ике аягым да сау-сәламәт бит. Сул кул белән тотынам, аяклар белән этәреләм. Кортлар, гадәттә, юкәнең иң очын сара. Шуннан җыеп алам.

Хәлиуллиннарның йортларын юкәләр әйләндереп алган. Хуҗа кеше агачларны махсус утырткан: кортлар качмасын, юкәдән бал җыйсын, дип. Нурлыбаян абый гомере буе корт тоткан. Быел умартачылар зарлана: җәй соңга калу, яңгырлы булу сәбәпле, бал аертмаганнар. Хәлиуллиннарның да кортлары әле балны «пичәтләп» кенә килә икән:

– Әйе, умартачылар өчен бик уңышлы ел булмады быел, – ди Нурлыбаян абый. – Кайбер кешеләр, акча булсын диптер инде, икешәр тапкыр бал аерта иде. Быел юк. Тик шулай да өмет бар: кортлар тырышып эшли. Ашарлык булса да бал булачак, монысында шигем юк.

Бал дигәннән, Хәлиуллиннар, оясыннан аерылып чыгып оча башласа, кортларга су сибәләр икән.

– Яңгыр ява дип уйлыйлар булса кирәк, кортлар янә ояларына керәләр, – дип, тәҗрибәсе белән урташты Гөлфинә апа.

Аю авылында Нурлыбаян абыйның кулы орынмаган йортлар сирәк: балта остасы, бизәкле тәрәзә яңакларыннан башлап, бөтен йортка кадәр эшләгән. Хәзер алай йөрми инде, үзенең йортында гына агачтан могҗизалар ясый. Аның йортында агач умарта оясына кадәр челтәрләп бизәкләнгән. Капка, сарай, йорт кыеклары турында әйтәсе дә юк. Моннан тыш, Нурлыбаян абый авылның атаклы баянчысы да. Аюда бер генә мәҗлес тә ансыз узмаган.

PRESSA.RU

– Менә, әле генә эшләп куйдык, – дип, Гөлфинә апа яңа казылган коеларын күрсәтте. – Элек коены каршыбызга эшләткән идек. Искерде инде ул. Елга буенда яшәгәч, бездә су чыксын өчен җирне тирән казырга кирәкми. Дүрт метрдан эчәргә яраклы бер диген су чыкты. Насос белән шуннан көн дә суыртабыз.

«ЧИГҮ МОДАДА ИДЕ...»

Аюда әниле-кызлы тагын бер үзенчәлекле кешеләр белән таныштык: Разыйма апа Тимерханова. Ул эшләгән чигүле сөлге, җәймәләрне район, республика күләмендә узган төрле конкурс-кичәләргә алып баралар икән.

– Чигүле әйберләрне кызым Зөлфидәгә бирдем, аларда саклансын, гомерне белмәгән, – дип каршы алды безне Разыйма апа. – 79 яшь тулды, балалар. Яшь бара. Әле Аллага шөкер, әйбәт йөрим. Чебиләр, үрдәкләр үстерәм, бакчада да эшлим. Балалар кайта. Өч кыз, бер улым бар минем. Хәзер кайтып җитәләр үзләре... Рәхмәт. Кош-кортны да алар дип алам. Ялгыз кешенең ни ашы, ни эше дигәндәй. Ә өйгә балалар, оныклар кайткач күңелле, шулай яшәргә кирәк.

Разыйма апа Аю авылында туып-үскән. Кырык ике яшендә тол калган. Аннан, балаларга да якынрак булырмын дип, Чаллыга эшләргә киткән. 1991 елда янә Аюга – өлкән яшьтәге әтиәнисен карарга кайткан. Һәм туган нигезендә калган.

– Әни – 95, әти 96 яшькә җитеп үлде, – диде Разыйма апа. – Гаиләдә бердәнбер кыз мин. Пенсиягә чыккач, әти-әни янына кайттым. Сыер да алдым. Алтмыш тугыз яшемә кадәр сыер асрадым. «Әни, ялгызың җәфаланма», – дигәч кенә, сыерны саттым. Без бит эшләмичә торырга өйрәнмәгән. Җәй көне ярый, бакча бар. Ә кышын нишләмәк кирәк? Хәзерге яшьләргә аптырыйм мин, сыер, сарык асрамыйлар. Итне, сөтне сатып алалар. Безнең заманда печән табып булмый иде, хәзер болын тулы печән, чабучы гына юк. Ялкауланды халык.

Разыйма апа туган авылы турында менә нәрсәләр сөйләде:

– Авылның иң чәчәк аткан чоры – безнең балалар үскән чорга туры килде. Параллель класслар бар иде. 1990нчы елларда бала саны кимеде. Мин каян хәтерлим: ул елларны авылда яши идем. Бездә бик алдынгы «Рассвет» совхозы бар иде. Ул таралды. Кешегә эш калмагач, яшьләр дә авылда бик калмый башлады.

– Ә чигүгә хирыслык каян килә? – дим.

– Безнең заманда авылда чигү чикмәгән кеше булдымы икән? Юктыр. Ашъяулык, сөлгеләр дисеңме, челтәргә кадәр бәйли идек. Кызларым да миннән күреп бу эшкә өйрәнде. Ул чакларда өебездә чигелмәгән әйбер юк иде. Кызлар солдат озатканда төн йокламыйча яулык чикте. Аның нинди генә төре, бизәге юк иде. Тора-бара чигүнең модасы китте. Кул эшләнмәләрен җыеп, юып, матурлап төреп алып куйдык. Өйдә бүген чиккән берничә мендәр тышы гына калды.

МӘКЛЕ ЙОРТ

Чигүле әйберләрне күрергә теләп, Разыйма апаның кызы Зөлфидә апа йортына киттек. Нәбиуллиннар Аюның иң өске урамына зур йорт салып чыккан:

– Бу инде икенче йортыбыз, ун ел элек шушы нигездәге өр-яңа өебез янды, – дип үзләре турында сөйли башлады Зөлфидә апа Нәбиуллина. – Чаллы шәһәрендә гомер иттек. Ирем Самат белән ике ул үстердек. Балалар өйләнеп, башлы-күзле булдылар, оныклар бүләк иттеләр.

Зөлфидә апа берәм-берәм чигүле әйберләрне чыгарды. Нәрсә генә юк монда... Хәтта аерым бер күргәзмә эшләргә булыр иде!

– Бу әйберләрнең нәселдән-нәселгә күчә торган кадерле ядкарь булуын телим, – диде Зөлфидә апа. – Әнине күреп үскәнгәме, кул эшләрен бик яратам. Чигү генә түгел, сәйләннән төрле бизәкләр эшләү, рәсем ясау – барысына да битараф түгелмен. Дусларым, туганнарым миңа гел кулдан ясалган әйберләр, картиналар бүләк итә. Яратканны беләләр.

Зөлфидә апаның тагын бер «сәерлеге» бар: аның өендә бөтен нәрсә мәк чәчәгеннән. Гади чәй эчә торган чынаяктан, шикәр савытыннан башлап, урын-җире, аерым җиһазларга кадәр. Әйтерсең, мәк аланында йөрисең.

– Мәккә мәхәббәт кайдан килә? – дим Зөлфидә апага.

– Белмим, төгәен генә әйтә алмыйм. Әлеге йортны акрынлап ун ел төзедек. Кая барсам да, мәкле әйбер сатып алдым. Хыялымдагы йорт бу. Үзем кебек чәчәкле.

Зөлфидә апа лаеклы ялда, тормыш иптәше Самат абый хезмәттә әле, шуңа күрә гаилә күбрәк Чаллыда яши. Елларда исә «хыялдагы йорт»ка җыелалар. Якын киләчәктә ир белән хатын Аюдагы бу йортларына бөтенләй күченеп кайтырга ниятли.

– Улларым, килен, оныклар да авылны ярата, – ди Зөлфидә апа. – Кайчан кайтабыз, дип кенә торалар. Безнең урамга бөтенләй юл юк иде. Узган ел ирем берничә йөк машинасы таш алып кайтып җәйдерде. Хәзер җиңел машина белән керүп йөри башладык.

Нәбиулллинарның бакчаларында ни генә үсми: ясмин агачы, вербена, тырнак гөле, мәтрүшкәнең әллә ничә төре һәм башка дистәләгән дару үләннәре. Бөтен җирне виноград агачы чорнап алган, аның өч-дүрт төрле сорты бар.

– Быел виноград соңрак өлгерәчәк, – диде Зөлфидә апа. – Җәй салкынрак булды бит. Виноград алдагы елларны бик яхшы уңыш бирде. Бер тәлгәш 800–1500 граммга кадәр җитте. Аннан кайнатма, компот та әзерлибез. Туганнарга, дусларга да бирәбез. Тәҗрибә өчен виноградның тагын яңа сортларны утыртып карыйсы килә әле.

– Ә моның кадәр дару үләнен нишләтәсез? – дим.

– Җыеп киптерәм. Җәй буе яшел чәй эчәбез. Сәламәтлеккә файдасы бик зур. Менә күрәсез ич, кызлар кебек йөгереп йөрим. Үз яшемне дә бирмәссез, – дип, чын күңелдән сөенеп, елмаеп куйды Зөлфидә апа.

КЫРЫК ЕЛЛЫК ӨР-ЯҢА МӘКТӘП!

Аюның төп белем бирү мәктәбендә дә булдык. Авыл мәктәпләре арасында рейтинг буенча районда беренче урында икән. Директор Айрат Галимов белән гөлгә күмелгән бакчаларны, махсус ясалган хоккей мәйданчыгын карап чыктык.

– «Милли мәктәпләрне тәмамлаган балалар чыгарылыш имтиханнарын начар бирә» дигән сүзләрнең киресен раслыйбыз без, – дип сөйләде Айрат Галимов. – Укучыларыбыз берничә ел инде төп дәүләт имтиханнарыннан югары баллар җыялар. Район рейтингында ике ел рәттән беренче урынны алдык. Бу укучыларның да, укытучыларның да зур тырышлыгы нәтиҗәсе. Алга таба да шушы югарылыктан төшмәскә исәп. База яхшы, мөгалимнәребез тәҗрибәле.

2011 елга кадәр Аю белем бирү йорты урта мәктәп булган. Балалар саны кимегәч, тугызъеллыкка әйләнгән. Быелгы уку елында 30 бала белем алачак. Авылның киләчәген, күркен директор нәкъ менә мәктәптә күрә:

– Мәктәп ябылса, авыл бетә, – ди Айрат Галимов. – Бу минем сүзләр генә түгел, расланган дәлил. Балалар бакчасына унлап бала йөри. Әле мәктәпнең киләчәге бар, дигән сүз. Аннан нәрсә булыр, билгесез. Яшьләр калмый бит. Без исә хәлдән килгәннең барысын да эшләргә тырышабыз, спортка игътибар зур. Кичен спортзал көн саен ачыла, төрле түгәрәкләр, ярышлар дисеңме... Алайса авылда балаларга мөмкинлекләр юк, диләр. Менә ул: барысы да бар, килсеннәр, йөрсеннәр генә. Чыгарылыш сыйныфлар белән укытучылар аерым шөгыльләнә. Минемчә, яшьләрне авылда калдыру өчен аерым бер программа эшләргә кирәк. Үз эшен булдыру, йорт салып бирү һәм ул аңлаешлы, ачык булырга тиеш.

Мәктәп турында сөйләгәндә Айрат әфәнденең күзләре яна. Үз эшен яратып, җиренә җиткереп эшләгән кеше икәнлеген аңлар өчен, зур белгеч булырга кирәкми. 40 ел элек салынган, бер тапкыр капиталь ремонт күрмәгән белем йорты эчтән дә, тыштан да ялт итә. Нәрсәнең кайчан алынганын, ничек эшләгәнлеген бәйнә-бәйнә сөйли. Менә шундый директоры булган мәктәп ябылмыйдыр ул.

Без үз якларыбызда шактый гомерләрдән бирле «яшәп килгән» Татарстан риваятьләрен җыюыбызны дәвам итәбез. Азнакай районында бөтен риваятьләр Чатыртау тирәсендә әйләнә. Ул әкиятләр белән тулып торган китап кебек.

ТАТАРСТАН РИВАЯТЬЛӘРЕ: ӘКИЯТЛӘР ТАВЫ

БЕРЕНЧЕ ӘКИЯТ. ПАТШАЛЫ

Тау эчендә үзенә көмешне тартып торучы патша-магнит бар, дип сөйлиләр. Шуңа күрә моннан тибеп чыккан чишмәләрнең – ә алар биредә бихисап – суы шифалы, ягъни биредәге халык сөйләвенчә, – изге. Аларның берсе – «Чатыр чишмәсе» («Изге чишмә») мәгарә тирәсеннән агып уза. Аның янына борын-борыннан авыру кешеләр килгән, чатырлар корган һәм изге су белән коенган. Нәкъ менә биредә, үлгәннән соң, изге дип кабул ителгән кешеләрне юганнар. Ә исәннәр елга бер тапкыр булса да шифалы су белән госел коенырга килгән.

ИКЕНЧЕ ӘКИЯТ. ШӘФКАТЬЛЕ

Данлыклы тауның күзгә күренми торган шәфкатьле көче бар диләр. Кайберәүләр аны «тау иясе» дип атый. Халык әйтүенчә, Чатыртау башында теләнгән теләк, һичшиксез, кабул булачак.

ӨЧЕНЧЕ ӘКИЯТ. ИЗГЕ

Чатыртауның «Изгеләр тавы» дип аталган ягында изге кешеләрне җирләгәннәр, дигән сүзләр йөри. Җеназада катнашкан һәрбер кеше үзе белән кечкенә генә булса да таш алып килә торган булган. Ул ташларны, шайтанны куу, вафат булган кешенең рухын чистарту һәм аның Аллаһының катына тизрәк барып ирешүен теләп, кабер өстендә калдырганнар. Дала уртасындагы ташлар өеме изге урынга әверелгән.

ДҮРТЕНЧЕ ӘКИЯТ. ӘКИЯТИ

Шулай сөйлиләр... Шушы урында үзенең «халык гаскәре» белән лагерь корган Емельян Пугачев турында барысы да сөйли. Ә күпләр тау башындагы мәгарәләрнең борынгы коралларны саклау урыны булуына бүгенгәчә ихлас ышана... Һәм ул коралларны табарга хыяллана. Тик файдасыз. Шуңа да карамастан, бу риваять торган саен «картлар» сөйләгән яңа серләр белән тулылана бара – янәсе, кайчандыр мәгарәгә керү юллары шундый биек булып, алардан атка атланып узарга мөмкин булган, ә мәгарә эчендә ятаклар һәм өстәлләр уелган бүлмәләргә кадәр ясалган...

Реклама 16+
ТАТАРСТАН
Журнал акыллы, игелекле, мәңгелек кыйммәтләргә ия булган эксклюзив открыткалар сериясе тәкъдим итә
Кис тә бүләк ит
–30 августта очрашыйк. Шул ук урында, шул ук сәгатьтә. Яратам, үбәм, көтәм!
96 еллык зирәклек
ТАТАРСТАН
журналы
30 август.
Татарстанны яратам!

PRESSA.RU

– Мин үбәргә
әзер сине,
Татарстан.
Сөйгәнемне
синдә таптым
һәм...
яратам!
Реклама 16+